ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН ЗАМАН ТАЛӘПЛӘРЕ КУШКАНЧА УКЫТАБЫЗ

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН*

КАЗАН
2015

**ББК 74.268.1 Тат**
**Т 23**

**Проект җитәкчеләре:**
**Р.Г. Хәмитов,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Л.Ф. Салихова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты укыту-методик эшләр буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты

**Төзүчеләр:**
**Р.Р. Шәмсетдинова,** МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты
**Г.Н. Мөхәрләмова,** МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
**Г.В. Һадиева,** МҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы
**Ф.Т. Махмутова,** ТР Бөгелмә муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең мәгълүмати-методик үзәге методисты

Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләренә нигезләнеп укытабыз. ТР Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән: уку-укыту методик кулланма. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 160 б.

© ТРМҮИ, 2015

## ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ СҮЗ.......................................................... 6

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ
ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ. Фәттахова М.К. .................................11

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ РУС ТЕЛЛЕ
БАЛАЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ СӘЛӘТЛӘРЕН
ҮСТЕРҮ ӨСТЕНДӘ ЭШ. Хәмидуллина С.М. ..............................17

СОВРЕМЕННЫЕ ПОДХОДЫ К ОБУЧЕНИЮ
ШКОЛЬНИКОВ ГОСУДАРСТВЕННЫМ ЯЗЫКАМ.
Смирнова И. М. .......................................................21

ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕНДӘ МЕТОДИК ХЕЗМӘТНЕ
ОЕШТЫРУ. Гайнуллина З.Җ. ..........................................25

СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ.
Зәйнуллина Ф.В. ......................................................29

ТЕЛЕ БАРНЫҢ ЮЛЫ БАР. Хафизова Р.Ә. .............................34

ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ТОРМЫШЫН ҺӘМ ИҖАТЫН
МӘКТӘПТӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ АЛАРНЫҢ
ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ. Хафизова Р. ...............................39

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТӨРЛЕ
ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ УЕННАР ҺӘМ БАШВАТКЫЧЛАР КУЛЛАНУ.
Гайнуллина Г.М. .......................................................45

ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ
УКЫТУНЫҢ НӘТИҖӘСЕН ҮСТЕРҮ. Гайсина Р. З. ....................53

РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ
ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР. Фатхлисламова С. .....................57

ЯЗМЫШЛАР БИТ БЕЗ ДИГӘНЧӘ ТҮГЕЛ… (Хәсән Туфан
иҗаты буенча сыйныфтан тыш чара). Гыйләҗева Г.Л. ..............63

БЕЛЕМ БИРҮ СЫЙФАТЫ УКЫТУНЫҢ НӘТИҖӘЛЕ
ЫСУЛЛАРЫН ФАЙДАЛАНУГА БӘЙЛЕ. Сөнгатуллина Г. Ф. .........70

ХАЛЫК ТАРИХЫ – ИСЕМНӘРДӘ. Тахаутдинова Г. С. ................73

СОСТОЯНИЕ И ПУТИ СОВЕРШЕНСТВОВАНИЯ ЯЗЫКОВОГО ОБРАЗОВАНИЯ В УСЛОВИЯХ ГОСУДАРСТВЕННОГО ДВУЯЗЫЧИЯ. Хайбуллина Г. М. ............... 77

ПОЛИЛИНГВИЗМ ШАРТЛАРЫНДА ТЕЛНЕ ӨЙРӘТҮ. Харисова Р. С. ............... 83

ЗӘКӘРИЯ ӘХМӘРОВНЫҢ «ӘЛӘКЧЕ» ХИКӘЯСЕНДӘ ТӘРБИЯ ПРОБЛЕМАСЫНЫҢ КУЕЛЫШЫ (рус төркеме, 6-в сыйныфы). Гомәрова М. Җ. ............... 88

МӘКТӘП – ТЕАТР ТҮГЕЛ ... SCHOOL IS NOT A THEATRE. Ихсанова Г.Ф., Нестерова В.Н. ............... 97

ҺӨНӘР САЙЛАУ-ҖАВАПЛЫ ЭШ (6 нчы сыйныф рус төркеме өчен дәрес эшкәртмәсе). Асылгәрәева Г. В. ............... 105

ДӘРЕСЛӘРДӘ ЗАМАНЧА ИНФОРМАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ. Пушкарная Г. Р. ............... 111

УРМАН – ХАЛЫКНЫҢ БАЙЛЫГЫ (ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЕ). Ибатуллина Л. З. ............... 115

РЕЧЕВОЕ ПОВЕДЕНИЕ УЧИТЕЛЯ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА. Абдрахимова Р.Ш. ............... 121

“СЫЙФАТ” ТЕМАСЫН ЙОМГАКЛАУ (3 нче сыйныфта татар теле дәресе). Хөснетдинова Р.Р ............... 125

ИШЕТЕП АҢЛАУ АҢЛАУ ҺӘМ ҖАНЛЫ СӨЙЛӘМДӘ КАТНАШУ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ. Шәрифуллина А. М. ............... 132

СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ТҮГӘРӘК ЭШЕ. Фәттахова М.К. ............... 137

ИСЕМ ТЕМАСЫНА ЛИНГВИСТИК КРОСС (6нчы сыйныф, татар мәктәбе). Сөнгатуллина Г. Ф. ............... 145

НОВЫЕ ПОДХОДЫ В ОБУЧЕНИИ ДЕТЕЙ ДВУМ ГОСУДАРСТВЕННЫМ ЯЗЫКАМ. Кочеткова И.В. ............... 150

ЗАМАН ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ЙӨЗ ТОТЫП. Хәбибуллина Г. Ф. ............... 156

«Гыйлем юлы – бик кадерле юлдыр, лəкин бик мəшəкатьле һəм авырдыр. Шулай булса да, очы – бəхеткə, ахыры камиллеккə барып туктыйдыр»

Ризаэтдин Фəхретдинов

## КЕРЕШ СҮЗ

XX гасырның 80-90 нчы елларында илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә, шул исәптән татар телен укыту методикасы фәненә дә үзгәрешләр алып килде. Татар телен гамәлгә кую барышында аны укытуның юлларын, алым-чараларын төрлеләндерү, камилләштерү дә алга куелды. 1992 елның июлендә «Татарстан халыкларының телләре турында Закон» кабул ителеп, анда татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре буларак билгеләнде. Законда каралганча, татар теле рус теле белән берлектә Татарстан республикасының югары дәүләт хакимияте һәм идарә органнарында, дәүләт органнары, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары эшендә киң кулланылырга тиеш.

ТР Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе милли мәгарифне үстерү һәм «2014-2020 нче елларда Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» турындагы дәүләт программасын тормышка ашыруны үзенең төп максатларының берсе буларак билгеләп, нәтиҗәле эш алып бара. Максатка ирешү юлында түбәндәге бурычларны үтәүне күз алдында тота:

— милли мәгарифне үстерүнең матди-техник базасын баету;

— укучылар, ата-аналар, җәмгыять мәнфәгатьләрен искә алып төзелгән укыту программаларын үзләштерүнең сыйфатын үстерү;

— укучыларның шәхси мөмкинлекләрен искә алып, дәүләт стандартларына туры килерлек сыйфатлы белем бирү;

— заман таләпләренә җавап бирүче, көндәшлеккә

сәләтле шәхес тәрбияләү;

— заманча технологияләрне тирән үзләштереп, балаларның белемле, хезмәт сөючән, әдәпле булып үсүен тәэмин итү;

— рус телле укучыларның коммуникатив сәләтләрен камилләштерү;

— укучыларыбызда әхлакый сыйфатлар, милли үзаң тәрбияләү, башка милләт кешеләре белән уртак тел табып, тату яшәргә өйрәтү.

Бөгелмә – республикабызның бик борынгы шәһәрләреннән санала. Район һәм шәһәр белем бирү оешмаларында 15 тән артык милләт вәкиле укый, аларның 28,4% татар, 59, 3% рус, калганнары башка милләт балалары.

Бөгелмә шәһәрендә һәм районында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның 71%, татар милләтеннән булган укучыларның 31,6% туган телдә белем һәм тәрбия ала. Рус мәктәпләренең барысында да татар теле предмет буларак рус теле белән тигез күләмдә укытыла.

Башка милләтләрнең үз телләрен өйрәнүләренә дә игътибар ителә, якшәмбе мәктәпләре эшләп килә. Мисал өчен, мордва якшәмбе мәктәпләрендә укый торган укучылар республика күләмендәге олимпиадаларда даими рәвештә призлы урыннар яулыйлар.

Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән тулысынча тәэмин ителгән. Җәмгыятьтә тоткан урыны үзгәргән чорда, укытучы – мәгълүмат чыганагы гына түгел, ә укучыларның фикерләү сәләтен баетучы, уку, танып белү эшчәнлеген оештыручы, рухи һәм физик тәрбия бирүче дә ул. Бөгелмә муниципаль районында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәрвакыт яңалыкка омтылып, заман сулышын тоеп, белемнәрен өзлексез камилләштереп, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшлиләр, белемнәрен даими рәвештә мәгариф министрлыгы, мәгарифне үстерү институты һәм КФУ каршында оештырыл-

ган тьютор-экспертлар, Educare компаниясе укулары, универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, ФДББС шартларында инновацион технологияләр куллануга багышланган курсларда камилләштерәләр.

123 укытучыдан торган методик берләшмәнең төп максаты булып татар теле фәне, педагогика, психология, укыту методикасы буенча белемнәрне күтәрү, укытучының һөнәри компетентлыгын үстерү юнәлешендә эзлекле эш алып бару, җәмгыятьтә үз урын таба алырлык толерант укучы шәхесен тәрбияләү тора. Методик берләшмә үзенең эшчәнлеген җиде иҗади төркемгә бүленеп оештыра. Тәҗрибәле укытучылар җитәкчелегендә «Татар теле һәм әдәбияты дәресләренең сыйфатын камилләштерү», «Сәләтле балалар белән эш алымнары», «Рус телле балаларның актив сөйләм осталыгын һәм аралашу сәләтен формалаштыру», «Яңа әдәбият дәреслекләрен кулланып укыту үзенчәлекләре», «Бердәм республика тестларына әзерләнү» кебек темаларга семинар-практикумнар уздырыла.

Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне тоеп, инновацион укыту технологияләреннән урынлы файдаланып белем бирәләр. .Мәктәпләрдә заманча җиһазландырылган 98 татар теле һәм әдәбияты кабинеты эшли, аларда интерактив такталар урнаштырылган, һәр укытучының шәхси ноутбугы бар, интернет челтәрендә эшләү мөмкинлеге тудырылган.

Белем бирүнең Дәүләт стандарты нигезендә, татар телен һәм әдәбиятын укытканда, билгеле бер дидактик максатларны күз алдында тотып эшлиләр бөгелмәлеләр. Шуның белән беррәттән, заманча технологияләрне файдаланып, укучыларда стандартның үзәген – умыртка баганасын тәшкил итә торган өч төрле компетенция формалаштыру юнәлешендәге эшчәнлек тә уңышлы алып барыла. Укытучыларның эш тәҗрибәсен өйрәнү – аларның компетенцияләрнең татар мәктәбендә укучы өчен дә, рус мәктәбендә укучы татар баласы өчен дә, рус

телендә сөйләшүче башка милләт балалары өчен уртак булганнарын сайлап алып, шуларны үстерү юнәлешендә аеруча актив эшләүләрен билгеләп китәргә җирлек булып тора. Җыентыкта бирелгән дәрес эшкәртмәләре, нигездә, әлеге компетенцияләрне барлыкка китерү һәм үстерү юнәлешендә алып барылган эшчәнлекне чагылдыра. Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары коммуникатив яки аралашу, лингвистик, этнокультура компетенцияләрне тел өйрәтүдә аеруча мөһим булуын ассызыклыйлар. Мәгълүм булганча, коммуникатив компетенция – сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үзләштерүне, телне аралашуда төрле ситуацияләргә яраклы рәвештә өйрәтүне, телне аралашуда төрле ситуацияләргә яраклы рәвештә өйрәтүне, шуңа бәйле рәвештә укучыларның кызыксыну даирәсен һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алуны күздә тота. Лингвистик компетенция – телне иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак өйрәнүне, татар теленең төрки телләр арасында тоткан урынын, татар әдәби теле нормаларын үзләштерүне, укучыларның сүз байлыгын арттыру һәм алар сөйләмендәге грамматик формаларның төрлелеген тәэмин итүне бурыч итеп куя. Этномәдәни компетенция – телне милли мәдәниятнең чыганагы буларак күзаллауны, тел белән тарих бәйләнешен аңлауны, татар телен аның милли-мәдәни үзенчәлегенә төшенеп өйрәнүне, татарча сөйләмгә хас булган нормаларны үтәүне күз алдында тота.

Ана теле дәресләрендә укытучылар уку эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, тәнкыйди фикерләү, шәхескә якын килү, проблемалы укыту, коммуникатив технология һәм башка инновацион алымнарны уңышлы кулланалар. Укучыларга белем бирү процессын яңа укыту алымнары белән баету юнәлешендә алып барыла торган эшнең нәтиҗәсе булып, Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларының татар теленнән халыкара, республика күләмендә уздырылган олимпиадаларда яулаган призлы урыннары тора. Район

күләмендә үткәрелә торган конкурс-бәйгеләр, фәнни-гамәли конференцияләр иҗади эшләүче укытучыларның хезмәтләрен тиешенчә бәяләргә, педагогик-методик эшчәнлекләрен активлаштырырга мөмкинлек бирә. Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары республика күләмендә үткәрелеп килә торган күп төрле чараларда, педагогик укуларда, ана теле укытучыларның «Туган тел» мастер-класс конкурсында, татар теле һәм әдәбияты кабинетлары бәйгесендә уңышлы чыгыш ясыйлар. Соңгы елларда 23 укытучы «Иң яхшы укытучы» республика грантына лаек булган.

Фәнни эзләнүләр, уңышка ирешүләр юлында алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм уртаклашу, ачык дәресләр, мастер-класслар һәм сыйныфтан тыш чаралар, алдынгы укытучыларның иҗат лабораторияләре эше белән танышу, түгәрәк өстәлләр эш алымнарын камилләштерүгә ярдәм итә.

Йомгак ясап, Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының татар телен һәм әдәбиятын укытуда, кызыклы эзләнүләре, ирешелгән уңышлары, уртаклашырлык бай тәҗрибәләре булуны билгеләп китергә кирәк. Тәкъдим ителә торган җыентыктагы материаллар шуның ачык чагылышы булып тора.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Фәттахова М.К.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы Карабаш беренче гомуми урта белем бирү мәктәбенең директоры**

Хәзерге заман мәктәбе өчен шәхеснең иҗади мөмкинлеген үстерү, актив кеше тәрбияләү, укучыларның акыл эшчәнлеген һәм иҗади сәләтен үстерү беренчел булып тора. Бу бурычны мәктәп шәхескә юнәлтелгән технологияләрне кулланып кына хәл итә ала.

Мәгълүм булганча, Татарстанда рус һәм татар телләре тигез хокуклы дәүләт телләре. Татар теле – хөкүмәтнең, идарә органнарының халык белән аралашу, үзенең гражданнары белән сөйләшү теле, республикабызда инде ике дистә елдан артык вакыт эчендә дәүләт теле вазифасын башкара. Шуңа бәйле рәвештә, аны фән буларак укытуның юнәлешләре һәм эчтәлеге тамырдан үзгәрде. Татар теле татар һәм рус мәктәпләрендә белем алучы татар балаларына, рус телендә сөйләшүче төрле милләт укучыларына аерым программалар буенча өч юнәлештә алып барыла. Телгә өйрәтү традицион һәм яңа технологияләрне файдалануны күздә тота. Бу уңайдан безнең Карабаш беренче урта гомуми белем бирү мәктәбендә дә нәтиҗәле эшләр башкарыла. Белем бирүнең эчтәлеген яңартуга, сыйфатын күтәрүгә укытучыларыбыз нык игътибар бирә.

Мәктәптә укучыларның фәнни жәмгыяте 2005 нче елдан бирле эшли. «Фәнсөярләр» җәмгыятенең үз нигезләмәсе бар. Төп максатлар булып, фәннең, сәнгатьнең аерым өлкәләрендә белемнәрне камилләштерү, акыл эшчәнлеген үстерү, мәктәп укытучылары җитәкчелегендә фәнни эзләнү үткәрү, тәҗрибә эшчәнлеге күнекмәләре һәм осталыгы алу тора. Билгеле, укучының фәнни эше фәнгә яңалык өстәми, ул – аның үзе өчен генә яңалык. Укучыларның фәнни җәмгыятендә эшләү сәләтле укучыларның башка традицион эш формаларында – олимпиа-

даларда, бәйгеләрдә катнашуларына, укучының сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерүгә ярдәм итә. Мондый укучы китапларны күпләп укый башлый, төрле авторларның хезмәтләрен өйрәнеп чагыштыра, эзләнә, мәгълүмат туплый.

Аралашу чарасы буларак, телләрне яхшы белү – бүгенге көн таләбе. Ул мәктәптә яхшы белем алу ихтыяҗын үтәү өчен генә түгел, гасырның актив, иҗади, социаль яктан өлгергән шәхесне формалаштыру өчен дә кирәк. Галимнәр раслаганча, үсмерлек чорында иҗади фикерләү шактый зур үсеш ала. Укучыны мөстәкыйль уйлап эшләүне таләп иткән мәсьәләләр күбрәк кызыксындыра, аның күңеле иҗат итүне сорый башлый. Иң мөһиме шул: төрле иҗади эшләр белән шөгыльләнгән укучыларда дөньяга үз карашлары, оригиналь фикерләүләре формалаша. Эзләнү, логик фикер йөртә белү, нәни ачышлар ясарга омтылу – иҗади эшли белә торган шәхес әзерләүнең асылы булып тора. Шуларны исәпкә алып, без укучыларны фәнни эзләнү, тикшеренүләр белән шөгыльләнергә өйрәтү, танып-белү сәләтен, активлыгын, мөстәкыйльлеген үстерү юнәлешендә эш алып барбыз. Балаларның коммуникатив эшчәнлеген үстерү процессын интенсивлаштыру чараларына зур игътибар бирәбез. Моның бер ысулы – төбәк тарихын өйрәнү.

Эзләнү, тикшеренү эшен түбән сыйныфларда ук башласаң отышлы. Балаларга әти-әниләре дә, күрше-күлән дә бик теләп ярдәм итә. Алар өчен сораулык гади:

1. Үзең яшәгән урам атамасы (элек һәм хәзер).
2. Колхоз, совхоз исемнәре.
3. Чокыр, ерганак исемнәре.
4. Урман, агачлык, куаклык исемнәре.
5. Юл исемнәре.
6. Елга, чишмә, күл, сазлыклар исеме.

Өлкән сыйныфлар катлаулырак эш башкара. Мәсәлән, барлык төр ойконимнарның кайсы сүзгә нигезләнеп ясалганын; нәрсәгә нисбәтле булуын ачыклау һәм раслау өчен, тари-

хи-этимологик аспектта аларны махсус анализлау таләп ителәә. Профессор Г. Ф. Саттаровның «Мәктәптә туган як ономастикасы» дигән хезмәтенә нигезләнеп, укучыларга эш өчен әзер үрнәк бирәбез. Бөгелмә районы ойконимнары түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә аерыла:

1. Антропонимнарга нигезләнеп барлыкка килгән атамалар.

2. Гидронимнарга нигезләнеп ясалган атамалар.

3. Оронимик географик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар; чишмә сүзенә нисбәтле ясалган атамалар.

4. Урнашу урынына, теге яки бу физик һәм географик объектның кайсы урында урнашуына карап аталган исемнәр.

5. Туганлык терминына нигезләнгән атамалар.

Укучыларыбызның мавыгып эшләүләре безне дә иҗади эшкә дәртләндерде. Без, укытучылар һәм укучылар, Бөгелмә төбәге, Карабаш авылы тарихына бәйле исемнәр аша төбәк, авыл тарихын һәм андагы бәйләнешләрне ачыклау максатын күздә тотып, «Туган як ономастикасы» исемле иҗади проект төзедек. Проектның эчтәлеге балаларның кызыксынуын һәм иҗади фикерләү сәләтен арттыруга, фәнни гомумиләштерүләр аша нәтиҗәләр ясарга өйрәтүгә юнәлтелгән, анда предметара бәйләнешләргә дә (тарих, география, геология, биология) урын бирелгән.

**Проектның бурычлары:**

— сәләтле укучыларны ачыклау, аларны иҗади эшкә җәлеп итү;
— укучыда өйрәнә торган фән белән кызыксыну уяту;
— укучыларның интеллектуаль-иҗади эшчәнлеген популярлаштыру;
— танып белү активлыгын үстерү, иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
— төркемдә эшләү күнекмәләре булдыру;
— укучыларда милли үзаң формалаштыру.

**Эзләнү ысуллары:**

1. Укучыларның иҗади эзләнү эшчәнлеге өчен кирәк булган методик әдәбиятны өйрәнү.
2. Бөгелмә шәһәрендәге, Карабаш бистәсендәге туган якны өйрәнү музееның материаллары белән танышу.
3. Һәвәскәр тарихчылардан Асылов Солтан, Бикмурзина Энже, Сәйфиев Ильяс, Сәйфиев Гомәрләрнең истәлек дәфтәрләрен уку.
4. Тыл һәм сугыш ветераннары, аларның балалары белән очрашып, солдат хатларын барлау, гаилә архивларыннан Карабашлы Җәлилчеләр турында мәгълүмат туплау.
5. Төбәк ономастикасын өйрәнүгә караган әдәбият белән танышу (топонимика, антропотопонимика, антропонимика)
6. Җирле халыктан сорашып тупланган материалларны чагыштыру, гомумиләштерү, системалаштыру, анализлау.

## Проектны тормышка ашыру этаплары

**I этап – әзерлек эшләре.**

Проектны әзерләү процессында, өчәр укучыдан торган 5 төркем билгеләнә. Аларга түбәндәге эшләр йөкләнә.

**1. Тарихчылар төркеме**. «Еллар, язмышлар китабы» буенча Карабаш авылының тарихын, йолаларын, халык авыз иҗатын өйрәнү. Хөкүмәт бүләкләренә, мактаулы исемнәргә лаек булган авылдашларның биографияләре белән танышу.

**2. Социаль катламны өйрәнү төркеме**. Авыл кешеләре белән әңгәмәләр үткәрү, һәвәскәр тарихчыларның кулъязма, көндәлекләрен өйрәнү. Тупланган материалны гомумиләштерү, видеоматериаллар, фотосурәтләр булдыру.

**3. Экологик төркем**. Карабаш авылы елгасы, сулыклар, чишмәләрнең экологик хәлен, авылның табигать дөньясын тирәнтен өйрәнү.

**4. Компьютер графикасы төркеме**. Авылның күренекле

шәхесләренә багышланган белешмәләр базасын булдыру, «Сәйлән» газетасында мәкаләләр бастыру.

**5. Экскурсия үткәрүчеләр төркеме**. Карабаш авылының туган якны өйрәнү музеена, Һади Атласи исемендәге китапханә-музейга экскурсияләр оештыру.

**II этап – гамәли эшләр этабы.**

**III. Бәяләү этабы.**

Проектның нәтиҗәлелеген билгеләү, иҗади эзләнү эшчәнлеген җәелдерү буенча методик тәкъдимнәр туплау. Укучыларның «Эзләнү эшләре җыентыгы»н бастыру.

Әзерлек эшләре дәвамында укучылар архивта, китапханәләрдә эзләнү эшләре алып барды, авылдашлар белән кызыклы очрашуларда катнашты. Эш барышында аңлату, лекция, әңгәмә, төрле чыганаклар белән эшләү методларыннан уңышлы файдаланылды. Укучыларның һәркайсына ярдәм күрсәтелде. Гамәли дәресләрдә нәсел шәҗәрәләре төзелде, тупланган җирле ономастик материаллар билгеле бер системага салынды, анализланды.

Туган як тарихын өйрәнүгә багышланган рефератлар укучыларның фәнни-гамәли конференцясендә якланды («Карабаш авылы антропонимнары», «Бөек Ватан сугышында Карабаш авылы халкы һәм Карабашлы Җәлилчеләр», «Авылымның батыр уллары», «Бәширә шәҗәрәсе»). Әлеге юнәлештә тупланган тәҗрибә белән уртаклашу, уңышлы эш алымнары турында фикер алышу бистәбездә урнашкан ике мәктәп укучылары катнашында узган авылыбызның 285 еллык бәйрәм кичәсендә дәвам итте. Карабашның бай тарихлы төбәк булуын дәлилли торган, бүгенге көнгә кадәр беркайда да басылмаган, Санкт-Петербург архивыннан үзе эзләп тапкан язмалар турында сөйләгән филология фәннәре кандидаты Мәрдәнов Рәүф Фәтхулла улының чыгышы бу чараны тагын да нәтиҗәлерәк итте. Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты галимнәре катнашында узган региональ фәнни-гамәли конференциядә исә Карабаш һәм Бөгелмә районының

тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре турында укучыларыбыз да үз фикерләрен җиткерде. Карабашлы Җәлилчеләр истәлегенә бистәбездә һәйкәл торгызылган икән, димәк, укучыларыбызның монда да өлеше бар. Мондый чаралар һәркемне уйланырга мәҗбүр итә: ни өчен яшибез, ничек яшибез, ничек яшәргә тиешбез?

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ СӘЛӘТЛӘРЕН ҮСТЕРҮ ӨСТЕНДӘ ЭШ

**С.М. Хәмидуллина,**
**Бөгелмә шәһәре**

Рус телле балаларның тема буенча сүз байлыгын арттыру, сөйләм телен үстерү, шулай ук аларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү максатыннан IV сыйныфта Р.Хәйдәрова дәреслеге буенча үткәрелгән татар теле дәресендә дидактик материаллар, Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, Кызыл китап, аудио-, видеочаралар һ.б. файдаланылды. Дәрес алдыннан стендка укучылар өйдә ясап килгән урман күренеше рәсемнәре элеп куела.

Дәрес барышы.

I. Оештыру өлеше.

1. Дежур укучы белән әңгәмә.

2. Укучыларның игътибарын дәрескә туплау. (Бер укучының урманга баргач төшергән видеоязмасын карау.)

II. Актуальләштерү.

1. Фонетик күнегү. (Интерактив тактада [а], [ә], [ө] авазлары кергән сүзләр язылган: урман, матур, үләннәр, тынган, кергән, гөлҗимеш, сайрамый, төскә, сөйләде.)

— Укучылар, башта [а] авазы кергән сүзләрне генә укып чыгыгыз. (Укучылар сүзләрне табып әйтәләр, укытучы аларны беренче баганага яза бара. Аннан соң аларны ([ә], [ө] авазы кергән сүзләрне дә шулай ук) берничә укучы аерым-аерым дәрес итеп әйтә. Соңыннан бергәләп кабатлыйлар.)

— Бик яхшы. Әйдәгез, бу сүзләрнең русчага тәрҗемәсен искә төшерик. (Укучылар тәрҗемә итәләр.)

— Укучылар, бу сүзләр белән җөмләләр уйлап әйтегез. (Мин урманда булдым. Укытучы абый сөйләде. Чыпчык сайрамый. Абыем урманда матур куян күргән. Мин

урманны яратам һ.б..)

III. Өй эшен тикшерү. (Укучылар, үзләре ясап килгән урман рәсеменә карап, җөмләләр төзеп әйтәләр.)

IV. Яңа тема белән таныштыру.

1. Укучылар алдына максат кую.

— Балалар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез?

(Урман, көзге табигать турында.)

Алга таба яңа текст белән танышырбыз, аны тәрҗемә итәрбез, сорауларга җавап бирербез, хикәя төзеп карарбыз. Уйнап та алырбыз, шуңа күрә игътибарлы һәм актив булыгыз.

2. Текст (дәреслек) белән эш.

• Яңа сүзләр белән танышу: үзенчә – по-своему; тынган – притих; Кызыл китап – Красная книга.

(Красная книга сүзенең аңлатмасын сүзлектән карау.)

Красная (охранная) книга – международный реестр, в который заносятся сведения о подлежащих охране редких, исчезающих видов животных и растений. (С.И.Ожегов и Н.Ю.Шведова. Толковый словарь русского языка).

• Яңа сүзләр белән танышуны дәвам итү: рәхәт булды — было приятно; кызыл/кып-кызыл җимешле агач — ярко-красное плодоносное дерево; бу гөлҗимеш куагы — это куст шиповника; бик файдалы — очень полезно, полезный; таныш түгел — незнакомый, незнакомая, незнакомое.

• Сүзләрне укытучы укый.

• Укучылар бер-берсенә укыйлар.

• Сүзләрне сүзлек дәфтәренә язып куялар.

V. Текст белән танышу.

1. Текстны тыңлау.

— Тыңлагыз һәм нәрсә турында сүз баруын әйтегез. (Текст аудиоязмада диктор укуында яңгырый яки аны укытучы укый.)

— Кем аңлады: сүз нәрсә турында бара? (Җаваплар тыңлана.)

2. Текстны чылбырлап уку һәм тәрҗемә итү.

• Физкультминутка.

Без инде хәзер зурлар (кулларын өскә күтәрәләр),

Тиз эшли безнең куллар (бармаклар белән хәрәкәтләр ясыйлар).

Яшелчәләр алабыз (чүгәләп яшелчә алу хәрәкәте ясыйлар),

Кәрзиннәргә салабыз (кәрзингә салуны хәрәкәт белән күрсәтәләр).

Без инде хәзер зурлар,

Күп эшли безнең куллар (хәрәкәтләр кабатлана).

VI. Белем-күнекмәләрне ныгыту. (Төркемнәрдә эш.)

1. Төркемнәргә бүленү.

«Броун хәрәкәте». Укучылар ирекле рәвештә бүлмә буенча йөри. Укытучы: «Икешәрләп, молекула булып берләшегез!» — дигәч, алар парлашып баса. «Дүртәрләп берләшегез!»— дигәч, укучылыр дүртәр-дүртәр булып берләшә. Шул рәвешле класс төркемнәргә бүленә.

2. Биремне үтәү.

— Сейчас поработаем в группах. Класс делится на четыре группы: две группы задают вопросы по тексту, а две отвечают на них. (Укытучы сорауларны алдан кәгазьгә язып куя.)

1 нче төркемгә сораулар:

— Кайчан урман үзенчә матур?

— Агачлар нинди төскә кергән?

— Өрәңге нинди төстә?

2 нче төркемгә сораулар:

— Кемнәр экскурсиягә килгән?

— Юл буенда нәрсә үсә?

— Укучыларга кайда бик күңелле булды?

— Эшебез нәтиҗәле булсын өчен, без вазифаларны билгелик. Беренче утырган кеше — җитәкче булыр. Ул бөтен кешенең дә катнашуын тәэмин итә. Икенче кеше — докладчы — эш тәмамлангач чыгыш ясый. Өченче укучы

— рәссам — биремне плакат яки рәсем рәвешендә кәгазьгә төшерә. Дүртенчегез — хронометрист — вакытның әрәм ителмәвен тәэмин итүче. Бишенче укучы — нәфис сүз остасы — докладчы чыгышын башлаганчы, әсәрдән үзегезнең төркемгә тиешле бүлекне укый. (Биремне үтәүгә 5 минут бирелә.)

3. Төркемдә фикер алышу.

— Ә син көзге урманны яратасыңмы?

4. Җөмләләргә кем күбрәк сораулар куя ала?

Алсу апа укучыларга туган якның табигате турында сөйләде.

Бу урманда да Кызыл китапка кергән агачлар бар икән.

5. Сообщи о том что:

— вы в лесу собирали разные листья;

— в лесу было очень хорошо, интересно.

6. Убеди друга в том, что:

— в осеннем лесу очень красиво;

— надо собирать лекарственные травы;

— природу нужно беречь.

7. «Көзге урманга экскурсия» дигән хикәя төзеп сөйләү.

Файдалану өчен сүзләр һәм сүзтезмәләр: үзенчә матур, төрле төскә кергән, өрәңге, укучылар, Кызыл китап, табигать, сакларга.

VII. Дәрескә йомгак ясау. Билгеләр кую.

— Балалар, дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

— Нинди яңа сүзләр өйрәндек?

— Кызыл китап турында нәрсә белдегез?

— Туган як табигатен кем сакларга тиеш?

VIII. Өйгә эш: «Көзге табигатькә экскурсия» дигән 7-8 җөмләле хикәя төзеп язарга.

# СОВРЕМЕННЫЕ ПОДХОДЫ К ОБУЧЕНИЮ ШКОЛЬНИКОВ ГОСУДАРСТВЕННЫМ ЯЗЫКАМ

**Смирнова И. М., директор**
**МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4»**
**Бугульминского муниципального района РТ**

Школа целенаправленно работает по выполнению Закона РТ «О государственных языках РТ и других языках в РТ», по реализации Программы по сохранению, изучению и развитию языков. Татарский и русский языки как государственные языки изучаются в равных объемах в рамках федеральных государственных образовательных стандартов общего образования.

В школе созданы все условия для изучения государственных языков. Оборудовано 3 кабинета татарского языка и литературы и 2 кабинета русского языка и литературы, оформленные в национальном стиле, оснащенные современным оборудованием, информационно-коммуникативными средствами, мультимедийными пособиями, необходимыми учебно-методическими комплектами. Создана хорошая материальная и методическая база для организации учебно-воспитательного процесса для обучения государственным языкам.

В современных условиях социокультурного развития национальному образованию принадлежит ведущая роль в сохранении и формировании у подрастающего поколения национального самосознания. Обновление и развитие национального образования в нашей школе тесно связаны с ведущими концепциями, опираясь на которые целенаправленно строится педагогический процесс, осмысленно осуществляется подход к отбору содержания образования, к выбору дидактических средств и методов обучения, к организации учебной деятельности.

Учителя татарского языка и литературы прошли курсы по ФГОС (руководитель курса Р.З.Хайдарова) и наглядно убедились в эффективности системно-деятельностного подхода. Применяют сингапурские структуры обучения, используя

командные формы работы. В своей работе педагоги активно используют интернет – ресурсы в информационной системе «Электронного образования», в проектах «Ана теле», «Бала», «Әдипләр», «Кирилл и Мефодий», являются администраторами методических сообществ. Необходимым условием организации учебно-воспитательного процесса является применение информационных технологий, которые позволяют использовать готовые мультимедиа-уроки, тренажеры, тесты, презентации, обучающие игры. Применение на уроках аудио- и видеозаписей, мультфильмов, снятых по мотивам русских и татарских сказок, считается одним из успешных приемов в обучении. Данные ресурсы помогают детям вырасти в атмосфере национальных мотивов, учат детей уважать обычаи и традиции, чувствовать красоту родного языка.

Реализуя задачу по формированию национального самосознания учащихся в поликультурном пространстве, учителя татарского языка и литературы делают серьезный акцент на формирование и развитие навыков устной и письменной речи, привитие учащимся художественного вкуса, интереса и любви к татарскому языку; на обучение русскоязычной аудитории практическому использованию татарского языка как средства общения в пределах установленного программой словарного и грамматического минимумов, с применением здоровьесберегающих и коммуникативно-развивающих технологий. Преподавание татарского языка в русскоязычных классах по учебникам Р.З. Хайдаровой, Р.Р. Нигматуллиной дает возможность повышать практическую направленность уроков, развивать разговорную речь учащихся.

На уроках практикуются коммуникативная, ситуативная технологии, лингвистически ориентированная деятельность, проектная методика, которые дают учителю возможность включить учащихся в реальное общение, насыщенное иноязычными контактами, опирающиеся на исследовательскую деятельность, на совместный труд и увидеть реальные результаты своего труда.

Опыт своей работы педагоги обобщают, выступая на семинарах, участвуя в научно-практических конференциях, показывая открытые уроки, мастер-классы, размещая материалы на образовательных сайтах, в периодических изданиях.

Обучение татарскому языку в русскоязычной школе имеет свои особенности. Цели и задачи, поставленные в работе - это формирование первичных знаний, умений и навыков устной и письменной речи с опорой на коммуникативный подход к изучению татарского языка; включение обучающихся в диалог культур разных национальностей. В формировании активного мотивационного отношения русскоязычных школьников к изучению татарского языка исключительную роль играет развитие у них познавательного интереса на уроках, постепенное развитие ситуативного интереса к учебному предмету.

Формирование этнокультуры учащихся, приобщение их к культурным, образовательным, языковым традициям народов Республики Татарстан дает положительную динамику развития обучения и отражает целенаправленный, программный характер управления развитием национального образования в школе. В школе ведется систематическая работа по совершенствованию этнокультурного воспитания школьников.

В школе разработана программа по реализации национально-регионального компонента и программы по работе с одаренными детьми. На основе использования данных программ ученики знакомятся с известными деятелями культуры, науки, творчества, участвуют в поисковой деятельности информаций, исторических документов о земляках.

Классные руководители при составлении воспитательного плана учитывают самобытность и культуру каждой национальности и то, что семья является ведущим институтом сохранения и развития родного языка, разрабатывают тематику родительских собраний, классных часов, вечеров, с целью воспитания у детей уважения к традициям и культуре народов, живущих в Татарстане, пробуждение интереса к изучению истории родно-

го края. Внеклассная работа в классах с национальным воспитанием ведется на двух государственных языках. В школе создана воспитательная система, направленная на повышение интереса к изучению государственных языков, на развитие личности ребенка.

Таким образом, формирование языковой компетенции обучающихся в условиях погружения в языковую среду повышает уровень преподавания и уровень умений и навыков школьников, развивает их творческие способности.

# ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕНДӘ МЕТОДИК ХЕЗМӘТНЕ ОЕШТЫРУ

**Гайнуллина З.Җ.,**
**РТ Бөгелмә муниципаль районы Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясенең укыту эшләре буенча директор урынбасары**

Соңгы елларда мәктәп зур үзгәрешләр кичерде. Шул сәбәпле яңа гасыр баласы белән эшләү алымнары, укыту һәм тәрбия эшен оештыру да үзгәрешләр таләп итә. Укучыны мөстәкыйльлеккә өйрәтү генә җитми: ул үзенчә, үзгәчә фикер йөртергә, өлкәннәр кушканнан чыгып түгел, үз башы белән эш итә белергә, теләсә кайсы үзгәрешкә яраклаша алырга сәләтле булып җитлегергә тиеш. Болар барысы да укытучыга зур бурычлар йөкли. Безнең гимназия коллективы үз алдына югары әхлаклы шәхес тәрбияләү, укучыларга төпле белем бирү, аларның һәвәслеген, сәләтен искә алып, сәяси, социаль-икътисадый үзгәрешләр кичергән җәмгыятьтә яшәргә һәм эшләргә лаек шәхес тәрбияләү максатын куя.

Максатыбызны тормышка ашыру юнәлешендә, беренче чиратта, гимназиядә методик лабораториянең эшчәнлеген камилләштерү өстендә эш алып барабыз. Гимназия методик хезмәтенең төп максаты-- белем бирүнең сыйфатын яхшырту максатыннан, укытучыларның һөнәри, иҗади потенциалын үстерү, аларга үз белемнәрен камилләштерүгә шартлар тудыру. Укытуның сыйфатын күтәрү өчен укытучы ,үзенең һөнәри осталыгын үстерү өстендә эшләп, һәрвакыт һәм өзлексез үсештә булырга тиеш. Зур тизлекләр белән бара торган фән һәм техника үзгәрешләре алдында югалып калмастай, туган яңа теорияне практикада куллана белү өчен, укытучыга һәрвакыт белемнәрен тулыландырып, яңартып, төзәтмәләр кертеп, камилләштереп торырга кирәк. Хәзерге вакытта мәктәпләргә заман куйган бурычларны хәл итәрдәй, иҗади фикер йөртүче укытучылар кирәк. Ләкин мөгаллимне мәҗбүр иттерү мөмкин

түгел, шуңа күрә омтылыш уяту әһәмиятле. Методик хезмәтнең эш юнәлешләрен дә, педагогларның квалификациясен күтәрү моделен дә шушы максатлар билгели.

Укытучыларның квалификациясен күтәрүгә шартлар тудыру өчен, беренче чиратта, аларның мәнфәгатьләрен ачыклыйбыз һәм төрле уку модульләре тәкъдим итәбез. Шундыйлардан «БДИ га әзерлек технологияләре», «Укытучы эшчәнлегендә ИКТ куллану», «Укыту һәм тәрбия процессында системалы эшчәнлек аша яңа белем стандартларын тормышка ашыру», «Укучыларның фәнни тикшеренү эшчәнлеге белән идарә итү», «Индивидуаль һәм дифференциаль якын килү нигезендә шәхесне һәр яклап үстерү» кебекләрен мисал итеп алырга мөмкин. Укытучы, әлбәттә, үзенең һөнәри осталыгын күтәрүгә, иҗади үсешкә юнәлтелгән модельне сайлый, методист һәм тьюторлар ярдәмендә индивидуаль үсеш траекториясен билгели, бу модульдә эшләү өчен кулай эш формаларын таба. Укытучыларның күпчелеге иҗади төркемнәрдә эшли. Беренче чиратта методик әдәбиятны өйрәнү, фикерләр алышу, эш тәҗрибәсе белән уртаклашу тормышка ашырыла. Моннан тыш укытучылар педагогик укуларда, методик семинарларда, педагогик киңәшмә, методик берләшмә утырышларында катнаша. Мондый традицион эш төрләре белән беррәттән инновацион формалар да еш кулланыла: тренинг, түгәрәк өстәл артында сөйләшү, эшлекле уен, мастер-класс, проект эшләре әнә шундыйлардан санала.

Һәр мәктәптә яшәп килүче фән укытучыларының методик берләшмә эшчәнлеген оештыру үзенчәлекләренә аеруча зур игътибар итәбез. Эшчәнлек фән үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла. Һәр укытучының үз эш тәҗрибәсе, үзенә генә хас эш алымнары бар. Шуңа күрә укытучы, методик берләшмә эшчәнлегендә үз урынын табып, үз юлын күрә ала. Әлбәттә, бу берләшмә эшчәнлегенә уңай нәтиҗәләр бирә. Безнең гимназиядә, уку елы барышында, республика, шәһәр, мәктәп күләмендәге семинарлар еш үткәрелә. Укытучыларга эш тәҗрибәләре белән

уртаклашырга һәм төрле бәйгеләрдә катнашырга мөмкинлекләр ачыла. Методик берләшмә эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыру укытучыларга яңа технологияләр, укыту,методик әсбаплар сайлаудаарасында үз юлын табарга ярдәм итә. Гимназия күләмендә үзара дәресләргә йөрү практикасы да уңай нәтиҗәләр бирә.

Яңа белем бирү стандартларына күчү чорында урта һәм югары сыйныфларда эшләүче укытучылар, башлангыч сыйныфларның дәресләренә йөреп, яңа стандарт таләпләре белән якыннан таныштылар. Мондый эшнең нәтиҗәсе буларак, методик берләшмәләрдә эшчәнлекле һәм үстерелешле укыту методикасы буенча хәтерлекләр төзелде, яңа стандартларга туры килгән дәрес эшкәртмәләре әзерләнде.

Педагогик кадрларның квалификациясе, аларның хәзерге заман технологияләрен куллануга әзерлеге – белем бирүне заман таләпләренә туры китерүнең төп нигезе булып тора. Шуңа күрә дә бүгенге көндә электрон белем бирү тирәлеге мөмкинлекләрен актив кулланабыз. Укытучыларыбыз иҗади эшләүче педагоглар челтәрендә, төрле сайт һәм порталларда актив эшли, күпчелек укытучының интернет челтәрендә үз сайты яки блогы бар. Алар даими рәвештә методик материаллар, дәрес, сыйныфтан тыш чара эшкәртмәләре белән тулыландырып торалар. Моннан тыш укытучылар үз эшләрен nsportal.ru, videouroki.net, infourok, pedkopilka.ru, metodisty.ru h.б. сайтларында урнаштыра.

Укытучының иҗади лабораториясен булдыру өстендә эшчәнлек шулай ук педагогларның квалификациясен күтәрү моделенең бер формасы буларак алып барыла. Ул берничә этаптан тора. Беренчедән, укытучының норматив документлар, иҗади лабораториягә һәм кабинетларга таләпләрне өйрәнү этабы. Икенчедән, иң нәтиҗәле эш тәҗрибәсен өйрәнү мкаксатыннан гимназиядә ел саен үткәрелүче методик материаллар конкурсы. Конкурска һәр укытучы фән яки өстәмә белем бирү буенча эш программалары, дәрес эшкәртмәләре, тестлар, проектлар тәкъдим итә. Иң уңышлы дигәннәре гомуми кулланылышка кертелә, яки төрле бәйгеләрдә катнашуга тәкъдим ителә.

Укытучыларның һөнәри компетентлыгын күтәрүдә проект эшчәнлеге аерым урын тота. «Эколидер», «Красивая школа», «Туган тел», «Патриот», «Яшьтәш» кебек мәктәпкүләм социаль проектлар әзерләүдә гимназиянең һәр педагогы аерым урын тота., әлбәттә , аларның һөнәри осталыгын күтәрүдә бу эшнең әһәмияте бәхәссез.

Укытучының иҗади үсешенә китерүче шартларның тагын берсе--һөнәри конкурсларда катнашу. Мондый чараларга әзерлек укытучыда үзенә ышанганлык, үз-үзен күрсәтү, үзен раслау, үз планнарын тормышка ашыру юнәлешендә рухи мөмкинлекләрен үстерә. Безнең укытучылар арасында «Иң яхшы укытучы» муниципаль бәйгесе җиңүчеләре, «Ел укытучысы» республика конкурсы лауреатлары, «За образцовое владение русским языком в профессиональной деятельности», «Рус теле укытучыларының мастер класс бәйгесе» бөтенроссия конкурсы җиңүчеләре, «Иң яхшы заманча дәрес», «Белем бирү эшчәнлегендә ИКТ куллану» республикакүләм конкурсы, «Ачык дәрес» халыкара конкурсы призерлары, «Мәгариф» илкүләм өстенлекле проекты кысаларында «Белем бирү учреждениеләренең иң яхшы укытучылары» конкурсы җиңүчеләре дә бар.

Укытучының педагогик осталыгын һәм белем сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән методик хезмәт эшчәнлеге укыту-тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген бирде. Инде ике ел рәттән эш күрсәткечләре буенча безнең гимназия «Татарстанның иң яхшы 100 мәктәбе» исемлегенә, 2013-2014 ел нәтиҗәләре буенча Рәсәй Федерациясенең иң яхшы белем бирү учреждениеләре милли реестрына кертелде.

# СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

**Зәйнуллина Ф.В.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**икенче лицейның укыту эшләре һәм**
**милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары**

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы алдында һәрвакыт укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү бурычы тора. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә белем бирү процессы укытучы алдына шәхси фикере, идеяләре булган, фантазияле, иҗади сәләтле, эшлекле укучылар әзерләүне күз алдында тота.

Заман бездән, укытучылардан, баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес буларак тәрбияләүне таләп итә. Укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачу иң төп, мөгаен, иң авыр мәсьәләләрнең берседер.

Сәләтле баланы эзләп табуны, ачыклауны, аңа теләктәшлек күрсәтүне лицей укытучылары «Сәләтле бала» программасы нигезендә алып бара. «Сәләтле балалар банкы» булдырылды, ул ел саен тулыландырыла.

Сәләтле балалар белән эшләүнең төп юнәлешләре түбәндәгеләр: укучыларны фән буенча олимпиадаларга әзерләү, фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләнү һәм чыгыш ясау, төрле конкурсларда һәм интеллектуаль уеннарда катнашу.

Сәләтле балалар белән эш формалары ул – дәресләр, өстәмә белем бирү студияләре һәм түгәрәкләре, класстан тыш үткәрелә торган чаралар. Олимпиадалар уздыру – укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен активлаштырырга, талантлы балаларны ачыкларга мөмкинлек бирә, белем туплау белән кызыксынуны арттыра. Октябрь аенда мәктәп күләмендә фән буенча олимпиадалар үтә. Анда 5-11 нче сыйныф укучылары катнаша. Укучыларыбыз, республика күләм олимпиадаларның муниципаль турында җиңү яулап, республика турында да нәтиҗәле чыгыш ясыйлар (Камалтдинова А., Федорова Е., Мусина Л.,

Галиев Ә., Хафизов И., Котлова А.). Болардан тыш башлангыч сыйныф укучылары Россия Федерациясе һәм чит ил укучылары өчен үткәрелә торган «Татар теле инфо» халыкара дистанцион, «Йомшак керпе 2014», «Белмәмеш сораулары» онлайн; югары сыйныф укучылары татар теле буенча Халыкара һәм КФУ үткәргән олимпиадаларда актив катнашып, дипломнарга ия булдылар (Кулагина Е., Федорова А., Андреянов В., Мусина Л., Лисица Я., Зяблова М., Сафин Д., Гараев А. ). Тел гыйлеме буенча «Зирәк тиен» россиякүләм конкурс-уенында катнашу да традициягә әйләнде (Манченко К., Синегаева К., Шитенков В.). «Эврика» (4 нче сыйныфлар өчен) төбәкара интеллектуаль-иҗади марафонында да безнең укучылар беренче булды.

Өстәмә белем бирү системасы аша да сәләтнең үсеше өчен шартлар тудырыла. Лицейда «Илһам» театр студиясе, музыка студиясе һәм төрле түгәрәкләр уңышлы эшли. Аларда шөгыльләнгән укучылар республика, төбәкара һәм муниципаль конкурсларда ел саен призлы урыннар яулый. «Калфаклы сандугач», Шәүкәт Биктимеров исемендәге театр сәнгатенең II республикакүләм, «Әниләрне олыларга онытмыйк» төбәкара, «Туган телем - серле тел» республикакүләм, «Күңелләрдә Тукай сүзләре» шигырь укучылар конкурсларында яуланган дипломнар боларга дәлил. «Чал тарихтан ал сабак», «Киләчәккә билет» исемле иҗади эшләр конкурсы һәм «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе сәләтле укучыларыбызны республика күләмендә танытты. Сыйныфтан тыш үткәрелә торган чаралардан «Сабантуй» милли бәйрәме, «Яз алиһәсе», «Егет солтаны» бәйгеләре, «Мин татарча сөйләшәм» республикакүләм акциясе, «Туган тел көне» кичәләрен үткәрү традициягә әверелде.

Укучыларның табигый сәләтен үстерү, иҗат эшенә кызыксыну уяту эше лицейда өч төрле юнәлештә алып барыла. Беренче юнәлеш ул – дәрес вакытында укучыларда мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыру, өстәмә әдәбият белән эшләргә өйрәтүне күздә тота. Безнең мәктәп профильле уку йорты булганга, татар теле һәм әдәбияты укытуда функциональ программа

кабул ителгән. Бу программа нигезендә дәресләрдә укучыларга Татарстанда фән үсеше тарихы турында, татар галимнәре, физиклары, математиклары турында өстәмә мәгълүматлар бирелә.

Икенче юнәлеш ул – укучыларның «Эврика» фәнни җәмгыяте эшчәнлеге. Җәмгыять лингвистик, физика - математика, химия – экология – биология, техник иҗат һәм башка секцияләрне үз эченә туплый. Алар төрле түгәрәкләрне, факультатив, махсус һәм электив курсларны үз эченә ала. Лингвистик секция рус, инглиз һәм татар теле буенча түгәрәкләрне берләштерә. Татар теле буенча «Кызыклы грамматика», «Лингвиния иленә сәяхәт», «Мин Тукай телендә сөйләшәм», «Шүрәледә кунакта», «Туган як» кебек түгәрәкләр эшләп килә. Бу түгәрәкләрдә укучыларның тел, әдәбият, туган төбәгебез турында мәгълүматлары тирәнәйтелә; аңлау, фикерләү сәләтләре үстерелә; туган илгә, туган телгә хөрмәт хисе тәрбияләнә.

Дәресләрдән соң югары сыйныф укучылары өчен 2 нче лицейның профиленә яраклы рәвештә «Фән һәм техника», «Физика һәм математика терминнарын татар телендә өйрәнү», «Татар физиклары һәм математиклары» исемле махсус һәм электив курслар уздырыла. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә фәнни эзләнүләр башлана. Электрон һәм басма сүзлекләр, энциклопедияләр белән эш укуның сыйфатын күтәрергә, иҗади һәм мөстәкыйль фикерләү тәрбияләүгә ярдәм итә.

Махсус курсларда татар халкының авыз иҗатын, традицияләрен, тарихын, күренекле шәхесләрен өйрәнү дә күздә тотыла. Бу дәресләрдә иҗади шәхес тәрбияләү генә түгел, ә ватанпәрвәр шәхес тәрбияләү дә максат итеп куела. Бүгенге тормышта андый шәхес тәрбияләү бик авыр. Моның өчен тарихны һәм тарихтан ватандар кешеләрне белергә һәм аларны үрнәк итеп алырга кирәк. Шуңа күрә лицей укытучылары укыту һәм тәрбия эшендә тематик уеннарны, милләтнең чал тарихлы рухи хәзинәсен, халык авыз иҗатын оста файдаланып, укучыларга бәет-мөнәҗәтләр аша халыкның күңел матурлыгын

җиткерә. Шәһәребезнең «Мирас» фольклор төркеме мәктәптә кунакта еш була, бу укыту һәм тәрбия эшендә халык педагогикасын кулланып эшләүнең бер алымы. Чын гыйлемле бала ул – югары әхлаклы бала. Әхлакый яктан күркәм бала гына туган телен камил белә, тырышып иҗат итә, туган халкы белән горурлана, шуңа күрә әхлаклы шәхес тәрбияләү – төп максатыбыз.

Түгәрәк, махсус һәм электив курсларда алган белемнәр һәм тупланган материаллар соңыннан эшкәртелә, классификацияләнә һәм кайсы да булса фәнни тикшеренү эшенә нигез итеп алына. Алай гына да түгел, алган белемнәре укучыларны татар теле һәм әдәбияты буенча уздырылган фәнни тикшеренү конференцияләрендә катнашырга һәм призлы урыннар алырга ярдәм итә. Укучылар арасында ел саен үткәрелә торган «Ачыш» дип аталган фәнни-гамәли конференциядә аларның фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә нәтиҗә ясала, уңышлы эшләр төбәкара, республика конкурсларына тәкъдим ителә. Укучыларның «Шәҗәрәләр – нәсел агачы», «Укучылар – XXI гасыр фәненә» төбәкара, К. Насыйри, Муса Җәлил, Фатыйх Кәрим, Фатыйх Әмирхан, Туфан Миңнуллин исемендәге, «Г. Тукайның иҗади дөньясына заманча караш» «Без яшь, без сәләтле...», «Яшьләр фәнни эзләнүдә» Республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм башка бәйгеләрдә укучыларыбыз призлы урыннар яулады. Шәһәр, төбәкара һәм республика бәйгеләрендә яулаган грамота һәм төрле дәрәҗәдәге дипломнар укучыларыбызны тагын да җиңүләргә канатландыра.

Лицей укучылары «Сәләт» республикакүләм балалар лагере белән дә тыгыз бәйләнештә яши. Биредә төрле өлкәләрдә сәләтле булган балалар җыела: кемдер – фәндә, кемдер сәнгатьтә көчле. Берничә ел рәттән инде укучыларыбыз «Сәләт» мәктәбен үтә, биредә үз идеяләрен камилләштерә һәм тормышка ашыра, математика, физика, информатика, журналистика, ораторлык сәнгате һәм башка өлкәләрдә белем ала, тәҗрибә туплый. «Сәләт» мәктәбен үткән укучыларыбыз үзләре дә төрле интеллектуаль уеннар оештыра. Күптән түгел мәктәп командасы,

«Сәләт» оешмасының 20 еллыгына багышланган «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» интеллектуаль турнирында катнашып, уңышлы чыгыш ясады.

Соңгы елларда татар телен һәм әдәбиятын укытуда тагын бер өстенлекле юнәлеш аерып чыгарыла. Бу – мәктәпнең балалар бакчасы белән бәйләнеше. Хәзерге вакытта балалар бакчаларындагы тәрбия эшенә дә зур игътибар бирелә. Балалар бакчасында тәрбияләнгән бала мәктәпкә килгәндә, нинди әзерлек белән килергә тиеш дигән проблемалы сорау куела. Бу юнәлеш мәктәп һәм балалар бакчасы бәйләнешен күздә тота. Лицей укытучылары ел саен 6 нчы балалар бакчасы белән әлеге юнәлешнең эш планын төзи. Шул план нигезендә уку елы агымында бергә педсоветлар, төрле семинарлар, очрашулар, бакча тәрбиячеләре өчен ачык дәресләр, төрле тәрбия чаралары үткәрелә. Болай эшләү мәктәпкә укырга килүче балаларның әзерлек дәрәҗәсен алдан белеп торырга, ә инде тәрбиячеләргә балалардан мәктәп нәрсә таләп итәчәген төгәл күзалларга ярдәм итә. Сәләтле балалар да алдан ук ачыклана.

Лицейның татар теле укытучылары, эзләнеп, яңалыкка тартылып, алга омтылып эшли. Сәләтле балалар – безнең байлык, тик аларның сәләтен вакытында ача белергә генә кирәк. Аларга ялкынлы илһам, сүнмәс дәрт, якты ышаныч өстәп торыйк!

# ТЕЛЕ БАРНЫҢ ЮЛЫ БАР

**Хафизова Р.Ә.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы МБГББУ**
**аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче**
**6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**

Укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрүнең төп шарты – мәктәптә системалы методик эшне оештыру. Бүгенге көндә, яңа методик алымнарны, технологияләрне, рациональ һәм зур тизлек белән үз эшеңдә куллану кирәк чорда, методик эшнең әһәмияте аеруча арта. Педагогик коллектив «Татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирү процессына заманча технологияләрне кертүнең уңай яклары» – дигән проблеманы ачу өстендә өченче елын эшли. Бүгенге көндә укыту методикасының мөҺим бурычы – информацион технологияләрдән нәтиҗәле файдалану. Компьютерны урынлы куллану аша укыту сыйфатын күтәрүгә ирешү – аның иң өстенлекле ягы. Һәр укытучы үзе сайлаган тема буенча фәнни әдәбият өйрәнә, үз предметы өчен куллана һәм тарату өстендә эш алып бара.

Дәреснең формасы һәм оештыру методикасын камилләштерүгә аеруча зур әһәмият бирелә. Укытучылар тәҗрибә уртаклашуга, хезмәттәшләре фикеренә уңай карыйлар. Белем бирүне информатизацияләү һәм фәннәрне укытуда информацион технологияләр куллану эше дәвам итә. Укучыларның актив, аңлап эшләвен тәэмин итү чарасы буларак Э.А.Ситдикова, Г.М.Нәдершина, А.А. Газалиева, Р.Ә.Хафизова, Р.М.Кыямова компьютерны дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда отышлы кулланалар. Татар теле кабинетларында электрон кулланмаларны дискка күчереп, кабинетларда күргәзмәлелекне баету эше дәвам итә. Мультимедияле презентация-дәрес материалын күзаллауның иң отышлы формасы. Дәресләр һәм класстан тыш чаралар өчен

узган уку елында күп кенә мультимедияле презентацияләр эшләнде. Принтер ярдәмендә слайд һәм буклетларны кәгазьгә күчереп куллану да уку материалын аңлаешлы итә, күп вакытны янга калдыра. Бу алымнан А.Р.Хәева, А.Ф.Рәхмәтуллина, Л.А.Йосыпова, Э.Ф. Гыйльметдинова уңышлы файдаланалар.

Укытуның сыйфатын күтәрү өчен укытучы үзенең һөнәри осталыгын үстерү өстендә эшләп, һәрвакыт һәм өзлексез үсештә булырга тиеш. Зур тизлекләр белән бара торган фән һәм техника үзгәрешләре алдында югалып калмастай, туган яңа теорияне практикада куллана белү өчен, укытучыга һәрвакыт белемнәрен тулыландырып, яңартып, төзәтмәләр кертеп, камилләштереп торырга кирәк. Хәзерге вакытта мәктәпләргә заман куйган бурычларны хәл итәрдәй, иҗади фикер йөртә алырдай укытучылар аеруча кирәк. Ләкин мөгаллимне мәҗбүр иттерү мөмкин түгел, шуңа күрә омтылыш уяту әһәмиятле. Бу юнәлештә укытучыларның методик берләшмәсе зур этәргеч булып тора. Методик берләшмә эшчәнлеген нәтиҗәле итеп оештыру - укытучыларга яңа технологияләр, укыту – методик әсбаплар арасында үз юлын табарга ярдәм итә. Укытучыларның методик берләшмәсе – ул мәктәп эшчәнлегенең бер тармагы, укытучыларның традицион оешмасы.

«Сыйфатлы белем – конкурентлыкка сәләтлелекнең нигезе» дигән исем астында уку елын башлап җибәрәбез. Белем бирүнең сыйфатын яхшырту максатыннан, укытучыларның һөнәри, иҗади потенциалын үстерү, аларга үз белемнәрен камилләштерүгә шартлар тудыру идеясе ассызыклана. Һәр укытучының үз эш тәҗрибәсе, үзенә генә хас эш алымнары бар. Шуңа күрә укытучы методик берләшмә эшчәнлегендә үз урынын табып, үз юлын күрә алса, берләшмә эшчәнлегенә уңай нәтиҗә биреп була.

Сәләтле балаларны үстерү, барлау максатыннан ел саен татар теле һәм әдәбияты буенча уздырыла торган олимпиадаларда катнашабыз. Олимпиадаларның муниципаль турында

ел саен Р.Ә. Хафизова, Р.М.Кыямова, Л.А.Йосыповаларның укучылары җиңүче була. Соңгы өч елда Әхмәдишин Ильяс, Әбелхәерова Алия, Гөлкәева Розалия, Бакирова Айгөл, Рагимова Лолалар 1нче урынны яуладылар. Шулар арасыннан Гөлкәева Розалия (2013нче ел), Бакирова Айгөл (2015нче ел) республикакүләм олимпиадада призер булдылар.

Мәктәпнең Интернетка тоташкан булуы да мәгълүмати ресурслар санын арттыра. Интернет торган саен укыту-тәрбия эшчәнлегендә файдалана алырлык мөмкинлекләргә ия була бара. Педсоветта, методик берләшмә утырышларында: «Укыту - тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүдә Интернет мәгълүматлар», «Компьютер һәм аның мөмкинлекләре», «Интернет һәм электрон почтаны файдалану» – дигән темалар буенча эшлекле сөйләшүләр үткәрелә.

Edy.tatar.ru сайтында берләшмәләргә, ЦОРларга керәбез, электрон почта аша коллегалар белән аралашабыз, тәҗрибә уртаклашабыз. Укучылар татар теленнән КДУ оештырган Интернет-олимпиадада, халыкара һәм ТатартТелеИнфо олимпиадаларында Э.А.Ситдикова, Р.Ә.Хафизова, Р.М.Кыямова, А.А.Газалиева, Г.М.Нәдершина, Г.Х.Сафинаның укучылары читтән торып катнаштылар. ТатарТелеИнфо сайтының «Белем сандыгы« бүлегендә Р.Ә.Хафизова, Р.М.Кыямова, А.А.Газалиева, Э.А.Ситдиковаларның эшләре басылды. Шул ук сайтның «Илһам килгән чакта....» конкурсына укучыларыбыз бик теләп эш җибәрделәр. (А.Гибадуллина, Э.Урманчева, А.Хафизова, Э.Ситдикованың эшләре җибәрелде.). nsportal.ru сайтына укучыларның иҗади эшләре (Сибгатуллина Р. »Туган җирем» шигыре, Гыйләҗева А. «Хәтердә ул көннәр» темасына инша; укытучы: Р.М.Кыямова), Р.Ә.Хафизованың дәрес план-конспекты «Талантлы шагыйрь + бөек кеше = Хәсән Туфан» басылды.

Укучыларыбыз төрле конкурсларда теләп катнашалар. Республикакүләм «Туган телем – серле тел» шигырь бәйгесендә 11 укучы катнашып, Самойлов И. (3нче сыйныф,

укытучы: Р.М.Кыямова), Моргачева А.(2нче сыйныф), КузнецоваТ. (3нче сыйныф, укытучы: А.Р.Хәева) дипломнарга лаек булдылар. Ел саен уздырыла торган «Зирәк тиен» бәйгесендә дә укучыларыбыз көч сынаша. Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, ветераннарга хат яздык, герой Газинур Гафиатуллинның улы - Әнвәр абый белән очраштык, район сочинениеләр конкурсында катнаштык. Мәктәбебездә балаларның да, ата-аналарның да сәләтен, мөмкинлеген кызыксынуын искә алып, һәртөрле чаралар үткәрелә. «21нче февраль – халыкара туган тел көне», «Аларның исеме мәңгелек» (герой шагыйрьләр, язучылар турында), «Г.Тукай безнең йөрәкләрдә», «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый», «Юбиляр әдипләр» шуның ачык мисалы.

Хәзерге укытучы югары культуралы, әхлаклы, фидакарь, яңалыкка омтылучан, алга карап эш итүче, яшь буынны киләчәк тормышка әзерли белүче, һәр эшкә иҗади якын килүче, актив, таләпчән, ярдәмче булырга тиеш. Безнең укытучыларыбыз да үзләренең эш тәҗрибәсе белән һәрдаим уртаклашалар. Эшләре газета-журнал битләрендә, төрле сайтларда бастырыла. Р.А.Хафизова һәм Р.М.Киямованың рус мәктәпләрендә укучы татар балалары һәм ата-аналары өчен «Әлифбада кунакта» дигән ярдәмлек, 4нче сыйныф укучылары өчен тестлар, «Яңа технологияләр кулланып үткәрелгән дәрес эшкәртмәләре» китаплары басылып, кулланылышка керде. «Ачык дәрес» газетасында Р.М. Кыямова, Р.Ә.Хафизова, А.Ф.Рәхмәтуллина, А.Р.Хәеваның дәрес эшкәртмәләре басылып чыкты. «Бөгелмә авазы» газетасында «Ана йөрәге» (Р.Ә Хафизова) мәкаләсен күпләр яратып укыды. «Гамил Афзал укулары» дигән III республика педагогик укуларында Р.Ә.Хафизова – I урын, Р.М. Кыямова җиңүче булдылар. Сыйныф җитәкчесе булып эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары классларында «21нче февраль – халыкара туган тел көне», »Туган җирем – Татарстан», «Бөгелмә – туган ягым», «Мин татарча сөйләшәм» темасына ачык класс сәгатьләре үткәрәләр.

Укыту-тәрбиядә яңа нәтиҗәле алымнар, яңа

технологияләр кулланып, балаларга тирәнтен белем бирү - безнең төп бурыч. Мәктәбебездә татар телен үстерү юлында күп эшләр башкарыла. Татар балалары үз туган телләрендә яхшы итеп сөйләшә белсәләр, башка милләт балалары татар телендә аралаша алса, димәк безнең эш нәтиҗәле.

# ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ТОРМЫШЫН ҺӘМ ИҖАТЫН МӘКТӘПТӘ УКЫТУ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

**Хафизова Р.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче**
**6нчы урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Гамил Афзалның тормышы һәм иҗаты тәрбияви әһәмияткә ия.Бу тема бүгенге көндә дә актуаль, чөнки тәрбия темасы шагыйрьләрне генә түгел, һәр ата-ананы, җәмгыятьне дә уйландыра, борчый торган мәсьәлә. Безнең киләчәгебез кем кулында? Ул өметлеме? Гаиләдән килгән тәрбия бүгенге көндә ныклымы? Яшьләр бу болгавыр заманда үз урыннарын таба алырлармы? Менә шушы сораулар кешеләрне,шул исәптән мине дә, борчый.

Гамил Афзал иҗатын өйрәнүгә 11нче сыйныфта 1 сәгать кенә бирелә. Аның иҗаты белән тулырак танышу, тәрбияви әһәмиятен укучыларга тирәнрәк аңлату максатыннан чыгып,мин сыйныфтан тыш укуга да бер сәгать алам.Өй эше итеп Гамил Афзалның биографиясен укырга кушам. Дәрескә килгәндә, укучылар аның тормыш юлы һәм иҗаты белән хәбәрдар булалар. Дәресне кызыклырак, үзенчәлеклерәк итү өчен һәм шагыйрьнең иҗатын үзем дә яратканга күрә укучыларга түбәндәге таблицаны күрсәтәм.

| | | |
|---|---|---|
| Сыналу | Көч | Бүләк «Бүләк» |

Укучыларга мондый сорау бирәм:

— Гамил Афзалның тормыш һәм иҗаты буенча сез бу таблицага карап нәрсәләр әйтә аласыз?Сыналуга нәрсәләр керә?

Укучылардан көтелгән җаваплар:

— Туган авылыннан гаиләләре белән чыгып китәргә мәҗбүр итәләр.

— Авырып укуын ташлый.

— 1954нче елда, ягъни 33яшендә ll группа инвалид дигән язу ала.

— Укучыларга бу өлештә мин өстәмәләр кертәм:

— Язмыш аны 3яшеннән сыный башлый, шушы яшендә ул әнисез кала.

— 10яшендә туган авылыннан, балачак дусларыннан аерыла.

— 1959нчы елда 2көнгә генә туган авылына кайтып китә һәм гомере буе якты хатирәләр генә саклап, аны сагынып яши. Туган ягы турында шигырьләр яза.

Оныттылар, диеп үпкәләмә,
Карурманнар үскән илләрдә
Сине сагынып җаннар өзгәләнә
Айлы әкият кебек төннәрдә.

Икенче таблица «Көч» дип атала. Монданиләр әйтә алабыз?

Укучылардан көтелгән җаваплар:

— Авырып китүенә карамастан, язучылык дәртен сүндерми,иҗат итә.

— Магнитогорск шәһәрендә яшәсә дә, туган телен онытмый, татар телендә шигырьләр яза башлый.

— Үзлегеннән укый, тормыш университетын тәмамлый.

Укучыларның җавапларына өстәмә мәгълүматлар бирәм:

Гамил Афзалда мин нәселдән килә торган көч тә бар дип әйтер идем.Бабасы Афзалетдин бик саран, каты куллы, бай кеше була. Ул үз көче, тырышлыгы, үз хезмәте белән баый. 5 ел буе әрәмәлектән тал кисеп, чуманнар үреп сата, кибет ача.Ә тагын биш елдан ике катлы, алтыпочмаклы йорт сала, тегермәннәр төзетә. Үҗәтләнеп тормыш көтә.Мондый үҗәтлек, түземлелек Гамил Афзалда да күренә. Авырып, апасы янына кайтканнан соң, ул чиргә бирешми, яшәргә үзендә көч таба, әҗәлне җиңүгә

ирешә. Үлем белән көрәштә аңа сөргеннәрдән чыныгып кайткан көр һәм хөр рухы, ана сөте белән кереп калган ихлас мәхәббәте һәм киләчәккә өмете, ышанычы ярдәмгә килә:

Болыннарда ромашкалар үсәрләр,
Кашкарыйлар үсәр, көтәрмен.
Шул гөлләргә бер талпынгач,
Бер талпынгач,
Торып китәрмен!

Әйе, ул торып китә. Гамил Афзал көчле кеше. Аның көчлелеге тагын шунда күренә.

1949нчы елда 220шигырь тупланган китабын тотып, шагыйрь булырга, Казанның Матбугат йортына килә. Ишектән-ишеккә йөреп, 10-17шәр шигырь укый, ләкин аны хуплаучы булмый. Шагыйрь үзе бу турыда:

— Бетте эш, сынды кылыч, дип уйлаган идем, эш бетмәгән, кылыч сынмаган икән әле. Болай гына китү ярамый, егетлек түгел. Син хаклы икәнеңне эш белән исбат ит, ишекләрен шап итеп яп, дөньяны шаккатыр, югалтасы даннарың юк, тагын бер талпынып кара! Мин , усалланып, зәһәрле елмаеп, курыкмый тарткалашырга тотындым. Тешне кысып, җан ачысы белəнтарткалашканда, миңа ярдәмгә килделәр.1955нче елның көзендә »Совет әдәбияты» битләрендә берьюлы тугыз шигырем басылып чыкты. Мин иркен сулап куйдым, чыгып барган җан кире кереп, дөньяга ун тырнагы белән ябышты. Мин терелә башладым, йөри башладым.Инде иркенләп елый-елый, көлә-көлә язарга тотындым, көн-төн.

Бөгелмәдем
Бирелмәдем чиргә.
Моңын җиңеп кайгы сагышның,
Тешем кысып,
Шушы туган җиргә
Ун тырнагым белән ябыштым.
-дип яза.

Әдәбиятка килергә аңа Афзал Шамов һәм Сибгат Хәким кул сузалар, тартып алалар, капка ачалар, хәерле юл телиләр. Куллары җиңел була, Гамил Афзал танылган халык шагыйренә әйләнә.

Күргәнебезчә, Гамил ага көчле шәхес. Ул яшәү көчен каян алган соң? Нәтиҗә ясыйк әле.

Көтелгән җаваплар:

— Афзалетдин карттан, нәселеннән

— Туган авылыннан

— Ана теленнән

— Габдулла Тукай һәм Шәехзадә Бабич шигырьләреннән

— Башкортстанның Шәрип авылының ямьле табигатеннән

— Нәфисәнең мәхәббәтеннән

— Кызлары,кияүләре, оныкларыннан

— Замандашлары, дусларының җылысын тоюдан.

— Өченче таблицада кайсы бүләкне калдырырбыз. Гамил Афзал кайсы бүләккә лаек?

Көтелгән җавап: Беренче бүләк.

Аның иң зур бүләге – ул халык шагыйре. Тормыш сынауларын үткәндә, сыгылмыйча, теләсә нинди шартларда да (тормыш сиңа власть,акча, авырлык бирә) син кеше булып калсаң, үзеңне-үзең югалтмасаң, язмыш сине бүләкли. Үлгәннән соң да яшәү үзе бүләк түгелме? Талантлы шагыйрьнең иҗатын ничә еллар буе өйрәнү – ул бит бездән бүләк.

Укучылар белән «Өф-өф итеп» шигыренең темасын, идеясын билгелибез.Дөрес тәрбия бирмәү нәтиҗәсендә, бәхетшатлык китерергә тиешле баланың әрәмтамак, җилкуар, ата-анасына да җәмгыяťкә дә, файдасыз бер бәндә булып үсүен балалар аңлыйлар.Моның сәбәбе булып баланы «өф-өф итеп», иркәләп үстерү, ягъни халыкның борынгыдан килгән тәрбия чараларын санга сукмау тора.Мондый яшьләр, кызганычка каршы, безнең арабызда да бар.

Ә укучылар үзләренең бүгенге көндә конкурентлыкка

сәләтле яшьләр булуларын дәлилләргә тырыштылар.Гамил Афзалның шигыренә җавап-шигырь яздылар,шигырьнең эчтәлегенә туры китереп рәсем ясадылар.

**Нык-нык итеп**
Малай тудыбезнең.Нинди шатлык!
Икебезгә уртак бәхет таптык.
Сокланабыз аңа исебез китеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Малай үсә.Буе, яше арта.
Нәни чагы инде калды артта.
Уку-язу тәлап итә заман,
Каләм-китап кирәк бакчага да.

Әни, зинһар, акча китер миңа
Әйдә, тизрәк,йөгерик »Книжный»га.
Әти, зинһар, кабыз машинаны,
Тиз-тиз итеп, тиз-тиз итеп.

Йөгерәбез, шәһәр буйлап, китап эзләп.
Яңа ЕГЭ варианты чыккан икән.
Магазинга, магазинга тизрәк.
Китап кирәк, китап кирәк.

Төннәр буе ЕГЭ эшли бала,
Ярдәм итә аңа ата-ана.
Зур тормышта югалмаскакирәк белем
Моны бүген ачык аңлый һәркем.

ЕГЭ, ВУЗлар инде артта калды.
Бала кулына диплом алды.
Зур тырышлык белән юлын тапты
Нык-нык итеп, нык-нык итеп.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Гамил Афзал шигырьләренең тәрбияви әһәмияте бик зур.Балаларыбызны тәрбияләү өлкәсендә ата-аналар, җәмгыять, укытучылар, язучылар, шагыйрьләр максатчан эш алып барса, киләчәгебез тәрбияле балалар кулында булыр.



# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТӨРЛЕ ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ УЕННАР ҺӘМ БАШВАТКЫЧЛАР КУЛЛАНУ

**Гайнуллина Г.М.,**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**18 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Элек-элек заманнардан бирле татар халкы балаларны телгә өйрәткән, тел ачкычын биргән, ана бишек җырларын җырлап, гаиләдә сүзле уеннар оештырып, телне үстерүгә зур игътибар биргән. Сөйләмдә һәм язуда кеше телдән никадәр оста файдаланса, шулкадәр белемле дип таныла.

Кечкенә балаларга, хәтта яшүсмерләргә дә уен аркылы белем һәм тәрбия җиңелрәк бирелә, чөнки уен аның табигый халәте. Уен аша бала күп нәрсәгә өйрәнә, төрле күнекмәләр ала. Уен кызыксынуын арттыра, акыл эшчәнлеген, тапкырлыгын, зирәклеген үстерә. Ахырда мөстәкыйльлекне һәм ихтыяр көчен дә үстерергә ярдәм итә. Җиңгәндә һәм җиңелгәндә дә үз-үзен ничек бүтәннәр арасында тотарга да өйрәтә. (Бу инде укытучыдан да тора).

Башваткычларны дәреснең төрле этапларында, хәрефләрне матур һәм чиста язу минутларында, яңа теманы өйрәнгәндә, яисә кабатлау дәресләрендә, дәресләрне җанландыру өчен кулланырга була:

| | | |
|---|---|---|
|  |  |  |

Сүз төркемнәрен өйрәнгәндә, я булмаса кабатлау дәресләрендә 7 сүз төркеменә ребус бар, аларны кулланырга мөмкин.

Башваткычларны: шарада, метаграмма, анаграмма, логогрифларны балалар чишергә яраталар:

**Тартмада алар икәү,**
**Ә караватта – өчәү.**
**Эзләсәң аны җирдә,**
**Табалмассың син бердә.**
**Һавада ул авазлар,**
**Йәгез, кем әйтеп карар?**
(Монда сүз бара а авазы турында).

Мисалга логогрифлар:

| | | |
|---|---|---|
| **Логогриф**<br>Үзем ачырак булсам да,<br>Кайнатмам тәмле була,<br>Кайнатмам тәмле була,<br>Телне йотарлык була.<br>Алдан хәрефне алабыз,<br>Урманнан кая чыгабыз? | **Балан-алан**<br> | **Балан-алан**<br> |

Икенче логогриф һәм җавабы:

| | | |
|---|---|---|
| **Логогриф**<br>“Д” белән – мин көчле җил,<br>Дуласам, куркадыр ил,<br>Сыз алдан бер хәрефне,<br>Монда беләләр һәркемне. | **Давыл-авыл**<br> | **Давыл-авыл**<br> |

Метаграмма:

| | | |
|---|---|---|
| **Метаграмма**<br>“К” белән – тырыш җәнлек,<br>Күп булган илдә элек.<br>Ике хәреф баштан ал,<br>“А”ны алга өстә,<br>Килеп чыгар үсемлек:<br>Чәчәге сары төстә. | **Кондыз-андыз**<br> | **Кондыз-андыз**<br> |

Шарада:

| | |
|---|---|
| Ас-тар  | Ас-тар  |

Шарадада билгеле бер сүз берничә өлешкә бүленә һәм һәр өлеше аерым сүздән гыйбарәт. Шараданы чишкәндә, сүзләрне өлешләп чишәсең, бөтен сүз соңыннан чишелә.

*Мисаллар:*
Беренче иҗек җылыда эри,
Икенчесе җирне үлчи,
Икесе бергә оча, җирдә йөри,
Җирдән бөҗәкләрне чүпли.
(кар-га)

Беренче иҗек караның киресе,
Хайван түгел икенчесе,
Оча торган җәнлек,
Икесе бергә күлдә йөзә,
Кем кошны әйтеп бирә?
(ак-кош)

Сыекча беренче иҗек
Ансыз яши алмый кеше һәм җәнлек,
Икенче иҗек билгели алсу төсне,
Ул матурлап ача йөзне,
Өченче иҗек зур мичкә,
Аны кертә алмыйсың мичкә.
Бөтенесе бергә:

Бик кирәк әле җиргә,
Яңгырдан соң чыга,
Җирне йомшартып чыга.
(су-ал-чан)

Метаграммада яшеренгән билгеле бер сүз, аны белергә кирәк. Метаграмманы чишәр өчен элек бер сүзне чишәсең, ул сүздә бер хәрефне яисә иҗекне икенчесенә алыштырырга кирәк була, сүзнең мәгънәсе үзгәрә, димәк икенче сүз барлыкка килә, шуны чишсәң, димәк, максатка ирештең.

*Мисаллар:*
«М» белән – аны ашыйлар,
Ул – мәңге яшел агач.
«Т» белән – олылар бииләр,
Вальс белән мине сагынгач.
(манго-танго)

«С» белән билгеле төс
Ул матур сайлаганда,
«Т» белән ул бәрчәдә
Җитешә басуларда.
(сары-тары)

Логогрифларда башта нинди сүз турында әйтелгәнне табарга кирәк. Тапкан сүзгә бер яисә ике хәрефне я өстәргә кирәк, я, киресенчә алып ташларга кирәк,шуннан соң «җавап» сүзе килеп чыга.

*Мисал:*
Мин кызыл, яшел, сары,
Агачтан көзен төшәм,
Өстәсәң алга «с»ны,
Тәмле аш булып пешәм.
(алма-салма)

«С» белән битне сөртәсең,
Ул төшсә әгәр, күрәсең:
Сүз бөтенләй үзгәрә,
Үрнәккә тиз әйләнә.
(сөлге-өлге)
Эссе көндә җылы пар, томан
Күренәм мираж булып,
«Ке»не өстәсәң алдан,
Бик тиз очам канат кагып.
(рәшә-керәшә)

Анаграммаларда билгеле бер сүзне уйлап табарга кирәк, ул сүздәге хәрефләрнең урыннарын алыштырганда, икенче сүз хасил була, шул җавап була да инде.

*Мисаллар:*
Сулдан уңга укысаң –
Ылыслы агач була,
Уңнан сулга укысаң –
Җир астыннан су суырта.
(нарат-таран)

Сулдан уңга укысаң –
Аяк киеменең төбе, олтан.
Уңнан сулга укысаң –
Һәлакәттә кагалар чаң.
(табан-набат)

А авазы һәм хәрефенә табышмак, шарада, метаграмма, анаграмма, логогрифлар

Тартмада алар икәү,
Ә караватта – өчәү.
Эзләсәң аны җирдә,
Табалмассың син бердә.
Һавада ул авазлар,

Йәгез, кем әйтеп карар?
(а авазы)
Үзем ачырак булсам да,
Кайнатмам тәмле була,
Кайнатмам тәмле була,
Телне йотарлык була.
Алдан хәрефне алабыз,
Урманнан кая чыгабыз?
(балан-алан, укучылар әйтергә тиеш аланга)
«Д» белән – мин көчле җил,
Дуласам, куркадыр ил,
Сыз алдан бер хәрефне,
Монда беләләр һәркемне.
(давыл-авыл)
«К» белән – тырыш җәнлек,
Күп булган илдә элек.
Баштан ике хәреф ал,
«А»ны алга өстә,
Килеп чыгар үсемлек:
Чәчәге сары төстә.
(кондыз-андыз)
Беренче иҗек – бик матур җәнлек,
Киңнең киресе – икенче иҗек,
Бергә икесе
Табарсың үзеңдә,
Ул була киемдә:
Тунда, пальтода
һәм курткада.
(ас-тар)
Яши кара урманда,
Бал, җиләк ашый анда,
Кышын йокыга тала,
Нинди җәнлек, әйт бала.
(аю)

Мине йөртәләр кесәдә,
Минсез – беркем дә юк өйдә.
Кайткач ишек ачалар,
Мине элеп куялар.
(ачкыч)
Озын, җәен яшелдән киенә,
Аңа карап, күпләр сөенә.
Көзен җил аны талый,
Киемнәрен чишендерә,
Кыш килгәч, ак тун кидерә.
(агач)
Ак куян
Кара тактада сикерә,
Эзләрен карыйлар, сөртәләр,
Бик күпне беләләр.
(акбур)
Ә авазы һәм хәрефе
Тәгәрмәчтә алар өчәү,
Әтәчтә исә – икәү.
Әллә сорау шундый читен?
Безгә җавап бирә кем?
(ә авазы)
Б авазы һәм хәрефе
Тавыкта юк, әтәчтә,
Ишетерсең чебидә һәм әбидә.
Бәбидә һәм бабайда –
Алар икешәр,
Кем җавап әйтеп карар?
(б хәрефе)
Син өйдә мине табарсың
Һәм төрле биналарда.
Булам йозаклы, йозаксыз,
Алга «б»ны куйсагыз,
Төнлә бала йоклар уяусыз.

(ишек-бишек)
«А» белән – эшкәртәләр аны,
Эшлиләр монда.
Ул кайтара уңыш белән.
«А»ны «у»га алыштырсаң,
Аны тоталар гел кулда,
Ә ул тулы әйбер белән.
(бакча-букча)
«Ч» белән – вакытлы корылма,
Анардан яңгыр үтмәс,
«Б» белән – бик шаярма:
Көчле ул һәм җиңелмәс.
(чатыр-батыр)

Материал татар теленә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итәр дип өметләнәм.

# ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ УКЫТУНЫҢ НӘТИҖӘСЕН ҮСТЕРҮ

**Гайсина Р. З.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**1нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Мин, Гайсина Рәзилә Зәкиулла кызы, 1 нче мәктәптә рус телле балаларга татар теле укытам. Тел өйрәтү үзе бер кызыклы, җаваплы, нык ихтыяр көче сорый торган эш, дип уйлыйм. Башлангыч сыйныфларда Р.З. Хәйдәрова авторлыгындагы дәреслекләр белән эшлим. Алар бик кызыклы, төсле, рәсемле, яшь үзенчәлекләренә туры килә,тик коммуникатив максатка тулысынча җавап бирмиләр, чөнки без дәреслек буенча гына эшләп, балаларны җөмлә төзергә өйрәтмибез.

Хәзер яңа стандартлар турында күп сөйлибез. Яңа стандартлар буенча укытучы – юл күрсәтүче, ә укучы эзләнүче. Димәк, Р. Фәхреддиннең: «Күп белдерүгә караганда аз белдереп, эзләнү орлыгын салу, эзләгәнен үзе табарга өйрәтү, юлларын күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр», – дигән сүзләре бүген дә актуаль булып кала.

Төп максатыбыз шул. Бала татарча аңлый, аралаша белергә тиеш. Шуңа күрә дә, минемчә, грамматика белән артык мавыгырга кирәкми. Бары сөйләмдә актив булганнарына гына тукталырга кирәк. Үз дәресләремдә Н. В. Максимов тәкъдим иткән сөйләм калыпларын кулланам һәм моны отышлы дип саныйм. Гомүмән алганда, дәреснең сыйфаты укытучының ничек әзерләнүеннән тора.Безнең татар теленә өйрәтүебез дөрес түгел. Урыс баласына татар теле чит тел. Бер дәрестә әллә ничә сөйләм моделе бирелә, бу алар өчен бик авыр.

Безнең максат 45 минут буена бер генә җөмлә төре өйрәтергә. Грамматиканың үзен генә өйрәтмичә дә, сөйләм теленә өйрәтеп була.Килеш сүзен өйрәтмичә дә килешләрне

өйрәтеп була. Без күреп истә калдырабыз. Мин юнәлеш килешен менә ничек аңлатам:

| | Кем? | Кая? | Нишли? | | -мы,<br>-ме |
|---|---|---|---|---|---|
| Әйе, | мин | мәктәпкә | барам | бармыйм. | |
| Юк, | син | шәһәргә | барасың | бармыйсың. | |
| Әлбәттә, | ул | кунакка | бара | бармый. | |
| | без | театрга | барабыз | бармыйбыз. | |
| | сез | | барасыз | бармыйсыз. | |
| | алар | | баралар | бармыйлар. | |

Һәрбер багананы вертикаль юнәлештә тутырыбыз. Һәр баганадан соң нәтиҗә ясыйбыз. Икенче багананы тутырганнан соң, бу сүзләрнең нинди сорауга җавап бирүләре, нинди сүз төркеменә керүләре турында сөйләшәбез.( Кем? Соравына җавап бирәләр, зат алмашлыклары булалар).

Өченче багананы тутырганнан соң, сорыйм:

— Что общего между этими словами? (Есть окончания –га, -гә, -ка, -кә; отвечают на вопрос Кая?)

— То есть слова с окончаниями –га, -гә, -ка, -кә отвечают на вопрос Кая?. Кая? соравына юнәлеш килеше җавап бирә. (Шулай ук нечкә, калын булуларын тикшерәбез).

— Дүртенче багананы тутырганнан соң:

— Обратите внимание на окончания, что они означают?

— -м к какому слову относится? ( Мин).

— Фигыльләрнең заманнары билгеләнә. (Хәзерге заман хикәя фигыль).

— «Мин мәктәпкә барам», действие происходит? А если действие не происходит, как мы скажем?

— Мин мәктәпкә бармыйм.

— Окончания –мый, -ми образуют отрицательную форму глагола.

— Окончания вопросительного предложения –мы, -ме. (Син мәктәпкә барасыңмы?).

Таблица тезелеп беткәннән соң, диалог төзибез. Сөйләм моделен ятлап бетергәнче, шушы таблица өстендә эшлибез. Соңыннан монолог төзибез.

Хәзерге заманны өйрәнеп беткәч, билгеле уткән заманга, аннан соң билгесез үткән заманга күчәбез.

Без барыбызда дәрестә сораулар бирәбез, ләкин безнең сорауларыбыз беръяклы гына. Укытучы сорау бирә, ә балалар җавап кайтара, күбрәк «допроска» охшаган. Ә бит балалар үзләре дә сорау бирә белергә тиеш. Менә шушы сөйләм калыбына таянып, балалар җиңел генә сорауларны үзләре дә төзи алалар.Сорауга каршы сорау бирергә өйрәнәләр. ( Встречный вопрос).

Башлангыч сыйныфларда гади таблицалар төзелә, ә югарырак сыйныфларда катлауландырыла. Кушма җөмлә төзергә өйрәтергә дә була. Шуннан соң монологка чыгабыз, текст төзибез. Ә текст төзи алгач, укучылар үзләре генә сочинение (инша) дә яза ала дигән сүз.

Тик бер хатадан сакланырга кирәк, сөйләм моделе буенча артык күп эшләү: берсен өйрәтеп бетермичә икенчесенә күчү, яисә бер дәрестә ике таблица өйрәнү. Бер сөйләм моделен өйрәтеп бетермичә, икенчесенә күчү; яисә бер дәрестә ике сөйләм моделен өйрәтү.

Мин дәресләремдә шушы сөйләм калыпларын кертәм һәм бу бик яхшы нәтиҗә бирә.Укучылар мондый дәресләрдә актив катнашалар. Җавапларын үз-үзләренә ышанып бирәләр.

Мин шушы алым буенча семинарда ачык дәрес тә күрсәттем.

Н. В. Максимов технологиясе буенча елына 30 сөйләм моделе өйрәтеп була. Бу сөйләм калыплары бик яхшы нәтиҗә бирә.

— сүзлек запасын баетабыз;
— лексик юнәлештә эшлибез;
— грамматика юнәлешендә эшлибез;
— җөмлә төзелешен өйрәнәбез;

— сүз төзелешен өйрәнәбез, чөнки һәрбер кушымча аңлатылып барыла;

— пунктуациягә дә өйрәтәбез.

Дәреслектәге темаларны бер калыпка салабыз, сөйләм модельләренә яраклаштырабыз.

# РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**Фатхлисламова С.,**
**Бөгелмә шәһәре 8 нче урта мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Татар телен чит тел буларак укытуда заманча технологияләрне куллану безнең эштә төп урынны алып торырга тиеш. Телне өйрәтүнең төп чараларын билгеләү, укыту-тәрбия эшчәнлеген оештыруга ярдәм итүче барлык уку материаллары белем бирү чарасы булып санала. Алар төп һәм ярдәмче чараларга бүленәләр.

Хәзерге вакытта дәресләрдә инновацион технологияләр куллану үз эшеңнең нәтиҗәсен күрергә ярдәм итә. Мин практикамда шәхескә юнәлтелгән технологияләрне кулланырга тырышам. Укучыларның үз хезмәтләрен үзанализ яки үзбәя аркылы бәяләргә тәкъдим итәм. Үзбәя кую схемалары белән укучылар инде күптән таныш, схемалар һәр укучының алдында ята. Укучы дәреснең һәр этабында үзенең эшчәнлеген бәяләргә тиеш була, ахырдан гомуми билге чыгарыла. Соңыннан укытучы укучылар белән берлектә эшне кабат тикшерә. Үзбәя куела.

Иҗади үстерелешле укыту технологиясе укучыга иҗади үсәргә ярдәм итә. Төрле темаларга сөйләшү оештырганда, укучыларны, белем дәрәҗәләренә карап, берничә төркемгә бүлеп утыртам. Укучылар алдына проблемалы сорау куела: «Син спорт белән дусмы?» Сөйләшүне төрлечә дәвам итәргә кирәк. Төркемдәге һәр укучы үз фикерен тулысынча, мисаллар белән сөйләп бирә, һәм шулай ук үзбәя куела.

Татар телен чит тел буларак өйрәтү процессында уеннардан файдалану укучыны белем алырга дәртләндерә, аларда фән белән кызыксыну уята. Аеруча, грамматик уеннар баланы фикерләргә, эзләнергә өйрәтә, телләр белүнең тормышта кирәк булуына төшендерә. Уен барышында балалар берләшә, бер-берсенә ярдәм итә, аларда үз көчләренә ышаныч арта.

Өйрәнелгән темалардан соң үткәрелгән уеннар аеруча нәтиҗәле була. Ул укучыларның сүз байлыгын арттыра, уен белән мавыккан укучы, курку хисен җиңә. Грамматик уеннар шунысы белән әһәмиятле: укытучы уенны башлар алдыннан, «татарча гына сөйләшәбез» дигән таләп куя, һәм ул укучы өчен җаваплы эш булып тора. Дәрестә уйнала торган уеннар берничә төркемгә бүленә:

*а) өйрәнелмәгән лексик – грамматик материаллы уеннар;*

*б) өйрәнелгән лексик – грамматик материалны ныгытырга ярдәм итүче уеннар;*

*в) граммматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар;*

*г) грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен камилләштерүгә ярдәм итүче уеннар.*

*Рус телле балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятырлык уеннар бик күп. Мәсәлән:*

1. Аерым билгеләр буенча сүзләр табу ( беренче аваз, хәреф һәм иҗек буенча; бирелгән тема буенча; рәсем буенча; соңгы хәреф буенча; синонимнар, антонимнар табу).

2. Сүзләрне тергезү (төшеп калган хәрефләрне кую; таралган хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштыру; таралган сүзләрдән җөмләләр төзү; яңа сүз ясау өчен хәрефләр (иҗекләр) өстәү яки алып ташлау).

3. «Тирәбездә нәрсәләр бар?» уены (әйләнә-тирәдәге мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атау).

4. «Кем яхшы күрә?» (рәсемнәрдә сурәтләнгән әйберләрне, аларның билгеләрен, хәрәкәтләрен санау).

5. «Үзебезнең типография» (өйдә укылган хикәя буенча кечкенә китапчыклар ясау).

6. «Кәефең ничек?» (укучының кәефенә туры килүче смайликлы рәсемне сайлап сөйләве).

7. Предметларны чагыштыру һәм шуларны рәсемнәргә төшерү.

8. Сынамышлар, тизәйткечләр, җырлар, табышмаклар, башваткычлар, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллану да татарча сөйләшергә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия. Алар укучыларның белемен, осталыгын, иҗади эшчәнлеген үстерә.

Рольле уеннарга аерым тукталып китәсем килә. Аларны эш барышында актив кулланам, тәкъдим ителгән ситуацияне күзаллап, укучылар рольле уеннарда теләп катнаша. Аларны парларда, төркемнәрдә үткәрергә мөмкин. Рольле уен катнашучылар һәм тыңлаучылар өчен бер дәрәҗәдә файдалы. Укучыларда төрле сөйләм формаларын кулланып сөйләшүдә катнашу, нидер сорау яки әңгәмәдәшенә җавап бирү ихтыяҗы туа. Рольле уен берничә этаптан тора: өйдә яки сыйныфта аңа әзерләнү, сыйныфта уенны оештыру, йомгаклау. Уенны оештырганда, укытучы берничә алшартны истә тотарга тиеш:

1) укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру;

2) сөйләм эшчәнлегенең дәрәҗәсен истә тотып, балаларга рольләрне дөрес бүлеп бирү, укучыларның мөмкинлекләренә игътибар итү;

3) укучының кәефен тоемлап, уңай нәтиҗәгә ирешүгә омтылу;

4) укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрне еш куллану;

5) үзара ярдәмләшү, телдән актив аралашу мохите булдыру.

Соңгы вакытта җәмгыятьтә барган үзгәрешләр белән беррәттән илебезнең мәгариф системасында укыту эчтәлеген яңарту процессы бара. Аның үзәгендә – шәхес, ягъни – укучы. Тирән белемле, югары әхлаклы, үз-үзен иҗади үстереп, шәхес буларак танытучы укучы тәрбияләү һәр укытучының бурычы.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү барышында файдалы, кызыклы итеп, заманча технологияләрдән файдаланып, югары нәтиҗәләргә ирешергә тырышам. Дәресләрдә балаларның танып белү эшчәнлеген үстерү өчен эш төрләрен дифференцияләштерү дә зур нәтиҗә бирә. Ягъни, сыйныфтагы һәр балага шәхси якын килеп, шәхси үзенчәлекләрен истә тотып, бирем һәм күнекмәләрне аерып бирү. Бу бигрәк тә йом-

шак укучылар өчен мөһим. Максатым: аларның белемнәрен, укуга карата кызыксынуларын һәм омтылышларын үстерү. Белемнәре, интеллектуаль дәрәҗәләре югары булган укучылар катлаулы, иҗади характердагы биремнәрне эшли алалар. Мәсәлән: дәрес барышында 7-8 таныш һәм таныш булмаган сүзләр әйтеп чыгам. Укучылар хәтерләрендә калдырганнарын дәфтәрләренә язалар, үзбәя куялар. Көчле укучылар шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр, йомшаклары сүзтезмәләр уйлыйлар. Кул астында төрле дәрәҗәдәге дифференциаль карточкалар, схемалар, рәсемнәр тотам. Газета-журналлар да бу вакытта ярдәмгә килә. Дифференциаль өй эше бирү дә гадәткә керде. Аны мин дәреснең беренче яртысында, укучы әле арып өлгермәгәндә бирергә тырышам:

а) дәрестә укылган тексттагы исемнәрнең килешләрен билгеләргә;

б) сыйфатларны табарга;

в) фигыльләрнең заманнарын билгеләргә;

Иҗади характердагы эшләр башкарганда да дифференциаль якын килеп эшләп була. Изложение язганда сыйныф ике төркемгә бүленә. Бер төркемгә текст танышу өчен өйгә бирелгән була. Көчле укучылар инде эшкә керешкәндә, йомшак укучылар, бер түгәрәккә җыелып, укытучы ярдәме белән язарга әзерләнәләр (сорауларга җавап бирәләр, план төзиләр).

Яңа технологияләр татар телен өйрәнүче укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлеккә өйрәтә. Компьютер технологияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерергә, информацион технологияләр дөньясындагы яңалыклар белән кызыксынырга теләк уята. Бүгенге көндә татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту зур тырышлык сорый. Компьютер технологияләрен кулланып укыту шушы проблеманы хәл итәргә булыша. Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшләргә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар әзерләргә өйрәтә.Укучылар аерым темаларга презентацияләр төзеп чыгышлар ясыйлар. Төрле конкурсларда катнашалар.

Сөйләм үстерү дәресләрендә бу презентацияләрне куллану да бик файдалы. Әзер материаллар рус телле балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уята. Мисал өчен «Минем гаиләм» темасын гына алыйк. Гаилә әгъзаларының әйтелеше татар телендә яңгырап, укучыларда сүзләрне дөрес әйтүгә һәм дөрес язуга булышлык итә. Үрнәк диалоглар тыңлау, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерә.

Укучыларның төрле әзерлек, белем дәрәҗәләренә юнәлдерелгән стандарт булмаган эш алымнарының иң отышлысы – проект эшен оештыру. Әлеге эш төре укучыларны актив эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тартырга ярдәм итә. Укучылар башлангыч сыйныфлардан ук фәнни-тикшеренү өлкәсендә беренче тәҗрибә туплыйлар, тикшерү методлары белән танышалар. Тикшерү нәтиҗәләре буенча презентацияләр әзерлиләр, аны яклап чыгыш ясыйлар. Проектлы укытуның мавыктыргыч, уен формасында булуы һәр дәресне укучылар өчен бәйрәмгә әйләндерә. Укучылар яңадан – яңа уңышларга ирешергә тырыша. Әлеге эшчәнлек татар телен кызыксынып өйрәнергә, грамоталы язарга өйрәтә.

Татар теле укытучыларының төп максатлары:

- укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- логик фикерләү сәләтен, сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;
- татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән даими таныштырып тору.

Бу максатларга ирешү өчен, рус балаларына татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Укучыларның танып белү активлыгын арттыру;
- Иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- Тыңлап аңлау (аудирование), сөйләү, уку, язу күнекмәләрен формалаштыру.

Бүгенге мәктәп укытуның традицион формалары белән генә чикләнеп калмый. Аның эчтәлеге инновацион процесслар белән тулыландырылганда гына алга китешне, үсешне күрергә

мөмкин. Һәрбер сыйныфта дәреслек белән генә чикләнмичә, методик кулланмалар, дидактик материаллар, җыентыклар, таблицалар, сүзлекләр, компьютер, проектор, интерактив такта, интернет челтәре кебек чаралардан да актив файдаланырга кирәк. Рус телендә сөйләшүче балаларга дәүләт телен үзләштерү өчен шартлар тудырылган. Хезмәтебезгә иҗади якын килеп, заманча технологияләрне урынлы кулланып эшлисе генә кала.

## ЯЗМЫШЛАР БИТ БЕЗ ДИГӘНЧӘ ТҮГЕЛ…
## (Хәсән Туфан иҗаты буенча сыйныфтан тыш чара)

**Гыйләҗева Г.Л.,**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**9 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Максат:**

Укучыларны Хәсән Туфанның тормышы һәм иҗат юлы белән тулырак таныштыру, балаларны шигырьләр хакында фикер йөртә белергә, аны аңларга, сәнгатьле сөйләргә өйрәтү һәм укучыларда туган илгә, туган телгә, ата-анага, сөйгән ярга, дусишләргә, табигатькә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:**

Хәсән Туфан портреты, «Хәсән Туфан» CD дискы, «Шигърият бакчасында» фонохрестоматиясе, буклетлар, Хәсән Туфанга багышланган Power Point программасында компьютер презентациясе, компьютер, мультимедиа аппараты, http://www.kitap.net.ru/tyfan.php, http://www.museum.ru/M2656 интернет-сайтлары.

Алып баручы:

— «Син гөлләр булсаң әгәр, ак чәчәк атар идең...» Кем сүзләре әле бу?! «Материя мин, җаным, сөя, сагына, елый торганы ...» Хәсән Туфан! Ике генә строфа танып алу өчен шул да җитә. «Кайсыгызның кулы җылы?...» Әйтә башладым гына ич әле, сез инде дәвамын пышылдыйсыз. «Бәйлисе бар йөрәкне». Шигърияткә 90 ел элек килеп кергән, ә безнең күңел дәфтәрләребездә нахакка гаепләнгәннән соң акланып кайткач урын алган шәхес бит ул! Сәер янәшәлек: ак чырайлы, ак күңелле, ак ниятле зат һәм ... аклану гамәле.

— Укучылар безнең бүгенге уеныбыз шигърият күгендә иң якты йолдызларның берсе булган күренекле әдип, репрессия машинасының ерткыч киртәләрен үтеп, ГУЛАГ

тәмугының барлык газапларын узып исән-сау әйләнеп кайткан һәм үзендә яшәргә һәм иҗат итәргә көч тапкан олы җанлы илаһи шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына багышлана. Хәсән Туфан күп еллар татар поэзиясенә армый-талмый хезмәт итә, күп телләргә тәрҗемә ителә, каләмдәш дусларына ярдәм итә, поэзия мәйданының чикләрен киңәйтә. Шушы гадәттән тыш тыйнак, бик тә мөлаем һәм игымлы Туфанны ничек гаепләп була соң? Аны һәр чын шагыйрьгә хас сыйфатлары һәм бу дөнья кешесе булмаганы өчен генә гаепләп буладыр. «Балалар кебек тиз ышанучан, садә күңелле, хыялый кеше иде шул ул», – дип искә ала аны Туфанның тормышын өйрәнгән Рафаэль Мостафин да.»

Хәсән Туфан татар халкының бәгыре иде, шагыйре генә түгел, шигыре иде. Ак дәфтәр бите шикелле керсез тормышын вак-вак хәрефләр белән яшел карага манып язды ул. Без бүген менә шул бик тә зур ихтирамга лаек булган язучының иҗаты турындагы белемнәребезне тагын да тирәнәйтербез һәм үзебезнең белгәннәребезне күрсәтербез.

Уеныбызның беренче туры «И язмыш, язмыш ...» дип атальр. Һәр командага чиратлап сораулар бирелер, әгәр дә җавап бирә алмасагыз, җавап бирү мөмкинлеге икенче командага күчерелә.

1. Хәсән Туфанның туган көне, ае, елы. (1900 елның 9 декабрендә).

1. Хәсән Туфан туган як. (Аксубай районы Иске Кармәт авылы).

2. Хәсән Туфан шәкерт булып укыган мәдрәсә (Шагыйрь «Галия» мәдрәсәсендә белем ала).

2. Хәсән Туфан әдәбият дәресләрен кемнән ала? (Галимҗан Ибраһимовтан).

3. Хәсән Туфан җәяүле сәяхәт иткән яклар (Кавказ һәм Урта Азия якларында).

3.Эшләгән эшләре (бакырчы-шахтер, токарь, слесарь,

укытучы, журналист).

4. Шагыйрьнең чын исем фамилиясе (Хисбулла Гөлзизин).

4. Матбугатта басыла башлавы (1924 елдан).

5. Язучылар Союзына алыну вакыты(1934 ел).

5. Хәсән Туфанның язмышында аянычлы роль уйнаган, аның «халык дошманы» дип кулга алынуының сәбәпчесе булган әсәр («Ант» поэмасы).

6. Хәсән Туфан белән бергә сөргеннән Казанга кайткан ике татар язучысының исемен атагыз (Сөббух Рафиков, Ибраһим Салахов).

6. Ничәнче елда аклана? (1956 елда).

7. Яраткан мавыгуы (Чәчәкләр үстерү, сәгать төзәтү).

7. Яраткан чәчәге (ромашкалар).

8. Нинди кара белән язарга яраткан? (яшел).

8. Кайсы вакытта иҗат итәргә яраткан? (төнлә).

9. Яраткан уен коралы (мандолина).

9. Яраткан агачы (каен).

10. Бүләкләре (Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге).

10. Яратан шагыйрьләре (Һади Такташ, А. Твардовский).

— Хәзер хөкемдарлар нәтиҗә ясаганчы без Хәсән Туфанның үзе укуында «Талантлы син кеше туганым» шигырен тыңлап китәрбез.

Иҗат юлы дәвамында нинди генә авырлыклар кичерсә дә, Туфан – баштан ахыргача үзенә генә хас индивидуальлеген саклаган шагыйрь. Ул поэзиядәге классик төзек, халыкчан, искиткеч камил эшләнгән шигырьнең иң матур үрнәкләрен тудырды.

Иң авыр шартларда да Туфан язуын дәвам итә. Алай гына да түгел, шагыйрь иҗатының иң актив чоры, иң югары ноктасы нәкъ менә тоткынлык елларына туры килә. Башта Х. Туфан язылган шигырьләрен күңеленә беркетеп, исендә генә тоту авырлаша. Ә иң хәтәре: үзе үлсә, барлык язганнары да юкка чыгачак.

Шагыйрь шундый әмәлен таба. Эшкә төнге сменага чыга.

Иптәшләре ял иткән арада, 3-4 кат күзлек киеп, каты карандашны кыл сыман очлап, шигырьләрен папирос кәгазенә яза (ул аларны папиростан аерып ала), монда 300 юлга якын шигырь сыя. 20-30 бит җыелгач, ул аларны түгәрәкләп тыгызлап төрә дә, сохарины тишеп шуның эченә яшерә. Тишекләрне исә ике яктан да ипи белән ябыштырып, мич алдында кыздырып киптерә. Шулай итеп ул, барысын булмаса да, иҗатының төп өлешен саклап, туган якларына алып кайта.

Алдагы турыбыз язучының иҗат җимешләренә багышланыр.

II тур Ничек икән синең йөрәк, дисең,
Ничек икән гомер көннәрең? –
Кулымдагы китабымда чордаш,
Шигырьләрдә минем йөрәгем.

Җавапларны кыңгыраулар ярдәмендә бирерсез. Кем өлгеррәк булыр?

1. – Бу шигырьләрнең кайсысын Х. Туфан язган?

1. Туган тел. 2. Туган тел турында җырлар. 3. Татар теле.

2. Хәсән Туфанның нинди шигыреннән өзек китерелде?

(«Чәчәкләр китерегез Тукайга» шигыре «Шигърият бакчасында» фонохрестоматиясеннән тыңлана).

4. Х. Туфан хатын-кыз җырчылардан кемне яратып тыңлаган? (Ф.Кудашева).

4. Ир-ат җырчылардан иң яратканы кем булган? (И. Шакиров).

5. Бу шигырьләрнең кайсысына Сара Садыйкова көй язган?

1. Казан кичләре. 2. Ак каен. 3. Агыла да болыт агыла.

6. Хәзер без сезнең белән җыр тыңлап китәрбез. Җырның исемен атарга кирәк. («Ак каен» җыры «Хәсән Туфан» CD дискыннан тыңлана).

Хөкемдарлар 2 нче турга йомгак ясаганчы Х. Туфанның музеена виртуаль сәяхәт кылырбыз. 11 – «Ромашкалар» җыры яңгырый

Алып баручы: Хәсән Туфанны без, барысыннан да элек үзенең фаҗигале язмышын, фаҗигале мәхәббәтен чагылдырган лирикасы белән кабул итәбез. Шул ягы белән ул үзенең генә түгел, чорның да, халкыбызның да язмышын ачты. Аңа кадәр беркем ача алмаганча шул фаҗигане, шигърият дәрәҗәсенә күтәреп, дөньяга яңгыратты.

Хәсән Туфан ромашкаларны бик яраткан, алар белән күрәзәлек иткән, кырда үскән бу ак чәчәкләр аның бердәнбер күңел юанычы булган. Һәр ромашка аны тынычландырырга теләгәндәй «ярата», «хәтерли» дип җавап биргән. Ләкин сөргеннән кайтыр алдыннан аңа хатынының үлем хәбәрен җиткерәләр. Менә шул чакта күңелендә йөрәк өзгеч юллар туа:

Юк, ромашка, минем йөрәкнең
Януларын баса алмыйсың.
Көтә әле, сагына һаман, дип,
Алдыйсың ич мине, алдыйсың.

III тур «Хәсән Туфан-мәхәббәт җырчысы»

Һәр командага биремнәр бирелгән иде. Беренче команда «Нәрсә ул мәхәббәт?», икенче команда «Нәрсә ул бәхет? сорауларына җавап бирерлек афоризмнар җыярга тиеш иде. Хәзер сезнең фикерләрне тыңлап китәрбез.

— Әйе, укучылар бу төшенчәләрне һәркем үзенчә аңлый. Кемгәдер бер елмаеп карау да бәхет булып тоелса, кемгәдер алтын таулары да бернинди сөенеч китермәскә мөмкин. Ә хәзер кабат Х. Туфан иҗатына әйләнеп кайтыйк. Командалар ромашкаларга язылган биремнәрне үтәп китәр.

1. Х. Туфанны сөю дәрьясына алып кереп киткән кеше? ( Луиза Салигаскарова)

2. Л. Салигаскаровага багышланган шигырьләрен атагыз. Берсеннән өзек сөйләп китегез. («Тургай нигә эндәшми», «Ромашкалар», «Кайсыгызның кулы җылы?», Тамчылар ни диләр?» «Әйткән идең»)

1. Х. Туфан тормышында йөрәк дәвасы булырлык зат очрый. Кем ул? (Шагыйрә Клара Булатова)

2. Х. Туфанның мәхәббәт турындагы шигырьләрен атагыз. Берсеннән өзек сөйләгез. («Бәхет», «Син дә көттеңме?», «Җилләр исә», «Иртәләрем-кичләрем», «Кояшта тудың микән?»)

— Димәк, шагыйрьнең саркып торган ярасы тән ярасы түгел, ә күңел ярасы икән. Шундый сырхаудан савыктыру өчен, аны аңлардай зат кирәк икән. Йөрәк дәвасы булырдай зат очрый Туфан тормышында, шагыйрь аны патша кызы дәрәҗәсенә күтәреп, Тәнәкә дип атый, илһамланып сөю хатлары, мәхәббәт шигырьләре яза. Тәнәкәнең прототибын Клара Булатованы очраткач, Туфан аңа багышланган шигырьләрендә үзен Искәндәр дип атый. Шагыйрьнең Искәндәр-Тәнәкә мәхәббәтенә багышланган шигырьләр циклы бар.

Хөкемдарларыбыз нәтиҗә ясаганчы Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Әйткән идең» җырын тыңлап китәрбез. («Хәсән Туфан» CD диск)

— Миңа Ленин премиясе дә бирделәр, Зур Герой да булдым, әмма әле булса Х. Туфан дәрәҗәсенә менеп җитә алганым юк, аны һаман чын остазым итеп саныйм...» дип язды Мостай Кәрим. Чынлап та, ул күп кенә язучыларны илһамга рухландырган язучы.

4 турыбыз «Туфанны сагынганда» дип атала. Кайсы команда җитезерәк җавап бирер.

1. Бу кем сүзләре?

«Туфан – авыр, катлаулы юл үткән, татар поэзиясенең зурлыгын гел сиздереп торган, Такташлар чорын бүгенге белән нык тоташтырган бердәнбер олуг фигура. Татар поэзиясендә Туфан бер генә, башка Туфан юк!» (Сибгать Хәким)

2. Кемнең Х. Туфанга багышлап язган шигыре?

— Х. Туфанның мөлаем елмаюын язучылардан кем рәсемгә төшергән? (Марсель Галиев)

— Бу портретларның кайсысын М. Галиев иҗат иткән?

Хөкемдарларның нәтиҗәләрен тыңлап китик инде.

— Х. Туфан иҗаты туган җирне яратырга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә;

— кешедә горурлык, гаделлек хисләре тәрбияли;

— мәхәббәтеңне сакларга, кадерләргә кирәклеген әйтә.

Әйе, укучылар, Халык шагыйре Х. Туфанның иҗата алдында баш иябез. Иҗатының кайсы гына чорына күз салсаң да, шигырьләрендә әледән-әле ак каенга, аккошларга, ак чәчәләргә, ак күлмәккә, ак юлга, ак теләкләргә юлыгасың. Ак төс Туфан шигъриятендә рухы сафлыкны гүдәләндереп килә. Ул үзе дә аклык, сафлык символы булып яшәде. Х. Туфан безнең арада булмаса да, аның җырлары, мәхәббәт-сагышлары халык күңелендә «шигырь булып яшәвен» дәвам итә.

## БЕЛЕМ БИРҮ СЫЙФАТЫ УКЫТУНЫҢ НӘТИҖӘЛЕ ЫСУЛЛАРЫН ФАЙДАЛАНУГА БӘЙЛЕ

**Сөнгатуллина Г. Ф.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Татар теленнән бердәм республика тесты гамәлгә кереп бара, шунлыктан укучыларда татар теленнән белем сыйфаты өчен җаваплылык та арта, белем бирүнең эзлеклелеген саклау принцибы тормышка аша, ә иң мөһиме: укучыдагы белем сыйфатына объектив бәя биреп булачак. Шулай ук 9 нчы сыйныф чыгарылыш укучысы системалы белем алса гына, бердәм республика тестына уңышлы әзерләнә һәм, анда катнашып, белем алуның югары баскычына күтәрелә ала.

Бердәм республика тесты укучының мәктәп программасында өйрәнелгән фонетика, орфоэпия, орфография, лексика, фразеология, морфемика, сүз ясалышы, грамматика, пунктуация, сөйләм эшчәнлегенә өйрәтү бүлекләрендә алынган белемнәрен гамәли куллана белү дәрәҗәсен тикшерү өчен үткәрелә.

2012/2013 нче уку елыннан республикабызда 9 нчы сыйныфлар өчен имтихан, сынап карау рәвешендә, яңа формада уздырыла башлады. Узган елдан имтихан бердәм республика тесты итеп үзгәртелде. 9 нчы сыйныфларда бердәм республика тестын тапшыру нәтиҗәләре турыдан-туры укучының грамоталылыгына, планлаштырылган әзерлегенә бәйле. Бердәм республика тестына әзерләнү һәм аны уңышлы тапшыру өчен, укучының белем һәм күнекмәләре ни дәрәҗәдә булырга тиеш?

Бүгенге көндә традицион диктант кына укучыларның белем һәм күнекмәләренә төгәл бәя бирә алмый. Укучыларның белем дәрәҗәсен бәяләүдә тест, текст өстендә комплекслы эшләр, төрле темага иҗади сочинениеләр уңайлы форма булып тора.

9 нчы сыйныф укучыларын изложение һәм сочинение кебек эш төрләрен бәяләү критерийлары белән яңадан таныштыра-

ру кирәк, чөнки бу текст төзелешендә, микротемаларны аерып чыгару барышында җибәрелгән хаталарны күрергә, үз эшләрен дөрес бәяләргә ярдәм итәчәк. Имтиханга әзерләнгәндә, укучыларга бер-берсенең алдан эшләп каралган вариантларын анализларга бирергә, тапкан хаталарны аерым биткә язып алырга тәкъдим итәм. Бу вакытта укучы нәрсәгә игътибар итәргә икәнен, киләчәктә үзенең хезмәтендә мондый хаталар җибәрергә ярамаганын тизрәк аңлый. Мондый аналитик алым укучыга да, укытучыга да бик файдалы була.

Татар мәктәпләрендә эшләүче укытучыларның тагын бер мөһим бурычы – укучыны кыска күләмле изложение язарга өйрәтү. Бары тик системалы рәвештә, текстта бирелгән информацияне эшкәртеп кенә, кыскарту күнекмәләре булдырырга мөкин. Мисал өчен, берничә җөмләдән генә торган кыска хикәяне бер озын җөмлә итеп әйтеп карау һ. б.

Текст өстендә эшләү нәтиҗәле булсын өчен предметара интеграция булу мөһим**.** Әдәбият дәресләрендә конспектлаштыру, реферат төзү, катлаулы план һәм бәяләмә бирү кебек эш төрләрен күбрәк файдалану сөйләм күнекмәләрен ныгытырга тагын да ярдәм итәчәк.

9 нчы сыйныф укучылары өчен биремнәр 3 өлештән тора: укучылар кыска изложение язарга, тәкъдим ителгән текст буенча тест биреме башкарырга, иҗади инша (сочинение) язарга тиеш.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, укучыларны изложение язарга өйрәтү кыен эш түгел. Гадәттә, укучыларда тест биремнәрен үтәү һәм иҗади биремнәрне башкару күнекмәләре булдыру кыенрак.

9 нчы сыйныфта бердәм республика тесты биремнәре укучыларда түбәндәгеләрне тикшерә (икенче төрле әйткәндә, кодификация нәрсәне үз эченә ала):

— лингвистик компетентлык, димәк, сөйләм теленә гадәти лингвистик анализ ясый белү;

— коммуникатив компетентлык, димәк, сөйләм теленең төрле төрләреннән файдалана белү һәм чит сөйләмне кабул итеп, үз фикереңне логик бәйләнештә җиткерә алу;

— тел компетентлыгы, димәк, татар телендә иркен аралаша алу, сүзлек байлыгы һәм грамматик нормалардан оста файдалану; тел нормаларын саклау.

Татар теленнән бердәм республика тесты структурасы һәм эчтәлеге өч өлештән тора. Имтиханның беренче өлеше тыңлаган текстның кыскача эчтәлеген язуны үз эченә ала. Укучы текстган төп һәм бик мөһим булмаган информацияне аера белергә тиеш. Бу эш төре укучыдан эчтәлекне истә калдыруын, фикерне эзлекле, логик бәйләнештә җиткерүен, сүз байлыгыннан максатчан файдалануын, хикәяләү, сурәтләү, бәяләү осталыгын күрсәтүне таләп итә.

Икенче өлеш укылган текст нигезендә башкарыла, һәм аның эчтәлеген тирән һәм төгәл аңлау тикшерелә. Укучының төп проблеманы аңлавы, автор яисә геройның позициясен тоемлавы, геройга характеристика бирә белүе, геройларга карата авторның мөнәсәбәтен күрә алуы; өйрәнгән сәнгати чараларны белүе бәяләнә. Бу өлештә шулай ук укучының сүз байлыгы да исәпкә алына.

Өченче өлешнең биремнәре үз фикереңне дәлилләүгә, шулай ук аргументлаштыруга бәйле. Моны бәяләү өчен, төрле әдәбияттан, сәнгатьнең башка төрләреннән, милли төбәк компонентларыннан, тормышта күргән яки белгәннәреннән иркен файдалануын күздә тоталар. Укучының киләчәккә булган хыялын һәм омтылышын, уй-тойгыларын чагылдырганда, тирә-юньдәгеләргә карата мөнәсәбәтен, тәрбиялелеген дә исәпкә алалар.

Өч өлешнең барысы да бер-берсе белән бәйле һәм укучының танып белү эшчәнлеге логикасын тулысынча күзаллый, шулай ук татар телен камил дәрәҗәдә белүен яки белмәвен ачыкларга ярдәм итәчәк.

9 нчы сыйныфта эшләүче һәр укытучы үзе уздырган тест нәтиҗәләре буенча сыйфат үсешен яктырткан мониторинг алып бара. Хаталар өстендә эш, вакытында кимчелекләрне төзәтү, киләчәктә үзен аклый.

# ХАЛЫК ТАРИХЫ – ИСЕМНӘРДӘ

**Тахаутдинова Г. С.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**Карабаш икенче урта мәктәбенең география укытучысы**

Туган җир. Туган авыл.

Йөрәккә якын һәм кадерле сүзләр. Һәр кешенең газиз туган йорты, йорты урнашкан кадерле туган авылы бар.

Карабашыбызның табигате гаҗәеп бай, аны төрле яктан таулар уратып алган, боргаланып-сыргаланып агып киләләр дә, Дала Зәе белән Урман Зәе бергә кушылып, Чулманга юл алалар. Чишмәләре, болыннары, кырлары, басулары, шаулап торган урманнары, сазлыклары дисеңме – бары да бар. Кечкенәдән үк, олылар үзара сөйләшкәндә һәр табигый объектны үзебезчә атаганннарын ишетеп үстем, үзем дә ул атамаларны хәзергәчә кулланам. Институтны тәмамлап кайткач, мәктәптә география укыта башладым. Ә һәр география дәресе ул – яңа ачышлар, яңа атамалар, алар һәрвакыт укучыларда зур кызыксыну уята. Кайсы гына фәнне алмыйк, туган як тарихымы ул, татар әдәбиятымы, географияме, алар арасында бер бәйләнеш бар: ул – географик атамалар. Шунысы кызык: аларның һәркайсысы кеше белән бәйләнештә барлыкка килгән. Мәдәни һәм этимологик яктан караганда да туган якның микротопономикасын өйрәнү бик кирәкле эш. Җирле атамаларның ни өчен шулай исемләнгәнен, бу исемнәрнең нинди серләр саклавын беләсе килү күңелне кытыклап тора. Минем дә туган ягым Бөгелмә районы Карабаш эшчеләр поселогының (элек зур гына авыл булган) микротопономикасын җыеп, укучыларым белән бергә фәнни яктан өйрәнәсем килде. Өйрәнеп кенә калу түгел, буыннан буынга тапшырылып килгән атамаларны саклап, тормышта куллану иде теләгем.

Үзебезнең эзләнүләребезне профессор Г. Ф. Саттаровның «Туган авылның яки төбәкнең ономастик материалларын җыйнау өчен сораулык» ярдәмендә алып бардык. Эш барышында, әби

һәм бабайлар белән очраштык, алар сөйләгәннәрдән чыгып, карта төзедек, җирле географик атамаларны билгеләдек. Нәтиҗәдә, якын-тирәдәге авыллар, 48 урам, 16 калкулык, 5 чокыр һәм ерганак, 4 көтүлек , печәнлек һәм болыннар, 3 кыр һәм басу исеме, 8 урман, куаклык, 5 юл, 17 елга, чишмә, күл һәм сазлык атамасының килеп чыгу тарихын өйрәндек.

Зәй суының югары агымында урнашкан бик борынгы авылны Карабаш диләр. Авыл исеменең килеп чыгуы да бик кызыклы. Шәҗәрәләр һәм халык арасында сакланган риваятьләргә караганда, авылның исеме Карабаш исемле кеше белән бәйләнгән. Йөз яшькә җитеп вафат булган Закир бабай Бадыйков сөйләве буенча, Карабашны »Карбыш» авылы дип йөрткәннәр. Аның чын исеме Карбыш булуы бик мөмкин, чөнки элеккеге Болгар дәүләте территорияләрендә урнашкан татар авылларында Карбыш, Кармыш, Курмыш нәселләренең шәҗәрәләре еш очрый.

Эзләнү барышында, тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәтле микротопонимнар соклану тудырды. Мәсәлән, Бишказак әрәмәсе. Легендаларга караганда, Карабаш би үзенең алае белән кайтып килгәндә, безнең якларның матурлыгына сокланып туктый. Бер бик матур, калын әрәмәлекне күреп, шунда биш казак белән яшеренә һәм яшәп кала. Шуннан соң бу әрәмәне Бишказак әрәмәсе дип йөртәләр.

Тагын бер легенданың эчтәлегенә караганда, Карабаш би хәтта чирмешләрнең Тамбикә исемле кызына өйләнгән дигән мәгълүмат та бар. «Каравыл тау» астыннан агып чыккан чишмә »Тамбикә» исемен йөртә. Бәлки, Карабаш би, исеме тарихта калсын дип, чишмәне хатыны исеме белән атагандыр.

Авылыбыз Бөгелмә Бәләбәй калкулыгында урнашкан. Аны төрле яктан уратып алган һәр калкулыкның исеме бар ( калкулыкларны элек-электән тау дигәннәр). Иң биек тауларыбызның берсе – Каравыл тавы. Балалар аны «Миру-Мир»тавы дип йөртәләр. Элегрәк, Советлар Союзы чорында тауның иң югары өлешенә тау ташыннан шундый лозунг языл-

ган иде, ә хәзер анда Карабаш дип язылган. Каравыл тау таулар тезмәсе арасында иң биеге булганга, хәрби вазифаны үтәгән. Көньяктан яки көнбатыштан килүче атлы җайдакны берничә чакрымнан күрергә мөмкинлек биргән. 1964 нче елда үзенең Татарстанга визиты вакытында Н. С. Хрущев Каравыл тауның түбәсенә менә. Дәүләт җитәкчесе менәр өчен ясалган өр-яңа юл «Хрущев юлы» исеме белән тарихка кереп кала.

Бур тавы, Йөрәк тавы, Хәмит тавы, Коелы кул, Аргы һәм Бирге Чүмәлә таулары, Аркылы тау, Очлы тау, Бакыр тавы ( олылар сөйләвенә караганда, элек монда бакыр таба торган булганнар, ә аңардан бизәнү әйберләре ясаганнар), Чишмәле тау, Күч килде, Каратай тавы, Билдәү, Чагыл тавы, Даулы кул, Кызлар тавы, Кәкре кар, Каенлы кул, Каран тавы, Биектау, Мөхәммәтрәхим сырты – тауларыбызның атамалары.

Екатерина юлын халык телендә «Әби патша юлы» диләр. Авыл эченнән уза торган юл Екатерина II идарә иткән елларда салынган була. Шоколад юлның исеме нефтьчеләр килүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Түбәнгә төшә торган Ак тау юлы кызыл балчыктан торганга күрә, яңгырларда үтеп йөрмәслеккә әйләнә. Бу балчык төсе белән шоколадны хәтерләтә, шуңа күрә нефтьчеләр юлны «Шоколад юл» дип атаганнар.

Бүгенге көндә бистәбездә иллегә якын урам бар, һәрберсенең үз исеме. Алар тарихи шәхесләр, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы геройлары, фән, әдәбият, мәдәният хезмәткәрләре исемен йөртә. Карабашыбызда яшәгән олуг шәхесләребезнең исемнәре белән бәйле урамнарыбыз да бар.

Карабашы Республикабызның көньяк-көнчыгышында Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгында урнашкан бу төбәкне «Татарстанның Швейцариясе» дип тә атыйлар. Вак елгалар, күлләр, чишмәләр күп булганга, халык шулай атагандыр. Иң зур сулыкларыбызның берсе – Зәй елгасы. Дала Зәе белән Урман Зәе кушылган урыннан башланып, Чулманга коя.

Күлләребезнең дә исеме яңгырашлы: Әюп күле, Үрдәк күле, Зәңгәр күл. Хәзер дә халыкка су чыганагы булган

коеларыбызның исемнәре буыннан буынга сакланып килә: Шәмкәч коесы, Имат коесы, Кара кое, Олы урам коесы.

Һәр ишмәнең үз исеме бар.

«Изгеләр чишмәсе», «Изгеләр кизләве» – боларның барысы да нинди дә булса тау, үр, яр астынарак урнашкан булыр. Калкулыкта, тау битендә, гадәттә, «Изгеләр зираты» яисә «Изгеләр кабере» торыр. Шул рәвешле изге чишмәләр турыдан-туры башка изге урыннар белән бәйләнгән булып чыга. Бездә дә Изге чишмә бар, ул Әхмәт төбәгендә (хәзерге Матросов исемендәге урамда) урнашкан. Гомәр абый Сәйфиев язуларыннан: «Әхмәт төбәгендә иске зират бар. Бу зират, сөйләүләргә караганда, кайсыдыр көчле бер чир халыкны кырган елны барлыкка килгән. Бу зират бер көндә үлүчеләр белән тулган диләр. Бу 1831 нче елга туры килә».

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, микротопонимнарның барлыкка килүе – җәмгыятьнең яшәү чорына хас күренеш. Аларның чыганаклары еракка, борынгы тарихка барып тоташа. Гасырлар үтү белән, кайберләре онытылса да, күбесе халык хәтерендә яши бирә. Алар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, көнкүреш үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрне һәм традицияләрне чагылдыра.

# СОСТОЯНИЕ И ПУТИ СОВЕРШЕНСТВОВАНИЯ ЯЗЫКОВОГО ОБРАЗОВАНИЯ В УСЛОВИЯХ ГОСУДАРСТВЕННОГО ДВУЯЗЫЧИЯ

**Хайбуллина Г. М.,**
**учитель татарского языка и литературы, МБОУ лицей № 2 Бугульминского муниципального района РТ**

В 1992 году был принят закон «О языках народов Республики Татарстан», согласно которому, татарский и русский языки являются равноправными государственными языками. Это сделало межкультурное взаимодействие неотъемлемым фактом повседневного общения.

Татарский язык изучается во всех общеобразовательных школах Республики Татарстан как обязательный учебный предмет для учащихся владеющих татарским языком, как родным и русскоязычных учащихся. В связи с этим возник вопрос о формировании межкультурной компетенции русскоязычных учащихся в процессе обучения татарскому языку.

Рассмотрим понятие «Межкультурная компетенция». Межкультурная компетенция – это знание культурных особенностей носителей языка, их привычек, традиций, норм поведения и этикета, умение понимать и адекватно использовать их в процессе общения, способность успешно общаться с представителями других культур, оставаясь при этом носителем другой культуры. Эта способность может появиться с молодых лет или может быть развита.

В структуру межкультурной компетенции входят:

- общекультурологические и культурно-специфические знания.
- умения практического общения.
- межкультурная психологическая восприимчивость.

Основой развития межкультурной компетенции несомненно является изучение культуры татарского народа.

Это неразрывно связано с целями изучения татарского

языка в общеобразовательной школе, среди которых:

- формирование коммуникативной компетенции в основных видах речевой деятельности (аудирование, говорение, чтение, письмо);
- развитие личности школьника, его познавательных и речевых способностей;
- повышение мотивации к практическому овладению татарским языком как средством межличностного общения, компетентность в межкультурном диалоге;
- формирование уважения и толерантности к татарскому народу, его истории, приобщение к культурным ценностям и национальным традициям татарского народа, что является залогом межнационального согласия и взаимопонимания.

Таким образом, можно считать, что конечной целью обучения является формирование и развитие межкультурной коммуникативной компетенции русскоязычных учащихся, что включает в себя знание моделей общения, культурных стереотипов, ценностных ориентиров, образов и символов культуры. Это подразумевает такой уровень владения татарским языком, который бы обеспечивал учащимся свободное общение с представителями татарской или иной культуры без психологических барьеров.

Какими же методами и формами можно сформировать межкультурную компетенцию русскоязычных учащихся в процессе обучения татарскому языку?

1. Словесные (лекции, дискуссии, работа с Интернет - материалом). ***Сфера использования при обучении: п***олучение информации о роли межкультурной компетенции при межкультурной коммуникации, информации о культуре как о теоретическом конструкте: рамки культуры, основные характеристики культуры, основные типы взаимоотношения между культурами.
2. Объяснительно-иллюстративные (объяснение, дис-

куссии). ***Сфера использования при обучении:*** обсуждение культурно-заостренного материала в сообществе, обсуждение результатов переписки с одноклассниками в сообществе.

3. Информационно-рецептивный. ***Сфера использования при обучении:*** получение новой информации в процессе общения в сообществе.
4. Интерактивный. ***Сфера использования при обучении:*** в процессе выполнения заданий учащиеся вовлекаются в процесс взаимодействия с партнерами по группе в сообществе, а также между собой при обсуждении информации.
5. Коммуникативный. ***Сфера использования при обучении:*** обучающиеся вовлечены в процесс общения с целью выражения, обсуждения и интерпретации информации посредством общения в группе. Татарский язык выступает основным средством общения.
6. Методы контроля. ***Сфера использования при обучении:*** самоконтроль в конце процесса обучения.
7. Организация проектной деятельности с использованием ИКТ и интернет-технологий.

Алгоритм формирования межкультурной компетенции средствами ИКТ.

Организация всей проектной деятельности школьников будет представлена в 10 шагах:

**Шаг 1:** *Учащиеся и педагог выбирают тему проекта*.

**Шаг 2:** *Учащиеся и педагог определяют конечный продукт проекта.*

**Шаг 3:** *Учащиеся и педагог структурируют проект.*

**Шаг 4:** *Педагог объясняет учащимся требования, предъявляемые к сбору информации.*

**Шаг 5:** *Учащиеся собирают информацию.*

**Шаг 6: Педагог** *объясняет учащимся как соединять воедино и анализировать различные сведения.*

**Шаг 7:** *Учащиеся обобщают и анализируют информацию.*

**Шаг 8: Педагог** *объясняет учащимся требования, предъявляемые к использованию языка на последнем этапе работы.*

**Шаг 9:** *Ученики делают презентацию конечного результата.*

**Шаг 10:** *Учащиеся оценивают проект*

Алгоритм реализации проектной деятельности учащихся, состоящий из трех этапов.

**Этап 1:** *Планирование проекта:* учитель и ученики обсуждают масштаб и содержание своего проекта на татарском или на русском языке. На этом этапе обсуждаются и намечаются определенные языковые средства, которые потребуются при выполнении проекта, а также конечный продукт (результат).

**Этап 2:** *Реализация проекта:* этот этап может включать такие виды деятельности, как опрос прохожих на улице, анкетирование сверстников, учителей, родителей и т.д. Учащимся на данном этапе необходима поддержка и мониторинг со стороны учителя.

**Этап 3:** *Создание конечного результата,* который должен быть вполне конкретным. Он может быть представлен в самых различных формах – презентациии, стенгазета, журнал, Web-сайт, сочинение или изложение, эссе для обсуждения в сети и т.д. Целесообразно пригласить коллег и других учащихся на презентацию конечного результата.

Предложенные этапы проекта носят общедидактический характер и могут быть использованы для реализации любого типа проекта.

Содержание УМК Р.З. Хайдаровой «Весёлый татарский язык» (1-4 классы) позволяет создать виртуальные сообщества и включить изучаемые циклы в учебный процесс. Так же возможно использование индивидуальных и групповых **форм взаимодействия** между педагогом и учащимся и группой учащихся при индивидуальной переписке с партнерами по проекту.

Обсуждение результатов данной переписки, итогов проектной работы и рефлексия будут проводиться в классе.

Таким образом между учениками происходит воздействие друг на друга. Возникает желание что-либо сказать, о чём-нибудь спросить, либо ответить на вопрос собеседника. Общение проходит очень интересно.

Обучение русскоязычных детей разговорной речи достигается через диалог, поэтому, мы составляем диалоги на разные ситуации. Однако, просто диалоги утомляют учеников. Для того чтобы заинтересовать своих учеников я использую различные слайды. На поиски слайдов включаются и ученики, они самостоятельно находят слайды на разные темы и составляют диалоги в парах и группах. В процессе составления диалога идет активное запоминание слов и словосочетаний, ученики придумывают интересные фразы и выражения и вводят их в свой лексикон.

Использование ИКТ, в педагогической деятельности, дает возможность включать различные виды работы. Например:

1. Работа с текстом. С помощью презентаций очень удобно проводить словарные, проверочные диктанты или контрольное списывание. Для этого на одном слайде я даю предложения с пропущенными буквами или тексты с орфографическими ошибками. После выполнения работы, ученики обмениваются тетрадями и проверяют друг - друга по следующему слайду. Пропущенные буквы и орфографические ошибки выделяю другим цветом. На следующем слайде показываю критерии оценки работы. В данной ситуации появляется возможность проверить правильность выбранных вариантов ответов, а не только их сравнивание. В случае безошибочных работ ученики хвалят друг – друга, а если находят ошибки стараются объяснить своим одноклассникам ошибки и закрепляют примерами.
2. Переставляя местами слова и словосочетания, состав-

ляют связанный по смыслу текст.

3. На своих уроках часто использую ребусы, головоломки, кроссворды из интернет – сайта. Ученики с большим интересом выполняют такие работы, и сами совместно с родителями составляют ребусы, головоломки и кроссворды. На уроке обмениваются своими работами, выполняют их и делают выводы.
4. Пересказ стихотворения своими словами и составление сюжета по содержанию развивает творческое мышление учеников. Учит самостоятельности. Данный вид работы помогает раскрыть способность учеников.

Основной задачей формирования межкультурной компетенции является развитие умения выражать свои мысли на заданную тему. Приведенные выше виды работ могут быть различными и должны использоваться с учётом уровня коммуникативных навыков учащихся.

Таким образом, развитие межкультурной компетенции учащихся начальной школы является важной проблемой, решение которой должно находить отражение в повседневной деятельности учителя татарского языка.

## ПОЛИЛИНГВИЗМ ШАРТЛАРЫНДА ТЕЛНЕ ӨЙРӘТҮ

**Харисова Р. С.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче**
**5 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Илебездә дистәләрчә телдә сөйләшүче күп төрле халыкларның туганнарча дус, хезмәттәшлек итеп яшәүләре, аларның милли мәдәниятләре, телләре чәчәк ата бару – җәмгыять казанышы. Һәр милләт кешесе өчен:

Иң моңлы көй – милли көй,
Иң матур тел – милли тел.

Чал тарихка барып тоташа торган туган телебез бүгенге көндә иң бай телләрдән санала. Ләкин соңгы елларда татар телен өйрәнүгә, аны сөйләмдә куллануга карата кызыксынуның көнән-көн кимүе, бик күпләрне, шул исәптән мине дә борчый һәм бу проблема бүгенге көндә дә бик актуаль. Мин, әлбәттә, республикамда күптеллелек булуына һәм телләр, мәдәният төрлелегенә, толерантлыкка хөрмәт белән карыйм. Тик шулай да туган телемнең киләчәге турында уйланулар мине полилингвизм шартларында җәмәгатьчелекне республикабыздагы татар телен өйрәнүнең торышы һәм үсеш перспективасы белән таныштыруга этәрде. Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым:

1) татар телен өйрәнүгә кызыксынуның кимүе сәбәпләрен ачыклау;

2) полилингвизм шартларында татар телен өйрәнү торышы, бу өлкәдәге проблемаларны күрсәтү;

3) халыкта татар телен өйрәнүгә һәм куллануга стимуллаштыру чараларын ачыклау.

Нәрсә соң ул тел? «Авыз күрке – тел, тел күрке – сүз», – дигән халык. Тел – кешеләрнең үзара аралашу чарасы. Тел – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Тел кешеләргә бер-берсен

аңларга, бер-берсенең теләген, максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә. Рус педагогы К. Ушинский телнең шәхесне тәрбияләү һәм үстерүдәге әһәмияте турында: «Халыкның теле – аның рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә халык һәм аның Ватаны җанлы рәвеше гәүдәләнә, телдә халыкның бөтен рухи тормышының тарихы чагыла,» – дигән.

Телне бөек хәзинә, диләр. Табигатьтәге һәр нәрсә үзенчә байлык түгелмени?! Тел байлыгын, кыйммәтен ничек белергә? Сүзләрнең күплеге, сөйләшүчеләрнең саны беләнме? Озак яшәүчәнлеге, кешеләр үсешенә керткән өлеше беләнме? Бу әйтелмәләр барыбер төгәл билгеләмә түгел. Һәр тел үзенчә бөек. Җир йөзендә телләр бик күп. Аларның төгәл санын әйтү дә кыен. Телләрнең күптөрлелеге полилингвизмның да төрле формалары булуга китерә: индивидуаль, төркемле (групповой), региональ, дәүләт полилингвизмы (бу төр дәүләттә бердән күбрәк дәүләт теле булган илләр өчен хас). Безнең республикада полилингвизмның барлык төрләре дә күзәтелә. Аеруча киң формалары булып, төркемле билингвизм (милли-милли, милли-рус) һәм трилингвизм (ике милли һәм рус теле, өч милли тел санала). Лингвистлар һәм башка белгечләр әйтүе буенча икетеллелек һәм күптеллелек үсү динамикасы саклаcount. Барыбызга да билгеле, телләр бер-берсеннән башка яши алмый. Шагыйрь Р. Юнысов телләр үсеше турында: «Телләр үлми! Үлә бары телен җуйган халыклар!» («Үлми телләр») – дип яза. Ләкин, кызганычка каршы, телләр мамонтларга караганда – ике, кошларга караганда дүрт мәртәбәгә тизрәк юкка чыга бара.

Моның сәбәбе нәрсәдә икән соң? – дигән сорауга җавап эзләп карадым. Көннән-көн тормышыбызга күбрәк үтеп кергән инглиз телеме? Яисә өлкән буын кешеләренең яшь буынның туган телдә сөйләшүенә ваемсыз каравымы? Әллә әхлакның түбән булуыннанмы?

Туган телебез – татар теле бүген ни хәлдә соң?! Заманында халыкара телләрнең берсе булган, бөтендөнья күләмендә

сөйләшер өчен уңай ун-унбиш тел арасында саналган телебез ни хәлдә? Сораулар катлаулы һәм авыр. Телнең бөеклеге турында абстракт фәлсәфә чоры үтте. Халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул – тулы милләт, яртысы сөйләшә икән – ярымйорты милләт, биштән бере генә сөйләшсә? Телебез аңлауга, ярдәмгә, яклауга мохтаҗ.

Минемчә, безнең республика халыкларының күпчелеге ике телдә сөйләшүен истә тотып, милли телне, шулай ук рус телен һәм дә чит телне өйрәнү өчен дә шартлар тудырырга кирәктер. Без, әлбәттә, мәктәптә бу телләрне өйрәтәбез. Безнең максатыбыз шундый: балаларны үз телебездә һәм чит телләрдә сөйләшергә өйрәтү. Без укучыларның игътибарын татар теленең чит тел белән бәйләнешенә юнәлтәбез. Нәтиҗәдә, алар дәресләрдә татар һәм инглиз телендә күп кенә охшаш авазлар һәм грамматикада уртаклыклар күп икәнлегенә төшенә. Шунысы куанычлы: безнең мәктәптә татар телен яхшы белгән балалар чит телне дә, рус телен дә яхшы үзләштерә. Бу бик мөһим, чөнки татар һәм рус телләре безнең дәүләт телләребез булса, хәзергесе вакытта чит телне дә белү бик кирәк дип уйлыйм. Моның сәбәпләре берничә: хәзер чит илләргә чыгу мөмкинлекләре зур, димәк ул телне аңлау, аралашу зарур дигән сүз. Шулай ук күп оешмаларда эшләү инглиз телен белүне таләп итә. Үз халкыңның тарихын, мәдәниятен белү белән бергә, башка халыклар культурасы турында белем алу чыганагы булып та чит телләрне белү кирәклеге тора.

Руслашкан шәһәребездә күп милләттәшләремнең туган телендә сөйләшә белмәве, ана телебезне бозып сөйләү, татар телен өйрәнүгә кызыксынуның көннән-көн кимүе күңелне борчый. Бу турыда шагыйрьләребез дә әйтә килделәр һәм хәзер дә язалар. Мәсәлән, Дәрдемәнд:

«...Урысча күп сүзең, азы татарча,
Беләалмыйм, кем син - урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:

Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?» – дип язса, шагыйрь Равил Фәйзуллин:

«Ана телне ватып – бозып сөйләп,
кешелегең генә төшә бит!
Корама тел, яман чир булып,
яңа буыннарга күчә бит!» – дип яза «Туган тел турында бер шигырендә.

Халык массаларында татар телен өйрәнүгә һәм куллануга стимуллаштыручы чаралар турында күп уйландым. Беренчедән, без туган телебезнең төрки телләр составына кергәнен беләбез, шуңа күрә гарәп, фарсы, үзбәк, казак һәм башка телләрне үзләштерү татар телен белүчеләр өчен күп мәртәбәгә җиңелрәк. Алай гына дә түгел, хәтта кытай телен дә... Моны белгәч, үзем дә гаҗәпкә калдым. Күптән түгел мәктәбебезгә хәзерге вакытта Санкт- Петербург университетының лингвистика факультетында укучы чуваш егете Соколов Александр килгән иде. Ул миңа зур рәхмәтләрен җиткерде. «Татар телен яхшы белүем миңа кытай телен өйрәнүдә зур ярдәм итә, ә [ң] авазын миннән башка беркем дә дөрес куллана белми», – диде ул. Казанда югары уку йортына укырга кергән рус егете Дагаев Кирилл да мәктәптә татар телен тырышып өйрәнүенә бары тик сөенә генә. Ул аңа курсташлары белән аралашу өчен бик кирәк икән. Икенчедән, башка милләт кешеләренең безнең белән аңлашу-аралашу мөмкинлеге барлыкка килә. Өченчедән, дәүләтебезнең сәясәтенә игътибар итсәк, дәүләт аппаратында эшләүче хезмәткәрләрнең ике дәүләт телен дә белүенә өстенлек биреләчәк. Дүртенчедән, без – татарлар, өлкән буын кешеләре белән туган телебездә сөйләшсәк, алар безгә карата уңай мөнәсәбәттә булачак. Бишенчедән, һәр кеше туган телен белергә тиеш дип уйлыйм. Ана телен яхшы белгән кеше генә милләте белән горурлана, аның кадерен белә.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: мин – татар милләтеннән. Татар булуым белән горурланам. Туган телемдә бик яратып сөйләшәм. Башка телләрне хөрмәт итәм. Шуңа карамастан, татар телен белүнең һәм балаларда татар телен

өйрәнүгә, аны сөйләмдә куллануга кызыксыну уятуның никадәр мөһим икәнлеген, бу хезмәтемне язганда, тирәнрәк аңладым. Күпме укучы, кеше бу турыда уйланмый, белми?! Шуңа күрә бу мөһим мәсьәлә – татар телен белүнең зарурлыгын пропагандалау гаиләдә дә, (тел гаиләдә саклана бит), мәктәптә дә, җәмәгатьчелек тарафыннан да алып барылсын иде. Күп милләтле мохит шартларында татар балаларының барысы да татар һәм рус телләрендә яхшы итеп сөйләшә белсә, башка милләт балалары татар телендә дә аңлаша алса, без максатыбызга ирешкән булырбыз. Туган тел турындагы фикерләремне шагыйрь Р. Мингалимов сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

Яхшы гына беләм мин үз телемне,
Дуслар белән сөйләшәм дус телендә.
Хөрмәт итә белгәч инде үз телем,
Хөрмәт итә белермен, дим, дус телен.

# ЗӘКӘРИЯ ӘХМӘРОВНЫҢ «ӘЛӘКЧЕ» ХИКӘЯСЕНДӘ ТӘРБИЯ ПРОБЛЕМАСЫНЫҢ КУЕЛЫШЫ
**(рус төркеме, 6-в сыйныфы)**

**Гомәрова М. Җ.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы МБГББУ**
**16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**

**Максат:**

— темага караган 12 сүзне актив кулланылышка кертү; укылган текстның эчтәлеген үзләштерү; план буенча эчтәлеген сөйләргә өйрәтү;

— укучыларның сораү-җавап имитацияле диалогик сөйләм; сәнгатьле уку һәм тәрҗемә, монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү;

— әләкләшү-начар гадәт икәнлегенә төшендерү; укучыларда әдәплелек, гаделлелек, намуслылык, бер-береңә ихтирамлылык кебек кешегә хас сыйфатларны тәрбияләү.

Җиһазлау: «Татарча да яхшы бел»: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 6 кл.: 2 кисәктә: 2 кисәк / Р.Р.Нигъмәтуллина; [рәссамнары: А.Айсена, В.Фомин]. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2014. – 111б.: рәс. б-н., ноутбук, мультимедиа-проектор, презентация, таблицалар, конвертлар, ак битләр, тестлар.

Дәрес тибы. Йомгаклау дәрес.

Дәрес төре. Сөйләм күнекмәләрен үстерү дәресе.

Белем бирү методы. Үстерешле укыту методы.

Предмет эчендә бәйләнеш. Татар теле, уку.

Предмет-ара бәйләнеш. Рус теле.

**Дәрес барышы:**

***I. Актуальләштерү.***

*Укытучы:* – Исәнмесез, укучылар!

*Укучылар:* – Исәнмесез,

Хәерле көн телибез без

Сезгә чын-чын күңелдән.
Укытучы:
— Бүген айның ничәнче көне?
— Атнаның кайсы көне?
— Бүген һава торышы нинди?
— Сыйныфта кемнәр юк? Ни өчен?
***Ситуатив күренеш.***
Ишек ачыла. Бер укучы кыз керә. Ул ашыгып:
— Мөсфирә Җиһаннуровна, Лилия урамда уйнап йөри. Ул авырмый. Алдашып,
мәктәпкә укырга йөрми. Үзем күрдем.
*Укучылар:*
*Әләкче, әләкче,*
*Әллә ниләр белмәкче,*
*Әллә кая үтмәкче,*
*Әллә ниләр әйтмәкче,*
*Беркөн дуслары сизәр,*
*Аннан бары да бизәр.*
*Укытучы:*
— *Укучылар, тынычланыгыз...*
— Айгөл, син дә тынычлан. Бар, урыныңа утыр.
— Укучылар, Айгөл хәзер нинди хаталар ясады?
Укучылар:
— Ишекне шакымый керде.
— Соңга калды.
— Исәнләшмәде.
— Дәресне бүлде.
— Гафу үтенмәде.
— Әләкләште.

*Укытучы:* - Әйе, Айгөл бик күп хаталар ясады. Ул безнең дәрестә катнашып, үзенең хаталарын аңлар һәм төзәтер дип ышаныйк.

***II. Белем күнекмәләрен камилләштерү.***

**1. Фонетик зарядка.**

*Укытучы:*
— Укучылар, «кешеләргә хас сыйфатларны» кабатлыйк
Слайд. **Кешеләргә хас сыйфатлар.**
Ялганчы Тупас
Гәйбәтче Ярдәмчел
Тыйнак Намуслы
Гадел Кызганыч
Максатчан Битараф
Игелекле Әләкче
— үзем укыйм; укучылар кабатлыйлар;
— укучылар чылбырлап укыйлар һәм рус теленә тәрҗемә итә баралар.
Укытучы:
— Укучылар, кешеләргә хас сыйфатлар ничә төрле була? Нindиләр?
Укучылар:
— Ике төрле.
— Уңай һәм тискәре була.
Укытучы:
— Кешеләргә хас сыйфатлар арасыннан уңай сыйфатларны гына әйтегез.
— Хәзер тискәре сыйфатларны гына әйтегез.
Слайд. **Рәсемнәр.**
— Бу кем?
— Шәвәли.
— Шәвәлидә кешеләргә хас нинди сыйфатлар бар?
— ТЫЙНАК
— ГАДЕЛ
— ИГЕЛЕКЛЕ
— ЯРДӘМЧЕЛ
— НАМУСЛЫ
— ӘДӘПЛЕ
— Ә бу кем?
— Кирлемән.

— Ә Кирлемәндә кешеләргә хас нинди сыйфатлар бар?
— ЯЛГАНЧЫ
— КЫЗГАНЫЧ
— МАКТАНЧЫК
— ТУПАС
— ӘЛӘКЧЕ
— БИТАРАФ

Укытучы:

— Димәк, сез уңай һәм тискәре сыйфатларны дөрес әйткәнсез?
— Уңай сыйфатлар белән җөмләләр төзегез.
— Тискәре сыйфатларны кертеп, җөмләләр төзегез.

2. Өй эшләрен тикшерү.

— Өйгә нинди эш бирелгән иде?
— 39нчы бит; 9нчы, 11 нче күнегүләр. Укырга, сорауларга җавап бирергә.
— Сорауларга җавапларыгызны тикшерик (рәтләп) (сорау-җавап, парлы эш)

Сораулар.

1. Ни өчен классташлары Мидхәтне әләкче диләр?
2. Балалар кемне акылга өйрәтергә булдылар?
3. Ул иптәшләрен кемгә әләкли?
4. Ни өчен укытучы ватык тәрәзәне таба алмады?
5. Мидхәт укытучыга ватык тәрәзәне ни өчен күрсәтә алмый?
6. Укытучы малайга нәрсә дип әйтә?

III. Яңа тема.

Укытучы: Бүген дәрестә «Әләкләшү – нинди гадәт?» дигән сорауга Зәкәрия Әхмәровның «Әләкче» хикәясе аша җавап эзләрбез, хикәяне өлешләргә бүлеп, эчтәлеген сөйләргә өйрәнербез. Хикәянең герое Мидхәткә бәя һәм киңәшләр бирерсез.

— Дәфтәрләргә число һәм теманы языгыз.

39нчы бит, 9нчы күнегүне табыгыз. Хәзер бу хикәяне

аудиоязмадан тыңларсыз, өлешләргә бүлергә әзерләнегез (тыңлату).

Безнең класста Мидхәт исемле бер малай бар. Белсә дә сөйли, белмәсә дә сөйли. Дөресен генә әйтсәк, әләкче ул. Күрсә дә, күрмәсә дә гел укытучыны эзләп китә. Әйткән сүзе дөрес булмаса, мин класста ишеттем, миңа теге әйтте, бу әйтте, дип аклана. Күзен дә йоммый. Менә шундый малай ул.

Беркөнне без бу әләкче малайны акылга өйрәтергә булдык. Озын тәнәфес вакыты иде. Мин Мидхәт янына килдем дә әкрен генә:

— Тәрәзәне ваттылар, – дидем.

Мидхәт, күзләрен зур ачып:

— Кемнәр? – дип сорады.

— Фатих бугай (кажется).

Мин әйтеп тә бетермәдем, Мидхәт инде укытучылар бүлмәсенә таба китте. Озак та үтмәде, аннан безнең класс җитәкчесе чыкты. Ул башта безнең классыбызны карады, башка классларга да керде, ләкин ватык тәрәзәне таба алмады. Аннан соң безгә Мидхәтне эзләргә кушты.

Без аны чишенү бүлмәсендә таптык. Тәрәзәдән карап, тыныч кына печенье ашап тора иде.

— Тәрәзәне кем ватты дидең, Мидхәт? – диде укытучы.

— Фатих инде, Фатих!

Без көлеп җибәрдек.

— Авырый ич ул Фатих! Бүген укырга килмәде, – дидек.

— Кайсы тәрәзә ватык соң, күрсәт әле.

— Белмим мин ... үзем... күрмәдем.

— Күрмәсәң ник сөйлисең?

Мидхәт оятыннан кып-кызыл булды, нәрсәдер әйтергә теләде, тик авызыннан сүзе чыкмады.

**3. План төзетү.**

Укытучы:

— Хикәяне ничә өлешкә бүлергә була? (3 өлешкә)

— lнче өлешне табып укыгыз;

— Бу өлешкә исем бирегез.
— 2нче өлешне табып укыгыз.
— Бу өлешкә исем бирегез.
— 3-нче өлешне табып укыгыз.
— Бу өлешкә исем бирегез.

План.

1. Әләкче Мидхәт.
2. Акылга өйрәтү.
3. Мидхәткә бик оят.
4. Слайд. Фотосурәтләр.

*Укытучы:* **– Бу рәсемнәр хикәянең кайсы өлешенә туры килә?**

lнче рәсем − планның пунктын укыту. Сез ризамы?

Әләкче Мидхәт.

2-нче рәсем-планның пунктын укыту. Сез ризамы?

Акылга өйрәтү.

3-нче рәсем − планның пунктын укыту. Сез ризамы?

Мидхәткә бик оят.

5. Укучыларның дәфтәрләренә планны яздырту
6. Слайд. Фотосурәтләр.

Планның һәр пункты буенча хикәянең эчтәлеген сөйләтү:

— 1нче рәт планның 1 нче пункты буенча эчтәлеген сөйли;
— 2нче рәт планның 2нче пункты буенча эчтәлеген сөйли;
— 3нче рәт планның 3нче пункты буенча эчтәлеген сөйли.

7. Кем хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләр?
8. Физминутка.

— Ә хәзер ял итик.

Кош рәсеме буенча уен (күзләрне ял иттерү).

**9. Мидхәткә бәя бирү (хикәянең төп герое турында сөйләшик).**

*Сораулар.*

1. Хикәянең төп герое кем?
2. Мидхәттә кешеләргә хас сыйфатларның кайсылары күбрәк?
3. Мидхәт сезгә ошадымы? Ни өчен?
4. Сиңа әләкчеләр ошыймы?
5. Синеңчә, әләкләү нинди гадәт?
6. Гадәттә, кемнәр һәм кемнәргә әләкли?
7. Әләкчене башка балалар ярата мы?
8. Әләкче чын дус була аламы?
9. Син үзең әләклисеңме? Әллә һәрвакыт дөресен генә сөйлисеңме?

**Укытучы:** – **Укучылар, Мидхәткә нинди киңәшләр бирер идегез**?

— Мидхәт, әләкләргә ярамый! – Мидхәт, әләкләү – начар гадәт!

— **Мидхәт,** әләкчене башка балалар яратамый!

— **Мидхәт,** әләкче баланың дуслары күп булмый!

— **Мидхәт,** әләкче чын дус була алмый!

— **Мидхәт, һ**әрвакыт дөресен генә сөйлә!

Укытучы:

— **Хикәянең герое кебек, Айгөл дә күп хаталар ясады.**

— Айгөл, син нинди хаталар ясадың?

Айгөл:

— Ишекне шакымый кердем.

— Соңга калдым.

— Исәнләшмәдем.

— Дәресне бүлдем.

— Гафу үтенмәдем.

— Әләкләштем.

Укытучы: -Укучылар, сез Айгөлгә нинди киңәшләр бирер идегез?

Конвертта ак битләр. Сез бу битләргә Айгөлгә үзегезнең киңәшләрегезне языгсыз. (Укучылар киңәшләрен укыйлар).

Киңәшләр язылган конвертларны Айгөлгә тапшыру.

**10. Айгөл белән сөйләшү.**

Укытучы:

— Айгөл, хаталарыңны аңладыңмы?

— Айгөл:

— Әйе, хаталарымны аңладым. **Әләкләү - начар** гадәт. Әләкче баланың дуслары күп булмый, шуңа күрә мин һәрвакыт дөресен генә сөйләрмен.

**11. Тест эшләү.**

*Укытучы:*

— Кешедә нинди сыйфатларның күбрәк булуы яхшы? (тестлар тарату)

Мидхәтнең нинди тискәре сыйфаты бар?

а) ул ялганчы

б) ул әләкче

в) ул мактанчык

Ул башка балаларны кемгә әләкли?

а) әнисенә

б) укытучыларга

в) мәктәп директорына

Классташлары Мидхәтне нәрсәгә өйрәтергә булдылар?

а) чисталыкка

б) математикага

в) акылга

Укытучы кабинетларга кереп нәрсә эзли?

а) ватык урындыкны

б) ватык өстәлне

в) ватык тәрәзәне

Тәрәзәне кем ваткан?

а) Фатих

б) Мидхәт

в) беркем дә ватмаган

Мидхәт ни өчен кып-кызыл булган?

а) чөнки ул курыккан

б) ул оялган

в) аның ачуы килгән

Тестларны җыеп алу.

**12.** ***Йомгаклау һәм укучыларга билгеләр кую.***

Дәрестә кемнең хикәясе белән таныштык? Хикәянең исеме ничек?

Әләкләшү – нинди гадәт?

Әләкче чын дус була аламы?

Хикәя сезгә ошадымы? Ни өчен?

**13. Өй *эше.***

Сез Мидхәт урынында булсагыз, нишләр идегез? Үз фикерләрегезне белдереп, берничә җөмлә языгыз.

## МӘКТӘП – ТЕАТР ТҮГЕЛ ... SCHOOL IS NOT A THEATRE

**Ихсанова Г.Ф.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Нестерова В.Н.,**
**инглиз теле укытучысы**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы МБГББУ**
**16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе**

Максат: 1) укучылар белән темага бәйле үткән заман сыйфат фигыльләрне, ясалма сыйфатларны, изафә бәйләнешен сөйләмдә аңлап кулланугa ирешү;

2) мәктәп һәм мәктәп формасына кагылышлы лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләрен булдыру;

3) укучыларда мәктәпкә һәм мәктәп формасына карата сакчыл караш тәрбияләү.

Җиһазлау: дәреслек («Татарча да яхшы бел», 10 нчы классы өчен татар теле дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) / Р.Р.Нигъмәтуллина. – Казан: Мәгариф, 2010; «Enjoy English» для 10 класса (Биболетова М. З., Добрынина Н. В., Трубанева Н. Н. – Английский с удовольствием / – Enjoy English‖: Учебник для 10 класса общеобразовательных учреждений. – Обнинск: Титул, 2011)), магнитофон, диск, компьютер, фотографияләр, эш дәфтәре.

Дәрес тибы: йомгаклау һәм белемнәрне системага салу (обобщение и систематизация знаний).

Дәрес төре: интеграль.

Сыйныф: 10, рус төркеме

Дәрес барышы:

**I. Оештыру өлеше.**

– Исәнмесез, укучылар. Хәерле көн.

**II. Актуальләштерү.** Үткән дәресләрдә алган белемнәрне ныгыту өчен сораулар:

1. – Укучылар, бирелгән сүзләр белән сүзтезмәләр төзегез

һәм татарчадан русчага тәрҗемә итегез. Бу сүзләр безгә дәрес темасын ачыкларга ярдәм итәр.

*(Слайд №2:* хосусый, дәүләт, башлангыч, урта, фәннәрне тирәнтен өйрәнүче, гомуми белем бирүче = мәктәп/мәктәбе).

– Бу сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп әйтегез. (Көтелгән җаваплар: Харроу мәктәбе – хосусый мәктәп. Америкада хосусый мәктәпләр дә, дәүләт мәктәпләре дә күп. Башлангыч сыйныфта сеңлем укый. 11нче сыйныфта урта мәктәпне тәмамлыйбыз.Фәннәрне тирәнтен өйрәнүче кызлар мәктәбе.16 нчы мәктәп – гомуми белем бирүче мәктәп.)

2. *– ..., спроси у ..., в какой школе он учится?*

*..., спроси у ..., она частная школа?*

*..., спроси у ..., эта школа с углублённым изучением предметов?* (Юк, бу гомуми белем бирүче мәктәп)

*..., спроси у ..., есть* ли в школе классы с углублённым изучением отдельных предметов?

3. Инглиз телендә укучылар дәрес темасын һәм дәрес максатларын әйтәләр*: (*Слайд №3*)*

*Teacher: There are many rules at school. I'll read you the student's responsibilities and you should say whether they are true in our school.*

*1. Students should be in the classroom 5 minutes before the teacher and they mustn't leave before the lesson has ended.*

*2. Students should be polite to one another and to the teacher*

*3. Students are not supposed to chew gum in class.*

*4. Students mustn't use the following excuses if they haven't done their homework «The dog ate it»or «It fell out of my bag».*

*5. Students may not smoke in school.*

*6. Never cheat on a test*

*7. Raise your hand if you want to ask or answer the question.*

*Teacher: Ok! Thank you! Student what else you should do in school? How can we guess that pupil study at school for his or her appearance?(to wear a uniform). Thank you!*

*Answer to my question please: Why pupils should wear a*

*school unuform?*

*Pupils:*

*1. It Gives a common identity to the school*

*2.If all pupils wear the same type of clothes they look smart when they are together*

*3.Pupils whose parents can't afford nice clothes look the same as everyone else and don't feel inferior*

*Teacher: Look at the board! Here you can see a theme of our lesson.(* Слайд темы №4*)*

III. Төп өлеш.

**1. –** Димәк, инглиз телендә әйтеп киткәнегезчә, бүгенге дәресебезнең темасы «Мәктәп театр түгел...» Бүгенге дәрестә мәктәп формасының үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында өйрәнгән лексикаларны кулланып сөйләшүне дәвам итәрбез. Әйдәгез, алдагы дәресләрдә үткән лексиканы татар, рус һәм инглиз телләрендә кабатлап китик**.** Катя укый, ә калганнар тәрҗемә итә. Слайд №5:

— зәңгәр төстәге шакмаклы сарафан

— кесәсез буй-буй пиджак

— вак бөрчекле блузка

— кечкенә кесәле алъяпкыч

— якасыз кыска күлмәк

— зур төймәле кызыл пальто

— җиңсез бизәкле жилет

*(dress in a cage blue* – сарафан в полоску синего цвета

*jacket without pockets in the strip* – пиджак без карманов в полоску

*blouse in polka-dot* – блузка в мелкий горох

*apron with pockets* – фартук с маленькими карманами

*short dress without collar* – короткое платье без воротника

*red dress with large buttons* – красное пальто с большими пуговицами

*jacket patterned sleevless* – жилет без рукавов с узорами*)*

**2. – Укучылар, слайдта күрсәтелгән рәсемнәр буен-**

**ча татар һәм инглиз телләрендә җөмләләр төзеп әйтегез** (слайдтагы рәсемнәрне күрсәтәм, ә укучылар аларны татарча, инглизчә әйтәләр) Слайд № 6

(Көтелгән җаваплар:1нче рәсем. Кыз озын җиңле 3 төймәле зәңгәр пиджак, ак күлмәк, буй-буй куе кызыл итәк, кара туфли кигән. Чәчләре җыелган.

2нче рәсем. Кыз зур ак якалы, уртача буйлы озын җиңле күлмәктән, ак альяпкычтан, үкчәле туфлидан.

3нче рәсем.Ике кыз да бер төстәге, бер төрдәге (фасондагы)жилеттан һәм итәктән, озын һәм кыска җиңле киң якалы блузкадан киенгән, рәсемнәр буенча җөмләләрне инглиз телендә әйтәләр.)

3. – Укучылар, әйдәгез мәктәп формасының тарихы белән танышып китик. Дәреслекнең ... битен ачыгыз һәм диктор артыннан карап барыгыз. Мәктәп формасы безнең илгә кайчан һәм кайдан килгән? шул сорауга җавап әзерләгез (дисктан (трэк №11) текстны тыңлау). Слайд №7

Мәктәп формасының тарихы бик ерактан башлана. Ул безнең илгә Англиядән килә. 1834 нче елда Россиядә гимназиядә укучы ир балалар һәм студентлары өчен махсус форма кертү турында закон чыга. *1896 нчы елдан гимназиядә укучы кызлар өчен дә мәҗбүри махсус форма кертелә.* Санкт-Петербургның Смольный институтында укучы дворян кызлары өчен кием фасоннарын Екатерина *II* үзе тәкъдим итә.

Революциягә кадәр мәктәп формасы укучының дворян гаиләсеннән булуын күрсәтеп торучы кием булган. Гимназистлар мәктәп киемен дәресләрдә генә түгел, өйдә дә салмаганнар. Бәйрәмнәрдә, театрга, кунакка барганда, дворян балаларына форма кию мәҗбүри булган. Алар формаларын дачага яки чит илгә баргандагына салганнар. 6-9 яшьлек кызларның күлмәкләре көрән, 9-12 яшьлекләрнеке ак төстә булган. Күлмәк һәм алъяпкычларны кыйммәтле тукымадан теккәннәр. Кызларның формасы ике төрле булган. Берсе – һәр көн кию өчен көндәлек форма, икенчесе – бәйрәм формасы. Көндәлек

форма өчен яхшы сыйфатлы нык тукыманы Англиядән махсус кайтарганнар, ә бәйрәм киемен ефәктән теккәннәр.

Революциядән соң мәктәпләрдә, университетларда махсус форма кию бетә, ә Бөек Ватан сугышыннан соң яңадан кертелә.

(Текстны тыңлагач, бирелгән сорауга җавап алына)

Сезгә ике вариантта сораулар бирелгән, шул сорауларга текст ярдәмендә җавап бирегез. (Укучыларның текстның эчтәлеген ничек аңлауларын тикшерү йөзеннән, вариантларда эш эшләтү, тикшерү) Слайд №8

| 1 вариант | вариант |
|---|---|
| 1.Россиядә гимназиядә укучы ир балалар һәм студентлары өчен махсус форма кертү турында кайчан закон чыга?<br>2.Революциягә кадәр мәктәп формасын кемнәр генә кигән һәм ни өчен?<br>3.Кемнәр өчен форма кию мәҗбүри булган?<br>4.Күлмәк һәм алъяпкычларны нинди тукымадан теккәннәр? | 1.Гимназиядә укучы кызлар өчен мәҗбүри махсус форма кайчан кертелә?<br>2.Санкт-Петербургның Смольный институтында укучы дворян кызлары өчен кием фасоннарын кем тәкъдим итә?<br>3. Кызларның формасы ничә төрле булган?<br>4.Революциядән соң нинди үзгәрешләр була? |

4. Инглиз телендә мәктәпнең 100 еллыгына багышланган мәгълүмат, укучылар чыгыш ясыйлар (Видеофильм карыйлар һәм кызлар презентация буенча сорауларга җавап бирәләр) Слайд № 9-10.

*Teacher:* Dear students, as you now, this year we celebrate century of our school. I suggest you to watch a video about our school and school uniform in past. Be ready to answer the questions.

Questions:

1. When was founded our school? (1915)
2. What was the school uniform in 1949?(a wool dress with a black apron with collar and cuffs)

3. What was boys' uniform in 1962?(Boys wore grey military shirt with collar)
4. Why is it compulsory to wear school uniform nowadays?(It gives a common identity to school and pupils look smart when they are together)

5. – Укучылар, сезнең әби-бабаларыгыз, әти-әниләрегез төрле елларда Татарстанның һәм Россиянең төрле мәктәпләрендә укыганнар. Алар нинди мәктәп формасы кигәннәр, шул турыда сөйләп китегез әле (слайдта укучыларның ата-аналарының фотографияләре чыга, шуларга таянып, аларның мәктәп формасы турында сөйлиләр) Слайд № 11-19

— Свечникова Анжелика: Минем әниемнең исеме Наталья Рашитовна. Ул Бөгелмә шәһәрендә укыган. 1981нче елда әнием бәйрәмнәрдә мәктәпкә озын җиңле, кечкенә якалы көрән күлмәк, ак алъяпкыч кигән. Һәрвакыт чәчен үргән һәм ак бант таккан.

— Тиглева Анастасия: Минем әтием – ИгорьЮрьевич, 1995нче елда 10нчы сыйныфта укыган. Ул елларда озын буйлы матур егет буй-буй ак күлмәк, озын җиңле көрән пиджак, кара чалбар, чистарткан туфли кигән.

— Смирнов Степан: Әнием Гүзәл Талгисовна, 1987нче елда 10 сыйныфта Бөгелмә шәһәренең 6нчы мәктәбендә укыган. Ул киң якалы ак блузка, уртача буйлы кара итәк кигән. Чәчләрен артка туздырып йөргән.

— Козлова Татьяна: Минем әнием 1983 нче елда Брежнев (хәзерге Яр Чаллы) шәһәрендә 2нче сыйныфта укыганда киң якалы озын җиңле көрән күлмәк, ак алъяпкыч кигән, октябрят значогы таккан. Ә әтием Сергей Анатольевич 1987 елда мәктәпкә бизәкле ак күлмәктән, көрән төстәге костюмнан йөргән, пионер галстугы таккан.

— Лукьянова Евгения: Әбиемнең энисе Наталья Фёдоровна 1….елда 5нче сыйныфта укыганда кечкенә якалы озын җиңле ак күлмәк һәм озын җиңле кара сарафан кигән. Ә әнием Галина Завдатовна 1982нче елда 10нчы

сыйныфта киң якалы көрән күлмәк, төсле бәйләгән кофта, кара чалбар киеп йөргән.

— Бойко Ольга: 1989нчы елда әнием укыган мәктәптә кызлар зәңгәр төстәге кыска җиңле жилет, киң итәк, озын җиңле ак күлмәк игәннәр.

— Кеньшенская Инесса: Әнием Елена Сергеевна 1995 нче елда 65нче (хәзерге 16нчы) мәктәптә укыган. Ул зәвыклы киенергә яраткан: кыска буйлы итәк, ак блузка кигән.

***6. Teacher:*** **As you know, girls conducted questionnaires How students in our school apply to the school uniform?** Let's look at the results! Girls, you are welcome. (мальчики рассказывают о результатах анкетирования) Слайд № 20-21

*Pupils:*

1.Is it necessary to introduct school uniforms?

- a) Yes, of course- 51,2%
- b) No-26,7%
- c) According to wishes- 22,1%

2. The positive side of school uniforms.

- a) Nothing positive-15%
- b) Fosters a sense of unity-18%
- c) Organizes the order-34%
- d) Equalizes students-33%

3. The negative side of school uniforms

- a) Nothing negative-25%
- b) Your time in search of school uniforms-11%
- c)Low quality-14%
- d) Additional monetary cost-18%
- e) The lack of desire to wear school uniform-32%

*Teacher:* Ok! Thank you!

**7. – *Укучылар, сез үзегез киләчәктә мәктәп формасының нинди булуын телисез? Әйдәгез, үзегезнең проект эшегезне яклап, сөйләп китегез. Сүзне сезгә бирәбез.*** (укучылар татар һәм инглиз телләрендә төркемләрдә үз эшләрен яклыйлар).

**IV. Өй эше.** Слайд №22

дәфтәрдә 24 биттәге 11-12 күнегүләрне биремдәгечә язмача эшләргә.

WB p.10 ex.4

**V. Йомгаклау.**

**1. – *Укучылар, гомумиләштереп әйтегез әле, ни өчен мәктәптә укучыларның тышкы кыяфәте (внешний вид) бертөрле булырга тиеш соң?*** (Көтелгән җаваплар: 1) гаиләләрнең матди хәлләре төрлечә булу сәбәпле, укучылар арасында бер-берсеннән көнләшү хисләре тудырмау өчен; 2) мәктәп белән, класс белән горурлану хисе тәрбияләү өчен; 3) матур, пөхтә һәм зәвыклы итеп киенергә өйрәтү өчен; 4) класстагы психологик климатны яхшырту өчен)

**2**. Укучыларның белемнәрен бәяләү. Your marks for today are...

— Дәрес тәмам. Сау булыгыз. The Lesson is over! Good bye!!

# ҺӨНӘР САЙЛАУ-ҖАВАПЛЫ ЭШ
# 6 НЧЫ СЫЙНЫФ РУС ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН
# ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘСЕ

**Асылгәрәева Г. В.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы,**
**МБГББУ 3 гомуми урта белем биру мәктәбе**

Бурыч: һөнәрләргә кызыксыну формалаштыру.

Максат:

***1. Белем бирү максаты***: һөнәр сайлау проблемасы буенча лексик-грамматик күнекмәләрне кулланып, диалогик һәм монологик сөйләмгә чыгу.

***2. Фикер үстерү максаты***: чагыштыра белү, үз мөнәсәбәтеңне әйтә һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү.

***3. Тәрбияви максат:укучыларга*** һөнәр сайлауда дөрес юнәлеш бирү; һөнәр ияләре турында мәгълүмат бирү; һөнәр сайлау җаваплы эш эш икәнен ассызыклау**.**

Дәрес технологиясе: үстерешле укыту.

Метод: өлешчә эзләнү.

Материаллар һәм җиһазлау: компьютер, проектор, экран, тема буенча **мультимедиа** презентация, карточкалар, индивидуаль карточкалар, С.И. Ожеговның сүзлеге, хезмәт кораллары ясалган рәсемнәр.

**Дәрес планы**

1.Оештыру өлеше.

— Уңай халәт тудыру.

— Рапортичка. Дежур укучы белән әңгәмә

2. Белемнәрне актуальләштерү.

— **РАУНД ТЭЙБЛ**

— «Ми чарлау» үткән тема буенча белемнәрне тикшерү

3. Яңа материал үзләштерү

— КОНОРС

— Әңгәмә

Ял итү минуты. МИКС ПЭА ШЭА

4. ***Белем-күнекмәләрне беркетү***
— РАФТ
— ТИМБИЛДИНГ
5. Өй эше.
6. Дәрескә йомгак. Рефлексия.
ТАЙМД РАУНД РОБИН

Дәрес барышы

***Оештыру.*** Уңай халәт тудыру.

**1. Исәнләшү.** Уңай халәт тудыру.

Укытучы: Исәнмесез, укучылар!

Укучылар:Исәнмесез. Хәерле иртә.

Укытучы: Укучылар, игътибар итегез әле, бүген көн нинди матур! Без дә бер-беребезгә матур итеп елмаеп дәресебезгә керешик!

Укучылар: (Укучылар бер-берсенә карап елмаялар)

Укытучы: Утырыгыз, укучылар.

**2. Рапортичка. Дежур укучы белән әңгәмә.**

Укытучы:Бүген дәрестә кем дежур?

Укучы: Бүген дәрестә мин дежур!

Укытучы: Бүген дәрестә кемнәр юк?

Укучы: Дәрестә барысы да бар!

Укытучы:Урамда һава торышы нинди?

Укучы: Урамда көн бик матур, аяз.

Укытучы: Бүген атнаның ничәнче көне?

Укучы: Бүген атнаның дүртенче көне, пәнҗешәмбе!

Укытучы: Бик яхшы.

***Белемнәрне актуальләштерү.***

В мире тысячи профессий. Все они почётны, значимы и очень нужны.

— Ә нәрсә соң ул һөнәр? Укучылар, менә Арина аңлатмалы сүзлектән һөнәр сүзенең мәгънәсен белеп килергә тиеш иде (укучының җавабы: профессия – это у людей основной род занятий, трудовой деятельности).

Димәк, һөнәр – ул кеше хезмәте һәм эшчәнлегенең төп төре.

Ә хәзер миңа һөнәр сүзенең синонимнарын әйтегез әле. (белгечлек, эш, профессия, хезмәт)

1. РАУНД ТЭЙБЛ

**РАУНД ТЭЙБЛ –** обучающая структура, в которой учащиеся по очереди выполняют письменную работу по кругу на одном листе бумаги.

Укучылар, сез нинди һөнәрләр ишеттегез?

Беренче номерлы укучылар бер бит кәгазь алыгыз. 1 минут эчендә һәр команда күпме һөнәр исемнәрен белә, шул кадәр язарга тиеш. Бу битне өстәл буенча җибәрәсез.

Вакыт бетте. Кем башлый? Сез ничә һөнәр яздыгыз (Табиб, тегүче, сатучы, укытучы, шофёр һ.б.). Аплодисменты команде, которая написала больше всех названий профессий.

**2. «Ми чарлау» үткән тема буенча белемнәрне тикшерү (6-8 слайд).**

Кем кайда эшли? (6слайд)

Уйла (7слайд)

- Китапханәче … бирә.
- Укытучы … укыта.
- Тегүче … тегә.
- Төзүче … төзи.
- Сатучы … сата.
- Уйла (8слайд)
- Китапханәче (нинди?) китап бирә.
- Укытучы (нинди?) укучыларны укыта.
- Тегүче (нинди?) күлмәк тегә.
- Төзүче (нинди?) йорт төзи.
- Сатучы (нинди?) күмәч сата.
- Пешекче (нинди?) аш пешерә.

(ТӘМЛЕ, КЫЗЫКЛЫ, ЗУР, МАТУР, ТЫРЫШ, ФАЙДАЛЫ)

3. Яңа материал үзләштерү

Профессий очень много. Каждая по – своему хороша. *Укучылар, психологлар һөнәрләрне 5 төргә бүлгәннәрен сез инде беләсез. Әйдәгез әле, бергәләп искә төшерик.*

(Человек – человек,

*человек – природа,*

*человек – техника,*

*человек – знаковая система,*

*человек – художественный образ)*

КОНОРС – «углы» обучающая структура, в которой ученики распределяются по разным углам в зависимости от выбранного ими варианта ответа.

Хәзер укучылар бастык. Урындыкларны этеп куйдык һәм үзегезгә ошаган почмакны сайлап, барып басыгыз. Ни өчен шуны сайлавыгыз турында үз партнёрыгыз белән фикер алышыгыз. Башладык.

Встаньте, задвиньте стульчики. Разделитесь на 4 угла. Обсудите по парам причину своего выбора. Поделитесь мыслями своего партнёра.

*Кеше – кеше.*

*Кеше – табигать. Кеше техника.*

*Кеше – билгеләр системасы.*

*Кеше – сәнгать образы.*

Ял итү минуты

Ял итеп алыйк. МИКС ПЭА ШЭА

Ә хәзер укучылар бераз ял итеп алабыз. Укучылар, без хәзер барыбыз да бер әйләнә ясап басабыз. Музыка кушыла, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, сез бер урында басып каласыз, һәм үзегезгә бер пар табасыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез шул сорауның җавабын пардагы укучы белән фикер алышасыз.

Когда музыка остановится, вы должны образовать пару с ближайшими к вам учениками и «дать пять», затем я задаю вопрос и даю 3-5 сек на размышление.

**1**нче сорау: Сез табиплар һөнәре турында нәрсә беләсез?

Что вы знаете о профессии врач?

30 сек. уйлагыз, кем озынрак шул җавап бирә башлый

Партнерыгызга рәхмәт әйтегез.

**2нче сорау: Сез укытучы һөнәре турында нәрсә беләсез?**

Что вы знаете о профессии учитель?

30 сек. уйлагыз, кемнең күзләре карарак шул җавап бирә башлый

Рәхмәт әйтегез.

Настя, әйт әле, сиңа партнерың нәрсә турында сөйләде.

Үз урыннарыгызга утырыгыз.

Поблагодарите своего партнера**.** А теперь на этот вопрос ответит Настя. Ответь, пожалуйста, что рассказал тебе твой партнер?

— Спасибо, ребятки, молодцы! А теперь пройдите на свои места.

**4. *Белем-күнекмәләрне беркетү.***

*РАФТ – Роль – Аудитория – Форма – Тема – более структурированный вариант организации проектной работы, в которой конечный продукт может отличаться в зависимости от роли учеников, аудитории.*

Я не случайно заговорила о профессии учитель, так как наша школа набирает в 10 класс учащихся у кого есть желание быть учителем.

Укытучы һөнәре сезгә бик таныш, кайберләрегез укытучы булу турында хыяллана да әле. Әйдәгез, укытучы булырга теләмәгәннәрне дә кызыксындырырлык итеп постер иҗат итик әле.

Һөнәрләр күп: кем булсаң да
Табиб, эшче, тукучы...
Тик онытма бер нәрсәне –
Юл күрсәтә укытучы.

1 һәм 2 өстәл укытучы турында, ә 3-4 өстәл төрле һөнәрләрне алып, постер әзерлиләр.

Тимбилдинг

Әйдәгез пантомима уенын уйнап алыйк. Сезнең өстәлләрдә карточкалар ята. Сез шул һөнәрне сүзсез аңлатып бирергә тиешсез.

Чтобы еще узнать о профессиях, давайте поиграем в пантомиму. Каждая команда будет показывать профессию, название которой у вас лежат на столах. А остальные должны ее угадать.

Стол №1(печекче), Стол №2 (укытучы), Стол №3 (шофер), Стол №4 (җырчы), Стол №5 (сатучы), Стол №6 (чәчтараш)

Молодцы!

**5. Өй эше.**

Көндәлекләрне ачабыз. Өй эше: «Һөнәр сайлау – җаваплы эш» темасына 5 җөмлә язып килергә

**VI. Дәрескә йомгак.** *Әңгәмә*

Укучылар, без бүген дәрестә бик күп һөнәрләр турында сөйләштек. Ә ничек уйлыйсыз: һөнәрнең кайсысы әһәмиятлерәк, әйбәтрәк? (Балаларның җаваплары)

Димәк, укучылар, менә шулай итеп әйтергә була: Бөтен эш тә әһәмиятле, барысы да яхшы. Һөнәр сайлау – җаваплы эш

**1.ТАЙМД РАУНД РОБИН**

Һәр укучы 30 секунд эчендә Бүген дәрестә үзенә нинди яңалык ачканын сөйли. Һәр өстәлдән 1-2 укучыдан сорыйм.

2. Билгеләр кую.

3. Саубуллашу.

— Дәрес тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Сау булыгыз!

# ДӘРЕСЛӘРДӘ ЗАМАНЧА ИНФОРМАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Пушкарная Г. Р.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы,**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган**
**1 нче урта гомуми белем мәктәбенең**

Соңгы елларда илебезнең һәр мәктәбендә барлык предметлардан да белем бирүдә компьютер техникасы һәм башка информацион технологияләр ешрак кулланыла башлады.

**Информатизация** – белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

Нәрсә соң ул информацион технология?

Белем бирүдә информацион технология – компьютер техникасы һәм программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү һәм җиткерү процессы.

Белем бирүдә кулланыла торган информацион технологияләр ике төргә бүленә:

— техник чаралар;

— программа чаралары.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә компьютер техникасы, информацион технология чаралары кулланып, дәресләрдә төрле мәсьәләләр чишеп була. Мәсәлән:

— укучыларда татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

— шәхес тәрбияләү;

— фикерләү сәләтен үстерү;

— эстетик тәрбия бирү;

— укытуның сыйфатын күтәрү;

— предметара бәйләнеш булдыру;

— укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уяту.

Мин үземнең өлкәнрәк сыйныф укучыларыма эзләнү-тикшеренү өстендә эшләгәндә, еш кына иҗади өй эшләре бирәм, реферат, презентацияләр, дәрескә өстәмә материаллар алып килергә кушам. Мондый очракта алар үзләре татар телендә булган сайтлардан материаллар эзләп табып алып киләләр.

Дәресләремдә информацион технологияләр куллану миңа төрле методик мөмкинчелекләр бирә:

- дәрес материалын күз алдына китерү;
- төрле модельләр, таблицалар төзү;
- үз-үзеңне тикшерү булдыру (тест формасында укучылар экранга карап үз-үзләрен тикшерәләр һәм үз эшләрен бәялиләр);

Шулай ук информацион технологияләр миңа:

- индивидуаль белем бирү;
- дифференциаль белем бирү;
- мультимедиа һәм интернет аша зур күләмле мәгълүмат алырга өйрәтү;
- мәгълүматны каталоглар һәм белешмәләр кулланып эшкәртергә өйрәтү;
- укыту процессында кирәк булган материалларны тупларга өйрәтү эшләрен булдыруда ярдәм итә.

Дәресләрне укыту процессында информацион технологияләр куллану махсус программа чараларнын куллануны күз алдында тота. Болар:

- электрон дәреслекләр (http://kitap.net.ru/ , http://www.tatknigafund.ru/, http://miras.belem.ru/, http://tatarca-text.narod.ru– «Татарча текстлар, программалар»..., http://adiplar.narod.ru/, http://tt.wikipedia.org/wiki/, http://adiplar.narod.ru/index.html h.б.);
- контроль ясаучы тестлар;
- информацион – белешмә программалар (http://watan.su/suzleklar/ - сүзлекләр, энциклопедияләр);
- күргәзмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар).

Презентация формасында эшләнгән слайдларны дәресләремдә еш кулланам. Сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацияләр бик уңайлы. Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Галимҗан Ибраһимов, Роберт Миңнуллин, Абдулла Алиш, Фәнис Яруллин, Шәүкәт Галиев кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре өчен, грамматиканы өйрәнү өчен эшләнгән (Исем, Фигыль, Сан, Сыйфат, Алмашлык һ.б.) әзер презентацияләрем дә бар.

Татар теле һәм әдәбият дәресләрен заманча информацион технологияләр кулланып эшләнгән эшләрем

«Яхшылык эшләргә ашыгыйк» дәрес – фрагменты;

«Каюм Насыйри мирасын өйрәнү» – фәнни-гамәли конференция;

Г.Тукай «Бала белән Күбәләк» шигырен сәхнәләштерү;

«Уенчыклар кибете» – мастер – класс;

«Иле барның – теле бар» – әдәби- музыкаль кичә;

«Тукай безнең йөрәкләрдә» – әдәби-музыкаль кичә;

«Әбием – алтыным» – әдәби-музыкаль кичә;

«Беркем дә онытылмаган, бернәрсә дә онытылмаган» - әдәби- музыкаль кичә;

«Мәңгелек ут яна! – әдәби-музыкаль кичә.

Менә соңгы 3 әдәби-музыкаль кичә Бөгелмә шәһәренең Якупов урамында урнашкан төп яшәү урыннары һәм шөгыльләре булмаган затларын социаль адаптацияләү үзәгендә яшәүче өлкән яшьтәге бабайлар һәм әбиләр өчен үткәрелде.

Дәресләрне укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш.

Иң мөһиме укытучы укыту процессын дөрес итеп, укучыларда конкурентлыкка сәләтле белемнәр формалаштырырлык итеп оештырырга тиеш.

Әдәбият исемлеге

1. Гыймадиева Н. Дәрестә һәм дәрестән соң. – Казан «Яңалиф»нәшрият йорты, 2004 ел.
2. Мукимова Н. Милли-мәдәни шартларда тел өйрәнү. – «Мәгариф» журналы. – 2010 ел, №9.
3. Селевко Г.К. Современные образовательные технологии. М., 1998.
4. Интернет ресурслары.

# УРМАН – ХАЛЫКНЫҢ БАЙЛЫГЫ
# (ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЕ)

**Ибатуллина Л. З.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**7 нче гимназиянең татар теле һәм**
**әдәбияты укытучысы**

**Дәрес тибы:** бәйләнешле сөйләм үстерү.

**Метод:** сөйләү, күрсәтү, практик, парларда, төркемнәрдә эш.

**Дәрес максаты:** төрле күнегүләр, эш төрләре аша укучыларның фикерләвен, дәрес темасы буенча сөйләм күнекмәләрен, рухи үсешен камилләштерү.

**Дәреснең бурычлары:**

- алдагы дәресләрдә өйрәнелгән лексик берәмлекләрне камилләштерү һәм укучыларның табигатьнең торышы турында белемнәрен киңәйтү;
- уйлау сәләтен, уку активлыгын, мөстәкыйльлелекне, диалогик, монологик сөйләмне үстерү, сүз байлыгын арттыру;
- табигать байлыкларын саклау буенча җаваплылык хисләре уяту, табигатькә сакчыл мөнәсәбәттә булу ихтыяҗы арттыру, аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү, барлык тереклек ияләренә хөрмәт, мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү.

**Дәрес технологиясе:** коммуникатив технология.

**Җиһазлау:** ноутбук, мультимедия проекторы, презентация, таратма материаллар.

Дәреснең барышы.

I. <u>Ориентлаштыру-мотивлаштыру этабы:</u>

а) уңай психологик халәт булдыру:

(1-слайд)

— Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез, бер-беребезгә елмаеп карыйк әле, чөнки елмаю кешенең кәефен күтәрә (улыбка

поднимает настроение).Бер-беребезгә хәерле көн телик.

Урыннарыгызга утырыгыз. Сезнең яхшы кәефләрдә булуыгыз өчен мин бик тә шат. Бүген дәрестә без сезнең белән тату һәм актив эшләрбез дип уйлыйм.

б) белемнәрне актуальләштерү:

* Прослушайте и перечислите названия животных упомянутых в тексте.

Куян – урман һәм басу җәнлеге, ул бик куркак. Төлке, бүре - куянның дошманнары. Куян җәен үлән, кышын агач кайрысы ашый. Куян җәен соры, кышын ак төстә. Аның колаклары бик озын. Ул бик тиз йөгерә, яхшы сикерә. Бүре – усал җәнлек, соры төстә. Бүре – урман санитары, чөнки ул авыру җәнлекләрне юк итә. Керпе – кыргый җәнлек. Ул урманда, бакчаларда яши. Тычканнар тота, алма ярата.

* Прослушайте диалог и расскажите содержание. (№5)

— Сезнең якта урманнар бармы?

— Әйе, безнең якта урманнар бар.

— Урманнарыгызда нинди агачлар үсәләр?

— Наратлар, чыршылар, каеннар, имәннәр, өрәңгеләр.

— Ә гөмбәләр бармы?

— Бар. Яңгырдан соң күп була. Гөмбәгә еш йөрибез.

1. Өй эшләрен тикшерү:

Өй эше итеп туган ягыбызда үсүче дару үләннәрен искә төшерергә бирелгән иде.

— Сез хәзер бер-берегездән сүзләр җыярсыз.

— Сез үзегезнең битләрегездә дару үләннәренең исемнәрен язасыз. Бу эштән соң сызык сызасыз. Моның өчен сезгә 30 секунд вакыт бирелә.

— Хәзер класс буенча йөрисез. Һәр укучы янына килеп, үзегездә булмаган сүзләрне язасыз. Бу сүзләрне җыяр өчен 5 минут вакыт бирәм.

— Вакыт бетте, үз урыннарыгызга утырыгыз. Хәзер без берничә укучының җавапларын тикшерәбез.

(2-слайд)

Үзбәя. (Таблицада үзләрен бәялиләр). Оцените свою деятельность в таблице.

1. Уку мәсьәләсе кую:

(3-слайд)

— Дәреснең темасын ачыклау өчен мин сезгә ребус тәкъдим итәм.

Һәр группага ребуслар таратыла, шул ребусны чишеп җавапны битләргә зур хәрефләр белән язалар.

— Ребус җавапларын тикшерәбез. 1 төркем – «халыкның» (4-слайд), 2 төркем – «урман» (5-слайд), 3 төркем – «байлыгы» (6-слайд).

— Һәр төркемнән 4нче укучы чыга һәм ребус җавапларыннан җөмлә төзеп басалар.

— Димәк, укучылар бүген дәресебезнең темасы нинди? (7-слайд).

Көтелгән җавап: Урман-халыкның байлыгы.

— Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы - «Урман – халыкның байлыгы.»

— Сез бу җөмләне ничек аңлыйсыз?

— Исходя из темы урока, сформулируйте его главную цель. Что сегодня предстоит нам выяснить?

Көтелгән җавап: Ни өчен урман – халыкның байлыгы дип санала?

II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы.

1 нче адым:

Сораулар ярдәмендә әңгәмә кору:

— Татарстанның табигате нинди? (табигате зур һәм бай)

— Аның аша нинди зур елгалар ага? (Идел, Кама, Агыйдел, Нократ)

— Татарстанда нинди шәһәрләр бар? (Казан, Әлмәт, Яр Чаллы, Бөгелмә,...)

— Бөгелмә районында урманнар күпме? (Бик күп)

— Урманнарда нинди агачлар үсә? (Имән, каен, нарат, чыршылар...)

— Урманда нинди чәчәкләр үсә? (Ак чәчәк, энҗе чәчәк)

Бөгелмә урманнарында нинди хайваннар яши? (Бүре, төлке, куян...) (8-слайд)

Үзбәя (Таблицада үзләрен бәялиләр.) Оцените свою деятельность в таблице.

2 нче адым: (9-слайд)

— Ә хәзер дәреслекләрегезнең 48нче битен ачыгыз, 3нче күнегүдәге биремне эшлик.

— Хәзер текстны укыйм, сез игътибар белән карап барыгыз һәм «Бу текст нәрсә турында?» соравына җавап әзерләгез.

— Шулай итеп, бу текст нәрсә турында?

— 1 укучы сәнгатьле укый.

— Сезгә текстны тәрҗемә итәргә 3 минут вакыт бирелә.

— Вакыт үтте. Парларга бүлендек. Кыскарак чәчле укучы иптәшенә текстны тәрҗемә итә. Ике укучының җавабын тыңлыйбыз.

(10-слайд)

Үзбәя (Таблицада үзләрен бәялиләр.) Оцените свою деятельность в таблице.

(11,12-слайд)

Ял минуты:

Укучылар, урыннардан тордык. Урындыкларны этеп куегыз. Стулья задвинули.

— Укучылар, без хәзер барыбыз да бер әйләнә ясап басабыз. Музыка кушыла, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, сез бер урында басып каласыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез шул сорауның җавабын миңа укучылар саны ярдәмендә күрсәтергә тиеш буласыз.

Татар халык бию көенә йөриләр. Музыка туктый. Сорау бирелә. Сораудагы җавап санына карап берләшәләр:

— Бөгелмә сүзендә ничә хәреф бар? (7)

— Мин көзне яратам җөмләсендә ничә сүз бар? (3)

— Татарстанда ничә зур елга бар? (4)

— Бүген дәрестә ничә малай бар? (5)

3 нче адым: (13-слайд)

— Ә хәзер төркемләп эшлибез.

А) Һәр төркем текст буенча 4 сорау төзи.

Б) 1нче төркемдәге 1нче укучы 2нче төркемдәге 1нче укучыга сорау бирә һәм җавап ала.

(14-слайд)

Үзбәя. (Таблицада үзләрен бәялиләр) Оцените свою деятельность в таблице.

4 нче адым

Һәр төркемгә ситуатив күнегүләр язылган карточкалар бирелә.

— Һәр төркемнең җавапларын тикшерәбез. Экрандагы эталон белән чагыштырабыз.

— Скажи, что:

1нче төркем (15-слайд)

Для людей от леса большая польза.

В лесу растут грибы и ягоды.

Деревья очищают воздух.

2нче төркем (16-слайд)

Мы собираем лекарственные травы.

Лес – наше богатство.

Лес охраняет сады от ветра.

3нче төркем (17-слайд)

Свежий воздух очень нужен людям.

Чистый воздух – наше здоровье.

Из деревьев строят дома.

(18-слайд)

Үзбәя (Таблицада үзләрен бәялиләр.)

— Оцените свою деятельность в таблице. Как вы работали в группе?

5 нче адым: (19-лайд)

«Бу нинди агач?» уены (урман шаулавы, кошлар сайравы, талгын музыка ишетелә).

— Укучылар, күзләрне йомдык. Үзебезне матур агачлар үскән урманда йөрибез дип хис итик. Игътибар белән карагыз әле, нинди агачлар үсә икән монда?

Слайдларда агач рәсемнәре чыга, укучылар аларның исемнәрен әйтәләр.

(20-26 слайдлар)

— Афәрин! Булдырдыгыз, бик күп агачларны таныйсыз икән!

III. <u>Рефлексия бәяләү этабы:</u>

— Вот урок подходит к концу.

— Димәк, ни өчен урман - халыкның байлыгы?

— Урман кешегә нәрсә бирә?

Дәрескә гомуми билге кую:

— Ә хәзер билгеләр куелган таблицагызны карагыз һәм дәрескә гомуми билге куегыз.

«5» – дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам.

«4» – әйбәт эшлим, материалны аңладым.

«3» – әйбәт эшлим, ләкин иптәшемнең ярдәменә каршы килмим.

Таблицаларны җыеп алу. Укучыларга билгеләр кую.

Өй эше бирү: (үзләре сайлап алалар)

49нчы бит, 7нче күнегү.

49нчы бит, 9нчы күнегү.

# РЕЧЕВОЕ ПОВЕДЕНИЕ УЧИТЕЛЯ НА УРОКАХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

**Абдрахимова Р.Ш.,**
**учитель татарского языка и литературы,**
**МБОУ «Средняя образовательная школа №3**
**с углубленным изучением отдельных предметов»**
**Бугульминского муниципального района РТ**

Описание материала: Данная статья полезна для учителей татарского языка, обучающих русскоязычных детей. В статье приведены типичные ошибки, которые допускают учителя татарского языка. Предлагаемый материал поможет педагогам грамотно, с точки зрения речевого этикета, построить свой урок.

Большое значение в работе учителя татарского языка играет его речевое поведение. Речь учителя выполняет важную функцию в учебно-воспитательном процессе, и к ней предъявляются определенные требования. Для учителя татарского языка, работающего в русских группах, важно не только хорошо владеть методикой преподавания татарского языка, знать татарский язык, для него важно еще и хорошо владеть русским языком.

Какую же роль играет русский язык, родной язык учащихся, в профессиональной подготовке учителя татарского языка для русскоязычной школы?

Знание грамматики русского языка необходимо учителю для реализации в работе принципа учета родного языка учащихся. Использование типологического описания русского и татарского языков – эффективный приём при обучении и татарскому произношению, и татарской грамматике. Кроме того, на начальном этапе обучения учителю татарского языка приходится использовать русский язык и с целью установления контакта с учениками: в этом случае русский язык выполняет важную коммуникативную функцию.

Таким образом, к устной речи учителя татарского языка

предъявляются достаточно высокие требования.

Устная речь учителя должна обладать определёнными свойствами: темпом, громкостью, интонационной окрашенностью, тембром.

Темп речи может быть быстрый, медленный, нормальный. На начальном этапе обучения татарскому языку темп речи на татарском языке должен быть от замедленного до нормального. Темп речи учителя на русском языке должен быть нормальным.

Тембр речи – это окраска голоса, которая может быть приятной и неприятной. Хорошее, доброжелательное настроение учителя поможет сделать ему свой голос приятным и располагающим к изучения татарского языка.

С точки зрения громкости, устная речь учителя может быть громкой, нормальной и тихой. При обучении второму языку важно, чтобы учащиеся ясно слышали речь преподавателя, поэтому говорить на татарском языке учитель должен чуть громче и яснее, чем на родном языке учащихся.

Тон речи может быть спокойным, взволнованным равнодушным, заинтересованным, убедительным, неуверенным и т.д. учитель татарского языка должен избегать монотонности и в зависимости от учебной ситуации менять тональность своей речи.

Особенно важным свойством устной речи учителя татарского языка является дикция, т.е. отчётливость произношения. С помощью специальных упражнений и занятий с логопедом учитель может исправить недостатки своей дикции.

В зависимости от конкретных учебных ситуаций учитель должен умело изменять темп, громкость, тембр своей речи на татарском и русском языках. Свободное владение устной речью на русском языке также, как и знание русской грамматики, снимает трудности в коммуникативной деятельности учителя, поможет создать в классе атмосферу речевого общения, а главное, укрепит авторитет учителя.

Помимо указанных свойств, устная речь учителя должна

обладать еще такими качествами, как правильность и чистота, точность и уместность. Эти качества речи должны быть присущи не только татарской речи учителя, но и его русской речи.

Правильность речи – это соответствие речи литературным нормам. Среди отступлений от норм русского литературного языка у учителя татарского языка могут быть нарушения, связанные с интерференцией, то есть влиянием татарского языка на его русскую речь. Учитель татарского языка может допустить акцент в своей русской речи при произношении слов со звуками [ч’] [ц’], а также с группами согласных СТК, СТР, ЛНЦ.

В татарском языке звук [ч] – шипящий, но является простым согласным и произносится без элемента «т» в начале, что является обязательным для русского [ч’]. Например: чәй, чәкчәк, чыршы, чистарта, чай, честно, чистить, чек.

Звук [ц],не свойственен фонетической системе тюркских языков и в татарском язык встречается только в словах, заимствованных из русского языка. Характерной для носителя татарского языка ошибкой является замена звука [ц], переднеязычным щелевым [с].

В речевых действиях учителя татарского языка звук [ц] может встречаться при произнесении следующих фраз : «Целый урок будем читать!», «Цель урока…» и других.

Сочетание согласных СТК, ЗДК не свойственны тюркским языкам, поэтому при произношении носитель татарского языка вставляет гласные: «ыстол», «Петыр», «ыстарик».

Учитель татарского языка должен хорошо владеть лексикой и фразеологией русского языка, чтобы обеспечить адекватный перевод с татарского на русский и с русского на татарский, а также не допускать ошибок в речи. Так, например, учитель произносит фразу «Подберите надпись к данному рисунку», «Я зачитаю слова, «Записывайте вместе с доской» (вместо «Я пишу на доске, а вы в тетрадях»).

К грамматическим ошибкам в фразах, произносимых учителем татарского языка на русском языке, относятся ошибки,

связанные с употреблением глагольных форм и построением предложений. Например, учитель говорит: «Задавайте друг другу вопросы по содержанию текста ( вместо Задайте) или «Отвечайте на вопросы ( вместо «Ответьте на вопросы»).

Одним словом, особым предметом внимания и профессиональной подготовки учителя является его собственная речь как на татарском, так и на русском языке. Учителю необходимо работать над такими качествами речи как тембр, темп, дикция, чистота и правильность речи.

На уроках татарского языка в русскоязычном классе учитель должен стремиться к использованию только татарского языка, а при пользовании русским языком соблюдать его орфоэпические нормы.

## «СЫЙФАТ» ТЕМАСЫН ЙОМГАКЛАУ
## (3 нче сыйныфта татар теле дәресе)

**Хөснетдинова Р.Р .,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**2 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Максатлар:**

1) сыйфат буенча өйрәнгәннәрне кабатлау, системага салу; текстан сыйфатларны аерып ала алу, башка сүз төркемнәре белән бутамау, сөйләмдә дөрес куллану;

2) укучыларның бәйләнешле сөйләм телен, мөстәкыйль фикер йөртү, нәтиҗә ясый, чагыштыра белү сәләтен үстерү;

3) әниләргә мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** Кабатлау һәм гомумиләштерү дәресе

Уку эшчәнлеген оештыру: парлап, төркемнәрдә, фронталь, мөстәкыйль эшләү.

Уку эшчәнлеге төрләре: өлешчә эзләнү, әңгәмә, рәсем буенча сөйләү, төрле характердагы күнегүләр эшләү, Смарт – тактада эш, монологик сөйләм.

Дәреслек. Ф.Ф. Харисов, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисова. Татар теле (3класс) Казан:Тат.кит.нәш., 2013.

**Җиһазлау:** биремнәр язылган карточкалар, Смарт-такта, презентация, жетоннар, номерлы карточкалар.

1. Ориентлаштыру-мотивлаштыру

**1.** Уңай халәт тудыру

**Укытучы.**

Исәнмесез, укучылар,
Хәерле көннәр сезгә.
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телим мин һәммәгезгә.
Елмая, көлә кояш
Сез дә елмаегыз әле бераз.(Укучылар бер-берсенә карап елмая, 1нче слайдта кояш рәсеме)

– Күтәренке кәефтә дәресебезне башлап җибәрик.

**2. Дәрестә үзеңне тоту кагыйдәләрен тыңлау.**

– Һәр дәрестә без куллана торган, бүген дә онытмаска тиешле 3 кагыйдә бар? Ул кайсы кагыйдәләр?

**1нче укучы.** Тулы җөмләләр белән сөйлә!

**2 нче укучы.** Игътибар белән тыңла, бүлдермә!

**3 нче укучы.** Кеше фикерен кабатлама, үз фикереңне әйт!

**3. Уку мәсьәләсен кую.**

– Укучылар, тактадагы рәсемгә игътибар итегез. (2 слайд, яз рәсеме)

– Анда елның кайсы фасылы сурәтләнгән? (Яз)

– Яз көнендә көннәр нинди?

– Язның иң беренче бәйрәме кайсы бәйрәм? (8 нче март)

– Әлеге бәйрәмдә без кемнәрне котлыйбыз? (Әниләрне, әбиләрне, кызларны, апаларны, укытучы апаларны, сеңелләрне)

– Сезнең өчен бу бәйрәмдә иң кадерле кеше кем? (Әни)

– Ә хәзер, әйдәгез, әниләргә яратып әйтелә торган җылы сүзләрне әйтик. (3 слайд, әни рәсеме)

– Әниләр нинди? (музыка тыңлана,күзләрен йомып, бер минут уйлыйлар (яхшы, матур, акыллы, сөйкемле, игътибарлы, кайгыртучан,йомшак күңелле,сабыр, тырыш )

– Укучылар, бу сүзләрне бер сүз белән ничек атыйбыз? (сыйфат, 4 слайд)

– Теманы аңлагансыздыр, ул нәрсәгә багышлана?

**4. Максатларны китереп чыгару.**

– Үткән дәресләрдә без «Сыйфат» темасында нәрсәләр белдек?

К. Ж. 1. Предметның билгесен белдерүче сүзләр сыйфат дип атала.

**2.** Сыйфат нинди? яки кайсы? сорауларына җавап бирә.

**3.** Предметның төрле билгеләрен белдерүен.

**4.** Сыйфат ачыклаган исем сыйфатланмыш була.

**5.** Синоним һәм антоним сыйфатлар була.

**6.** Сыйфатлар сөйләмне матурлый, тулыландыра.

– Димәк, үз алдыбызга бүген кайсы максатларны һәм бурычларны куябыз?

(5 слайд, дәреснең максатлары)

Максатлар:

1) сыйфат буенча өйрәнгәннәрне практик эшләрдә дөрес куллану;

2) текстган сыйфат белән сыйфатланмышны аерып ала белү;

3) язма һәм язма сөйләмебездә сыйфатларны урынлы, дөрес куллану.

4) синоним, антоним сыйфатларны бутамау.

Уку мәсьәләсен өлешләп чишү

1. Предметка хас билгеләрне әйт

– Укучылар, сезнең алда рәсемнәр. Безнең максат шул: предметка хас билгеләрне барлау һәм әйтү.

(чылбыр буенча эшләнә) (6 слайд, төрле рәсемнәр)

Мәсәлән: лимон ачы, сары; төлке хәйләкәр, зур.

Нәтиҗә. Димәк, сыйфат предметка хас булган нәрсәләрне белдерә? (билгеләрне)

**2. Дөрес кәрзингә сал.**

Смарт-тактада 6 кәрзин, кәрзиннәрдә – сыйфатлар. Әлеге кәрзиннәргә бирелгән сыйфатларны дөрес итеп урнаштырырга кирәк.

– Иң элек әлеге кәрзиннәргә исемнәр куйыйк. (Укучылар предметның төрле билгеләрен әйтәләр, укытучы ача бара)

Куллану өчен сыйфатлар: яшел, кара, кызыл, сары; баллы, ачы, тәмле, тозлы; кечкенә, зур, озын, түгәрәк; юмарт, усал, ягымлы, юаш; кояшлы,карлы, җилле, яңгырлы; йомшак, каты, куе, яшь.

Нәтиҗә. Димәк, сыйфатлар предметка хас кайсы билгеләрне белдерә? (төсне, тәмне, характерны, күләмне, форманы һ. б.)

**4. Физминут.**

– Укучылар, бастык. Әйдәгез, ял итеп алыйк. (Бию көенә хәрәкәтләр ясала)

**5. «Укы, уйла, яз, үз урыныңны тап, аңлат».**

– Укучылар, сезнең алда карточкалар. Аларда текст язылган. Сезнең бурыч шундый: текстны сәнгатьле итеп укырга; сыйфатларны табып, күчереп язарга; аннан, сыйфатлар санына карап, дөрес номер янына басарга.(2 мин)

**1 нче карточка**

Дәү әнием
Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул – минем дәү әнием...
Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

**2 карточка**

Иң матур әни
Минем әни, һич бәхәссез
Иң сөйкемле әни ул!
Яхшы сүзе, кылган эше-
Һәммәбезгә туры юл.
Борчыйсым килми әнине,
Елмаеп, көлеп йөрсен
Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен.

**3 карточка**

<u>Әнием</u>
Әнием минем матур,
күзләре якты,көләч.

Шундый күңелле була,
ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
Әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
Ә куллары йоп-йомшак.

Игътибар! Кемдә беренче номерлы карточка – алар 5 нче; кемдә 2 нче номерлы карточка – алар – 4 нче; кемдә 3 нче номерлы карточка – алар 6 нчы номер янында булырга тиеш. Дөрес номерны тапкач, шигырьне укыйсыз, сыйфатларны әйтәсез.

**Нәтиҗә.** Булса, сыйфатларны табуда кыен очракларны күрсәтегез.

**4. Парымны әйт.**

Смарт-тактада 2 баганада сүзләр язылган. 1 нче баганадагы сүзләр ачык, икенчесендәге капланган.

– Укучылар, сезнең алда сыйфатлар. Бирем: бирелгән сыйфатларның синонимнарын әйтегез.

| | |
|---|---|
| яхшы | әйбәт |
| дымлы | юеш |
| кечкенә | нәни, бәләкәй |
| батыр | куркусыз, кыю |
| матур | гүзәл, чибәр |
| акыллы | башлы |

**Нәтиҗә.**Синоним сыйфатлар дип без кайсы сыйфатларга әйтәбез? Алар ни өчен кирәк? (мәгънәләре охшаш булган сыйфатларга; кабатлаулар булмасын өчен кирәк)

**5.** тизрәк ал һәм дөрес җавап бир. (Смарт – тактада)

– Укучылар, сезнең алда диңгез. Сез, диңгездән«балык»ны алып, анда язылган сүзне кычкырып укырга һәм капма-каршы мәгънәдәге парын әйтергә тиеш. Башладык.

(Сүзләр: куркак, ачы, саран, ак, озын, тук, йомшак, ялкау)

**Нәтиҗә.** Капма-каршы мәгънәдәге сыйфатларны ничек

дип атыйбыз? (Антоним сыйфатлар) Алар ни өчен кирәк? (Сөйләмне кабатлаулардан саклау өчен)

**6. Белемеңә карап.**

– Укучылар, миндә 3 төрле конверт бар. Кызылында – катлаулы, яшелендә – уртача, агында җиңел биремнәр. Әйдәгез, белгәннәрне тикшереп карыйк.

Кызыл конверттагы бирем. Бирелгән сүзләрне файдаланып, әниегез турында сөйләгез.

Яше (карт, яшь, өлкән,урта яшьтә)

Күзләренең төсе (зәңгәр, коңгырт, яшькелт, соры, кара)

Борыны (туры, озын,кыска, киң, кәкре)

Иреннәре (матур,кабарынкы,калын, юка)

Чәчләре (бөдрә,озын,кыска,сары,чем-кара, куе, туры)

Гәүдәсе(зифа,ябык,юан,җитез)

Гомумән алганда, ( матур, акыллы, ягымлы, ярдәмчел)

Яшел конверттагы бирем. Җөмләләрне сыйфатлар белән тулыландырыгыз.

Яз җитте. Күктә кояш балкый. Урамда балалар уйный. Аларның тавышлары ишетелә.

Ак конверттагы бирем. Нокталар урынына тиешле сыйфатларны куегыз.

Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган —
Бүген әни бәйрәме.
Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн ..., көн ямьле!
Якты булсын, балкып торсын —
Бүген әни бәйрәме.
Өстәлөстен кат-кат сөртте,
Җәйде ... җәймәне.
... булсын, ... булсын
Бүген әни бәйрәме.
(Сүзләр:кояшлы, ап-ак, чиста, пөхтә)

Игътибар! Эшне һәр төркемнән 1 укучы тикшерә.

Нәтиҗә.**Укучылар,** әйтегез әле, сыйфатлар ни өчен кирәк? (сөйләмне тулыландыралар, матурлыйлар)

**7. Белемеңне тикшер** (интерактив тест).

– Укучылар, хәзер тестлар эшләп алыйк. Сезнең алда сораулар, дөрес җавапны билгеләгез.

**8.Сыйфатныңвизиткарточкасынясау**(модельләштерү).

–Укучылар, сыйфат буенча белгәннәрегезне әлеге ромашкага урнаштырыгыз.

Игътибар! Эшләр җыеп алына.

1. Рефлексив кабатлау

1. Сорау - җавап

– Менә дәресебез ахырына якынлашты. Куйган максатларга әйләнеп кайтып нәтиҗә ясыйк.(Слайд буенча нәтиҗә ясала) Барысын да тормышка ашырдыкмы? Нәрсәгә ирештек?

2. Үзбәя, бәя

Аңлатып, билгеләр куела.

– Кемгә бүгенге дәрес ошады, ул яшел түгәрәк күтәрә.

– Кемгә ошады, ләкин кыенсынулар булды, ул сары түгәрәк күтәрә.

– Кемгә дәрес ошамады, ул кызыл түгәрәк күтәрә.

**3. Өйгә эш бирү.**

1) сыйфатларны кабатларга;

2) «Матурлардан – матур әнием» дигән темага хикәя язарга;

3) әни турында матур фикерләр табарга.

**4. Саубуллашу.**

– Дәрес тәмам. Барыгызга да рәхмәт.

## ИШЕТЕП АҢЛАУ АҢЛАУ ҺӘМ ҖАНЛЫ СӨЙЛӘМДӘ КАТНАШУ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ
(РУС ТӨРКЕМЕНДӘГЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

**Шәрифуллина А. М.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче**
**5нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле**
**һәм әдәбияты укытучысы**

**Максат:**

— чит кеше сөйләгәнне яки укыганны тыңлап аңларга өйрәтү материалы белән таныштыру;

— фикерне әйтеп бирергә һәм башкаларның сөйләмен аңларга өйрәтү;

— ишетеп аңлау күнегүләрен кулланып, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, татар теленә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау:видеоязма, аудиоязма, карточкалар

Дәреснең барышы

Рус телле укучыларны татар теленә өйрәткәндә, беренче чиратта, чит кеше сөйләмен тыңлап аңларга өйрәтү эше тора. Бу күнегүләр системасы «аудирование» күнегүләре дип атала.

Аудирование күнегүләренең төп максаты:

— ишеткәнне аңларга өйрәтү;

— үз фикереңне әйтеп бирергә, башкалар сөйләгәнне аңларга өйрәтү;

— укучыларны татар халкының мәзәкләрен, табышмакларын, әйтемнәрен ишетеп аңларга өйрәтү;

— ишетеп аңлау күнегүләре кулланып, укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру, аңа карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Дәреслектә ситуатив биремнәр бик күп, ләкин аудирование күнегүләре юк дәрәҗәсендә. Рус телле укучылар өчен бердәм республика тестының беренче бүлеге укучыларның тыңлап

аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Моңа әзерлек эше башлангыч сыйныфларда ук башлана. Укучыларны чит кеше сөйләмен тыңлап аңларга өйрәтү максатыннан, дәреснең төрле этапларында аудирование күнегүләре кулланыла

**1нче күнегү:** «Һава торышы».

Укучылыр төркемләп утыра. Аларга Татарстан картасы таратыла. Аудиоязма тыңлаганда, укучылар Татарстан шәһәрләрендә һава торышы ничек икәнен билгелиләр. Максат: шәһәр исемнәрен искә алу, саннарны кабатлау, текстны аңлау дәрәҗәсен билгеләү. *(язма ике мәртәбә тыңлатыла)*

Бүген 10 нчы август, пәнҗешәмбе. Татарстанда ике ай хөкем иткән коры, эссе һава, ниһаять,төшә башлады. Хәзер республикабызда җылы, сәламәтлек өчен уңай һава торышы күзәтелә.

Казанда +29 – +30 градус җылы булачак, төнлә һава температурасы +15 – +17 градуска кадәр төшәчәк.

Республикабызның төньяк-көнчыгыш районнарында – Яр Чаллыда, Алабугада һава торышы сизелерлек бозыла һәм температура +20 – +22 градуска кадәр җылы булачак. Вакыты белән явым-төшем көтелә.

Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында – Әлмәттә, Бөгелмәдә җылы, явымсыз, җылылык +25 – +29 градус.

Төньяк-көнбатыш районнарында – Яшел Үзәндә алмашучан болытлы һава, урыны белән яңгырлар көтелә. Җылылык +23 – +26 градус.

Татарстан Республикасының көньяк-көнбатыш районнарында – Буада, Тәтештәһава торышы тотрыклы. Явым-төшем көтелми. Җылылык +27 – +29 градус. Бу хакта Татарстан Республикасының гидрометеорологияидарәсе хәбәр итә.

– Татарстандагы кайсы шәһәрләр искә алына? *(Казан, Яр Чаллы, Алабуга, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Тәтеш, Яшел Үзән)*

– Казанда һава торышы нинди?

– Яр Чаллы, Алабуга кайда урнашкан? Алардагы һава то-

рышы турында сөйләгез.

– Көньяк-көнчыгышта кайсы шәһәрләр урнашкан? Аларда һава торышы нинди?

– Яшел Үзән Татарстанның кайсы ягында урнашкан? Һава торышы турында сөйләгез.

– Көньяк-көнбатыш районнарында һава торышы нинди?

**2нче күнегү**

Ял итү минутларын да файдалы итеп үткәрергә мөмкин. Өлкән классларда җыр тыңлаганда, түбәндәге биремне бирергә мөмкин:

– Без ял итеп алабыз. «Мин яратам сине, Татарстан» җырын тыңларбыз. Сүзләрен белүчеләр кушылып җырлый ала. Шул вакытта һәр төркем җыр текстында булган тартым кушымчасы булган исемнәрне табарга тиеш. Кемнәр күбрәк таба, шулар җиңә.

«Мин яратам сине, Татарстан!»
(Р.Андреев көе, Р.Рәкыйпов сүзләре)
Мин яратам сине, Татарстан,
Ал <u>таңнарың</u> өчен яратам,
Күк күкерәп, яшен яшьнәп яуган
<u>Яңгырларың</u> өчен яратам.
Мин яратам сине, Татарстан,
Горур <u>халкың</u> өчен яратам,
Җан эреткән әнкәм <u>телең</u> өчен –
Татар телең өчен яратам.
Мин яратам сине, Татарстан,
<u>Тугайларың</u> өчен яратам,
<u>Тукайларың</u>, <u>Сәйдәшләрең</u> өчен,
<u>Җәлилләрең</u> өчен яратам.
Нәтиҗә: җиңүчене билгеләү

**3нче күнегү**

Послушайте текст. Перед вами лежат листы с заданиями. Вы должны правильно выбрать слово, которое соответствует содержанию текста

Без туган шәһәр – Бөгелмә. Ул Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышында. Бөгелмә яклары киң кырларга, шаулы урманнарга, көмештәй ялтырап агучы елгаларга бай.

Бөгелмә борынгы, бай тарихлы шәһәр. Шәһәребез көннән-көн матурая, үсә. Яңадан-яңа йортлар төзелә, төрле спорткомплекслар калкып чыга, балалар бакчалары, кибетләр үз ишекләрен ача.

Бөгелмә шәһәре үзенең данлыклы кешеләре, галимнәре, язучылары белән дә дан тота. Яраткан җырчыларыбыз Алсу, Надежда Кадышеваны кем генә белми икән?!

Шәһәрдә күп кенә уку йортлары, музейлар, парклар, театр бар. Әлеге гүзәл шәһәрдә күп кенә милләт вәкилләре үзара бик тату, дус яшиләр.

Бөгелмә ул – дуслык шәһәре. Бөгелмә – тарихи шәһәр. Бөгелмә – киләчәккә ныклы адым белән алга баручы шәһәр.

1. Бөгелмә Татарстан Республикасының....

1) көньяк-көнбатышында

2) көньяк-көнчыгышында

3) төньяк-көнчыгышында

2. Бөгелмә ... шәһәр.

1) тарихи

2) зур

3) яшь

3. Шәһәребез ... .

1) искерә

2) пычрана

3) матурая

4. Бөгелмә шәһәре ... дан тота.

1) галимнәре белән

2) эшчеләре белән

3) укучылары белән

5. Шәһәрдә милләт вәкилләре ... яшиләр.

1) начар

2) яхшы

3) тату

Нәтиҗә:Без туган шәһәрнең исеме ничек? Ул нинди?(монолог)

**4нче күнегү**

Балалар мультфильм карарга ярата. Татар телендә чыккан мульфильмнар да хәзер бик күп. Мультфильмнан өзек алып, балалардан эчтәлеген сөйләтергә яки өзеккә исем бирдерергә мөмкин.

– Укучылар, сез мультфильм карарга яратасызмы? Татар мультфильмнарын караганыгыз бармы?

Сезгә хәзер 4 мультфильм тәкъдим ителә, аларга исем табарга кирәк. *(укучыларга, сайлап алу өчен, карточкалар тәкъдим ителә)*

– Мультфильм геройлары кебек сез дә «Китапханәдә» дигән темага диалог төзегез.

– Кайсы төркемнең диалогы яхшырак булыр икән?

**5 нче күнегү**

Аудиоязма буенча таблица тутыру.

– Әдәбият дәресендә Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында өйрәндек. Хәзер Г.Тукай турындагы белемнәрне тикшереп карыйк. *(җөмләләр укыла - дөресме, дөрес түгелме икәнлеген билгеләргә кирәк)*

Нәтиҗә: Габдулла Тукай турында беләсез дип әйтергә мөмкин.

Шулай итеп, ишетеп аңлау күнегүләрен төрлечә үткәрергә мөмкин. Әлбәттә, бөтен дәрес аудирование белән узарга тиеш түгел. Ул бары тик дәреснең билгеле бер өлешендә генә булырга мөмкин.

## СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ТҮГӘРӘК ЭШЕ

**Фәттахова М.К.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**МБГББУ Карабаш беренче урта мәктәбе**

**Тема:** Карабаш авылы антропонимнары (сәләтле балалар белән түгәрәк эше).

**Максат:** Туган төбәктәге нәсел, шәхси кушаматларның килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш ысулларын барлау, мәгънәләренә төшенү. Шәҗәрәләр аша ата-бабаларыбызның тарихи үткәне белән танышу. Укучыларда үзең яшәгән төбәк халкы белән горурлану хисләре тәрбияләү; сөйләм һәм фикерләү сәләтен үстерү .

**Җиһаз:** китаплар стендында Ф.Гарипова, Г.Саттаров, М.Әхмәтҗанов хезмәтләре; укучыларның үз язмалары, гаилә шәҗәрәләре (алдан ук тема буенча сораулыклар таратыла); Карабаш авылы картасы.

**Дәрескә эпиграф:** Исеме онытылмаган шәхес – иң бәхетле шәхес.

Узбәк шагыйре Әлишер Нәваи.

Дәрес барышы.

**Укытучы.** Хәерле көн, кадерле укучылар. Бүгенге дәресебез гадәти түгел. Ни өчен, диярсез. Әйдәгез, бер язма тыңлап үтик. (видеоязмада Бәширә Насыйрова башкаруында «Карабашым» җыры яңгырый, Каравыл тау биеклегеннән төшерелгән видеофильм).

Каравыл тавы - горур тау,
Саклый салкын җилләрдән.
Җылы аламын йөрәккә
Назлы туган җилләрдән.

Әйе, ямьле Зәй елгасы буена урнашкан, туган авылыбызны уратып алган мәгърур Каравыл таулары әллә кайдан безне үзенә дәшеп тора. (слайд № 1 космостан төшерелгән Карабаш авылы күренеше).

Буген без туган як буйлап сәяхәткә чыгабыз. Мин – гади бер сәяхәтче, ә сез – юл күрсәтүче якты йолдызларым. Ышанам: мине адаштырмассыз. Ә моның өчен, әйдәгез, узган дәрестә үзләштергән белемнәребезне искә төшерик. Ономастика фәне нәрсә өйрәнә? (слайд № 2 – «Ономастика»)

**Укучы.** Дөньядагы һәр нәрсәнең исеме бар. Барлык төр ялгызлык исемнәрнең килеп чыгышын, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика (грекча «Исем кушу сәнгате») дигән махсус тармагы шөгыльләнә. Топонимика (барлык төр географик атамалар) һәм антропонимика (исем, фамилия, кушамат, шәҗәрәләр өйрәнү) ономастиканың ике иң мөһим һәм иң зур бүлекләрен тәшкил итә.

**Укучы.** Әйе, безнең авыл Зәй суының югары агымына урнашкан бик борынгы авыл. Шәҗәрәләр һәм риваятьләргә караганда, авылның исеме Карабаш исемле кеше атамасына бәйләнгән. Йөз яшькә җитеп вафат булган Закир бабай Бадыйков истәлекләренә караганда, аны «Карбыш» авылы дип йөрткәннәр. Шулай булуы да мөмкин, чөнки элеккеге Болгар дәүләте территорияләрендә урнашкан татар авылларында Карбыш, Кармыш, Курмыш нәселләренең шәҗәрәләре очрый. Бүгенге көндә авылыбызда 5250 халык исәпләнә.

**Укучы.** Татар теленең антропонимик системасында иң борынгы атау-эндәшү булып исем һәм кушамат санала. Кушамат аралашу, аңлашуны җиңеләйтә, кем турында сүз барганны төгәл ачыкларга ярдәм итә. Безнең авылда уннан артык гаиләне үз эченә алучы Чабак нәселе бар. Борынгы төрки телдә чабак сүзе «вак балык» мәгънәсен белдергән. Фиршеллар (Кәшшаф, Мифтах, Ибраһим, Исмәгыйль, Заһит) – Ибраһимовлар. Ерак бабалары Кәшшафның олы улы Самарада фельдшерлар мәктәбен тәмамлап, Бөгелмә өязендә бердәнбер медицина хезмәткәре була. Кәшәфетдинов Мифтахны бояр үз хисабына укыткан. Ул «Мифтах доктор» дип халык теленә кереп калган. Мондый төр кушаматларны бик күп атарга мөмкин: Төкеләр нәселе (маңгай белән төкү), Кәтчәләр («хотя» сүзеннән), Чумар (ашарга

гел чумар пешергәннәр), Тапай, Әтәч, Суыр, Песи, Чыпчык, Төперде (Мәхмүт карт балачакта «күпер» сүзен «төпер» дигән), Төрек (Шакир карт төрекләрдә әсир кала, шуннан Фатыйма исемле кызга өйләнеп кайта), Тырыс, Дул-дуллар (бәләкәй чакта ат кебек кешнәп, «Дулый бит» дип йөргән), Ябалак, Думбра, Бүре, Кара бәрән, Пирук, Кавызы (челән кебек озын торыклы булганнар), Шыпырт, Әрлән, Баскыннар (Төпле урамга 1878 нче елларда күчеп утырган Казан ягы кешесен халык «качкын, баскын» дип атаган).

Укучы. Кайбер кушаматлар кешенең исемен кыскарту юлы белән дә ясалган. Мәтәрәй (Мөхәмmәтгәрәй Таһиров) – бабалары бик тырыш, эшчән кеше булган. Оныкларының берсе бүгенге көндә Себердәге Мегион шәһәрендә яши, үз фирмасына «Мәтәрәй» исеме биргән.

Укучы. Шәхси кушаматлар да шактый гына кызыклы. Асаба Хабулласын гына алыйк . 1907 нче елда ике төрәнле сабан белән җир эшкәрткәннәр. Тимер сабан беренчеләрдән булып Бай Сөләйманнар ала, икенче булып, урта хәлле Хәмидулла алган. Улы Хабулланы бер көнне Аргы җирлекләрнең түгәрәк күл буйларын эшкәртергә җибәргән, тик ул сабанны һич тә көйли алмаган. Шул вакытта Печмән (Лениногорск) ягыннан бер рус кешесе килеп чыккан. Эшне аңлап алган рус кешесе сабанны көйләп биреп: «С новым плугом особо надо хорошо пахать, « – дигән. Хабулланың күңелендә «особо» сүзе утырып кала, бу сүзне дустына да өйрәтә. Шул көннән башлап ул үзе – Асаба Хабулласы, ә күл Асаба күле булып халык теленә кереп кала. Атитан (адъютант) Шәйхелислам (Галиәкбәров) та кызыклар сөйләргә бик маһир кеше булган. 25 ел буе офицер адьютанты булып хезмәт иткән. Түрәкәй Таҗетдине – урыны гел түрдә; Өрдер – кырт, кырыс; Шыр-шыр Атлас – шыр-шыр көләргә яраткан; Сәхи Мәрьям – алдауга оста, шуңа күрә «сәхи» дигәннәр; Чәпи Разыясы кушаматын болай аңлатырга мөмкин: удмурт теленнән «чипей» сүзе «Чуртан» мәгънәсен белдерә, тешле, үзсүзле кешеләргә татарлар «чуртан», руслар «щука»

кушаматы такканнар..

Укучы. Безнең авылда бер исемдәге кешеләр күп булган. Аларны бутамас өчен, бер-берсенең тышкы кыяфәте, йөз-гәүдә төзелешенә нисбәтле исем биргәннәр: Кызыл Фәрит – кызыл-кучкыл йөзле; Тәтәй Сәхәп – бик пөхтә йөргән; Урыс Хәмбәл чәче җитү булган; Тәпән Зәки – юан; Пасынка Гәрәй – үз оныгын русча әйтеп аңлата алмаган.

Укучы. Исем-фамилияләрне кыскарту юлы белән ясалган кушаматлар я берничә буынга кадәр ияреп килгән, я шул кешенең үзенә генә тагылган:

Дәүләтбайлар – Мәүлетбаев фамилияле нәсел кешеләре;

Сапыйлар – Сафиуллин фамилияле;

Муха Илгизе – Мухаметшин (Мөхәммәтшин);

Шәкүр – Шәкүровлар;

Әли Хаҗие – Газизов Мөхәммәтгали;

Бәдеркә Әсмасы – килен кешенең исеме Әсма, ә кайнанасы Бәдеркә исемле булган;

Әлү бабай – Әһлиулла бабай.

Укытучы. Җәмгыятьтә үзгәрешләр чорында шәҗәрәләр белән кызыксыну да арта. Бу үзгәрешләр һәр кешенең үткән тарихка, бүгенге көнгә булган карашын тамырдан үзгәртә.

Шәҗәрә сүзе татар телендә нәсел-ыру тарихы дигән мәгънәдә файдаланыла. Татар халкы бик борынгы заманнардан ук нәсел тарихын язуга зур әһәмият биргән. Шәҗәрә аркылы кешеләр ата-бабаларының дәвамчысы булуына төшенгәннәр. Ә сезнең гаилә шәҗәрәгез бармы?

Укучы. Нәсел шәҗәрәсе төзү гадәте борынгы заманнарда ук төрле халыкларда билгеле булган.18 нче гасырда генеалогия тарих фәненең аерым бер тармагы булып формалаша. 7 буын ата-бабаңны белү күп халыкка хас.

Мин дә шәҗәрәмне әтием нәселе турында төзергә булдым. Шәҗәрәләр белән кызыксынуымны белгәч, әтием миңа бик теләп булышты. Гаилә альбомнарын, архив документларын актарып чыгардык, бабамның, туганнарыбызның истәлекләре

белән уртаклаштык, гаилә шәҗәрәсен 14нче буынга кадәр төзедек. (слайд № 3)

Укытучы. Әйе, шәҗәрәңне белү-өйрәнү бүгене көндә бик актуаль, чөнки үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк. Буыннар чылбырын өзмичә, һәр буын, гаилә тарихына өлеш кертеп, үткәннәр белән киләчәк буын арасында арадашчы ролен оста башкарса, нәселнең киләчәге өметле булачак. Шәҗәрәләр төзү – әһәмиятле әхлакый чара. Ул гаиләне , шулай ук дәүләтне ныгыту өчен ярдәм итә. Син үз алдыңа нинди бурычлар куйдың?

Укучы. Бу максатка ирешүдә түбәндәге бурычлар куйдым:

1) ата-бабаларның нәсел тарихларын белү һәм саклау;

2)күренекле шәхесләрнең нәсел шәҗәрәләрен өйрәнү аша мәгълүмат туплау;

3) нәселемнең шәҗәрәсен җыю, туплау, эзләнү;

4) гореф-гадәтләр, нәсел тамгасы, гаилә ядкарьләре белән кызыксыну;

5) үз нәселемне, туганнарымны ихтирам итү, алар белән горурлану.

Төп методологик чыганаклар булып бу өлкәдә эшләүче академик Г.Саттаров, филология фәннәре докторы М.Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китабы (К., 1995), профессор Ф.Гариповаларның фәнни хезмәтләре тора.

Укытучы. Әйе, татар халкының күркәм матур гадәте – җиде буын бабасын искә алып, аларның исемнәрен тәртибе белән белеп, алар рухына дога кылу.

Укучы. Мин Фазыл абый Вәлиәхмәт турында сөйләп китәргә телим. Ул Карабашта туа, Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетын тәмамалап, 1991 нче елдан бирле районыбызда чыга торган «Бөгелмә авазы» газетасында эшли. Милләт азатлыгы өчен актив көрәшче буларак, язмаларында милли теманы киң яктырта. 1993 нче елда хаҗга бара. Әтисе Габдулла авыл мәчетенең беренче имамы булып тора, ә бабасы Вәлиәхмәт Петроградта гренадер булып хезмәт итә, патшаны саклый. Вәлиәхмәт шәҗәрәсе 7 буынны үз эченә ала: Яхшы бай

(1770) – Миңлегол (1900) – Гибадулла – Вәлиәхмәт – Габдулла – Фазыл – Рәмис. Бу – әтисе яклап нәсел агачы. Ә әнисе ягыннан бабасы Гайфулла Зәй-Каратай авылының бай кешесе була, ике тапкыр җәяү хаҗга барган, җиде айда әйләнеп кайткан, тик икенче баруында үлеп калган.

Укытучы. Димәк, нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән схема «нәсел агачы» дип атала. Икенче төрле аны «шәҗәрә» диләр. Бабаларыбыз тормышын өйрәнү нигә кирәк икән?

Укучы. Илебез, халкыбыз тарихын белү өчен, киләчәк тормышыбызны матур итеп төзү өчен. Ә бит тәрбиялелек нәсел геннары аша бирелә һәм ул – иң мөкатдәс сыйфат. Республикабызның танылган җырчысы Бәширә Насыйрова (минем бабамның бертуган сеңелесе) нәселен дә авылыбызда беләләр. Аның әтисе Шакир бабай Насыйров озак еллар безнең мәктәптә музыка укыткан. Ул гарәп телен камил белгән, татар халкының күптөрле милли уен коралларында уйнаган, оста скрипкачы. 1999 нче елда авылыбызның Тау Очы урамына Насыйров исеме бирелә. Бу бит инде үзе үк олы мәртәбә. Мин шул урамда яшим, шуның белән горурланам. (презентация «Моңга гашыйк нәсел» – җырчы Бәширә Насыйрова шәҗәрәсе)

Укытучы. Дөрес, Бәширәгә моң әтисеннән күчкәндер. Ә нәсел тамгалары турында ни әйтерсез, балалар?

Укучы. Бик борынгыдан татар халкы тамга дип аталган символларны даими файдаланган. Тамгаларның килеп чыгышы фәнни яктан ачыкланып бетмәсә дә, аңлашыла: борынгы төркиләрдә һәр ыру-кабиләнең , соңрак һәрбер ир кешенең шартлы билгесе булган.

Ата кеше үз тамгасын кече улына үзгәртмичә нәсел мирасы итеп тапшырып калдырган, шуңа күрә тамгалар нәселнең генә килеп чыгышын түгел, төрле нәселләрнең бер-берсе белән туганлыгын ачыклар өчен алыштыргысыз чыганак булып тора.

Тамагалар шактый еллар имза ролен дә үтәгән. «Тамга салу», «Тамга кую» төшенчәләре шуны аңлата булса кирәк..

Безнең нәсел тамгасы да хәзерге көннәргә кадәр сакланган. Аңа нинди мәгънә салынуы турында ике төрле уй-фикер бар. Әлеге билге, беренче фараз буенча, буыннар бәйләнеше һәм алга, өскә таба үсешне аңлата. Икенче фараз буенча, әлеге тамга – бик борынгы бабаларыбыз кулланган рун билгеләренең берсе. Ул тамганың фонетик эквиваленты озын »а».

Укытучы. Кеше исемнәре, кушаматларга нисбәтле географик атамалар (антропотопонимнар) да шактый безнең авылда. XII гасырда патша җирләрен үзләштерүдә катнашкан Карабаш (Карбыш) исемле гаскәр башы безнең якларга би итеп билгеләнә. Алар Каравыл тау итәгенә кирмән коралар. Карабаш би Тамбикә исемле кызга өйләнә. Моны исбатлаучы «Таңбикә чишмәсе»ннән яшь киленнәр бүген дә су ташый. Ул чорлардан бездә «Якуб аланы», «Биш казак әрәмәсе» Мөхәммәтрәхим сырты җәелеп ята. Кинҗәкәй чокырының үз тарихы бар. Бу урынга 1774 нче елда Пугачев ярдәмчесе булып торган атаман Кинҗә килеп утыра. Ул авылның чибәр кызы Хәнифәгә өйләнә. Бу мәгълүматларны Солтан абый Асылов язмаларыннан табарга мөмкин. Әлеге безнең авыл гидронимнары, оронимнары буенча эшлисе эшләр шактый. Димәк, алда сезне мавыктыргыч очрашулар, ачышлар көтә. Ни өчен Татарстанның көньяк-көнчыгышында вак елга һәм күлләр күп? Ни өчен бу төбәкне «Татарстан Швейцариясе» дип атыйлар? Бу сорауларга без чираттагы дәрес-сәяхәттә җавап бирербез. Чыгышларыгыз өчен барыгызга да рәхмат. Нәтиҗә ясыйк инде, балалар.

**Укучы.** Күреп үткәнебезчә , авылыбызның ономастикасын тикшерү татар халкының тарихын һәм этногенезын өйрәнүдә үзеннән мул өлеш кертә. Кушаматлар, нәсел шәҗәрәләрен барлау туган төбәк, аның кешеләрен яхшы белергә ярдәм итә, безне олыларга хөрмәт, туган җиргә бирелгәнлек рухында тәрбияли.

**Укытучы.** Дәресебезне Клара апа Булатова шигыре белән тәмамлыйсым килә. Мәктәбебездә узган шигырь бәйгесенең төп кунагы итеп чакырылган шагыйрә, илһамы килеп, тиз арада түбәндәге юлларны укыган иде:

Карабашның башы карадыр да -
Мин ышанам җаны аклыгына.
Мин ышанам аның тарихына
Актау җыеннары кайтуына.
Бу балалар белән туган җирне
Яшәртергә була бит әле.
Бу балалар белән туган телне
Яшәтергә була бит әле.
Карабашта дистә еллар буе
Төрле милләт яши аралаш,
Ә шулай да денен югалтмаган,
Телен югалтмаган Карабаш.

Бу юллардагы өмет тулы фикерләргә сез дә тугры калырсыз, без өлкәннәрнең ышанычын акларсыз дип уйлыйм.

Өй **эше.**

Әйтелгәннәрнең барысын да бергә туплап, «Карабаш авылы антропонимнары» дигән исем астында проект эшен башкарырга (төркемнәргә эш).

## ИСЕМ ТЕМАСЫНА ЛИНГВИСТИК КРОСС (6НЧЫ СЫЙНЫФ, ТАТАР МӘКТӘБЕ)

**Сөнгатуллина Г. Ф.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы**
**Һади Атласи исемендәге**
**14нче татар гимназиясенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Төп максатлар:**
— укучыларның фәнни күзаллавын киңәйтү;
— эзләнү алымы белән оста файдалану күнекмәләре булдыру;
— сөйләм телен баетудагы әһәмиятен ачыклау;
— хәтерне төрле ысуллар белән ныгыту;
— ватанпәрварлык, толерантлык тәрбияләү өчен шартлар тудыру;
— яшь буынны спортка, сәламәт яшәү рәвешенә чакыру.

**Җиһазлау:** интерактив такта, килешләр таблицасы, 25нче кадр өчен җөмләләр язылган карточкалар, дидактик карточкалар, рәсемнәр.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру** (Психологик уңай халәт тудыру). Укытучы. – Хәерле көн, укучылар! Исәнмесез! Бүген без сезнең белән сүз төркемнәрен гомумиләштерүне дәвам итәрбез. Бүгенге дәрес гадәти булмас.

**II. Белемнәрне актуальләштерү.** Укытучы. – Ягез әле, искә төшереп үтегез, 2013нче ел Татарстаныбызда нинди истәлекле вакыйга булды?

Укучылар. – 2013нче ел Татарстанда – бөтендөнья универсиада үткәрелде.

Укытучы. – Ә 2015нче елда Казаныбызда нәрсә көтелә?

Укучылар. – Спортның су төрләре буенча бөтендөнья чемпионаты узачак.

Укытучы. – Укучылар, мин сезнең барыгызның да спортны

ратуын беләм. Чөнки спорт ул – сәламәтлек, күтәренке кәеф, ярыш. Без бүген исемнәр иленә лингвистик кросска әзерләндек. Анда да үзенең стартлары һәм финишлары, җиңүләре һәм уңышсызлыклары булырга мөмкин. Ләкин барыбызны да белемгә омтылу теләге берләштерә.

(Укытучытактаның уң ягына «һ»тартыклары кергән сүзләрдән җөмлә беркетә) **«Шәһәрдә һава һаман зәһәр».**

(Тактаның сул ягына «х»тартыклары кергән сүзләрән җөмлә беркетә) **«Хыялдагы мәхәббәт хаты хатасыз».**

(Укучыларга фронталь сораулар бирү.) – Сүз төркеме буларак, нәрсә ул исем?(Исем-предметны атый яки белдерә торган сүз төркеме)

– Нинди сорауларга җавап бирә? (Ул кем?нәрсә? ни? сорауларына җавап бирә.)

– Нәрсәләр белән төрләнә? (Зат-сан, килеш, тартым белән)

– Исемнәр ясалышлары ягыннан ничә төргә бүленәләр? (5).

**III. Алынган белемнәрне ныгыту.**

Укытучы: – Зат-сан, тартым белән исемне төрләндерү әллә ни кыенлык тудырмый. Ә менә килешләр белән төрләндергәндә кайбер укучылар хата ясыйлар.

(Тактада 1 җөмлә языла) Волейболга да, баскетболга да, гимнастикага да сәләтем бар, киемнәрне дә әзерләп куйдым, ләкин спорт залының эшләгән вакытын туры китерә алмыйм.

Укытучы. – Бу җөмләдә төшем килешенә караган сүз бармы? (Бар.)

Укытучы. – Ничәү?(2)

(Кайбер укучылар киемнәрне сүзен генә табарга мөмкин, чөнки вакытын сүзенең –ны кушымчасы юк, ә киресенчә –ын чөнки ул тартым белән төрләнгән )

Укытучы. – Укучылар, мин сезгә килешләрнең сорауларын җиңелрәк истә калдыру өчен терәк рәсемнәр уйлап таптым. Ягез әле, килешләрне сораулары белән әйтеп барыгыз.

Укучылар. – Баш килеш. Кем? Нәрсә?

Укытучы. – Баш сүзе нәрсәне аңлата?

Укучылар. – Кемнеңдер икенчеләрдән өстен булуын, кеше гәүдәсенең өске өлешен, һ.б

(Экранда рәсем пәйда була. Спорт комитетында ике кеше утыра: берсе – вице-президент, икенчесе – президент. Кем баш монда?)

Укучылар. – Иялек килеше. Кемнең? Нәрсәнең?

Укытучы. – Иялек сүзе нәрсәне аңлата? Нинди сүздән ясалган? (Ия)

(Экранда рәсем пәйда була.Тренер кулына сыңар кроссовка тоткан һәм сорый: «Иясен таба алмыйм. Кемнең кроссовкасы?») Укытучы: «Күрәсең бу кроссовканың иясе мәхәббәттән башын югалткандыр (25нче кадр). Шулай инде, хыялдагы мәхәббәт хаты хатасыз була.

Укучылар. – Юнәлеш килеше. Кемгә? Нәрсәгә?

Укытучы. – Нинди сүз белән тамырдаш?(Юнәлү)

(Экранда рәсем пәйда була. Ике малай спорт сараена юнәләләр).

Малайлар нәрсәгә юнәләләр?Кая юнәләләр?

Укучылар. – Малайлар спорт сараена юнәләләр.

Төшем килеше.Кемне? Нәрсәне?(25нче кадр). Рәсемдә һава тонык, пычрак итеп сурәтләнгән).Укытучы әйтеп куя: карагыз әле шәһәрдә һава һаман зәһәр икән!

Укытучы. – Төшем килеше ниди сүз белән охшаш?

Укучылар.– Төшү сүзе белән.

(Экранда рәсем пәйда була. Бер кыз теннис ракеткасын төшереп җибәргән.)

Укытучы. – Кыз нәрсәне төшереп җибәргән?

Укучылар. – Ракетканы яки ракеткасын.

Укытучы. – Аерма бармы?(Бар.Ракеткасын булса, үзенеке була)

Укучылар. – Чыгыш килеше.Кемнән?Нәрсәдән?Кайдан?

Укытучы. – Кайдан чыгалар егетләр? (Компьютер салоныннан,боз сараеннан)

Укучылар. – Урын-вакыт килеше. Кемдә? Нәрсәдә? Кайда?

(Экранда рәсем пәйда була. Спорт матчына билет тикшереп кертәләр. Берәү: «Билет кемдә?»– дип, икенчесе: «Урыннарыбыз кайда?»– дип сорый.)

Укытучы. – Ярый, без сезнең белән килешләрне кабатлап чыктык. Карагыз әле, (тәрәзәгә ымлап,(25нче кадр)ә шәһәрдә һава һаман зәһәр!

**<u>2.Орфоэпик күнекмәләр. Орфоэпик зарядка ясап алыйк әле.</u>**

Укытучы. – Кайсыбер бердәм республика тесты һәм бердәм республика имтиханы биремнәрендә басымны дөрес күрсәтүне таләп итүче сораулар бар. Безнең татар телендә басым күбрәк кайсы иҗеккә төшә? (Соңгы иҗеккә)

Укытучы. – Кайсы очракларда басым соңгы иҗеккә төшми?

Укучылар. – Боерык фигыльләрдә, фигыльләрнең юклык формасында,–ча,–чә кушымчасы ярдәмендә ясалган рәвешләрдә һ.б.

Укытучы. – Дөрес. Бу сүзләрне истә калдырырга кирәк. Менә француз теленә дә шундый ук күренеш хас икән. Мәсәлән: абажур, тротуар, жалюзи... Ягез әле, бу сүзләргә татар телендә аваздаш, яки рифмага туры килә торган сүзләр уйлап табыгыз. (Ассоциация уены)

Абажур – бик матур. Тротуар – йөрми анда мал-туар. Жалюзи– алган юзи һ.б.

Укытучы. – Әлбәттә, тротуар ул шәһәрдә генә була, нишләп анда мал–туар йөрергә тиеш. Җитмәсә, шәһәрдә һава һаман зәһәр! (25нче кадр)

**3.**<u>Орфографик күнекмәләр.</u>

***1).***Укытучы. – Төшеп калган хәрефләрне язып чыгыгыз. Тәртибе белән язсагыз, бер гыйбарә килеп чыгарга тиеш. Нинди әйтем ул? (Спорт – сәламәтлек ул.)

Төс...ез, ту..ыл, төнб...ек, кы...ык, август...а, көй...ез, мәх...ббәт, күңел..е, сәл...м, сум..а, к...газь, елат...ы, метал...,

төлк...,са...чы, с...рәт, бал...

**2).** (Карточкалар таратыла).Укытучы: Бу сүзләрне ике кабат игътибар белән укып чыгыгыз.Хәзер сүзләрне ябабыз.

Төнбоек, янгыр, унбер, баулы, сәгадәт, сурәт, игътибар, тәэсир.

Укытучы:Нинди сүз беренче иде?Нинди сүз икенче иде?Барысы ничә сүз? Ничә сүз «с» хәрефенә башлана**?**

**IV. Йомгаклау.** Укытучы: Укучылар,сез бүген нәрсәләрне күбрәк исегездә калдырдыгыз? Дәреснең кайсы өлеше кызыклы булды? Үзегезгә нинди яңалык алдыгыз?

**V. Өй эше.** Укытучы. – Киләсе дәрескә «сыйфат»темасын кабатлап килергә. Ә хәзер кесә телефоннарыгызның диктофоннарын кабызыгыз да миннән бер әкият-теләк яздырып алыгыз**.** (Искәрмә очрагы булган сүзләрдә басымны истә калдыру өчен)

**«Йокларга ятар алдыннан көлмәгез, шауламагыз! Тешләрегезне чистартмыйча, юынмыйча ятмагыз! Һәркөнне бу әкиятне тыңларга онытмагыз! Хәерле төннәр!»**

Укытучы. – Дәресебез тәмам. Исән-сау һәм сәламәт булыгыз! Спорт белән шөгыльләнегез!

## НОВЫЕ ПОДХОДЫ В ОБУЧЕНИИ ДЕТЕЙ ДВУМ ГОСУДАРСТВЕННЫМ ЯЗЫКАМ

**Кочеткова И.В.,**
**старший воспитатель МБДОУ № 9 «Колобок»**
**Бугульминского муниципального района**

Дошкольный возраст – это период активного усвоения ребенком разговорного языка, период развития его лингвистических способностей. Раннее обучение второму языку создает прекрасные возможности для того, чтобы вызвать интерес к языковому и культурному многообразию Республики Татарстан и России, уважение к языку и культуре другого народа, способствует коммуникативно – речевому развитию С сентября 2012 года началось внедрение новых УМК по обучению детей татарскому и русскому языкам. В процессе обучения дети должны научиться воспринимать и понимать татарскую речь на слух и говорить по-татарски в пределах доступной им тематики, усвоенных слов. Педагоги нашего детского сада , получив новый учебно-методический комплект, с интересом взялись за дело. В июне 2012 года все русскоязычные воспитатели нашего ДОУ , а их у нас 89%, приступили к курсу ускоренного изучения татарского языка. Все педагоги прошли курсы повышения квалификации по теме «Использование новых УМК в образовательном процессе ДОУ. 100% педагогов участвует в проекте «Ана теле». Консультации, тренинги обучающие семинары, открытые занятия и мастер-классы проводились в детском саду в течении года. В результате всей проведенной работы, русскоязычные воспитатели владеют необходимым лексическим запасом , который позволяет им закреплять знания, полученные детьми на занятиях с воспитателем по обучению татарскому языку в режимных моментах и на занятиях по всем образовательным областям. Учитывая, что дети дошкольного возраста обладают преимущественно образным и конкретным мышлением, обучение татарскому языку проводится в

игровых и учебных ситуациях по темам, рекомендованным УМК для каждой возрастной группы. Поддерживать интерес ребёнка на занятии помогает ярко и красочно оформленный наглядно-демонстрационный и раздаточный материал, аудио-видео записи. Использование аудиозаписи развивает речь и воображение ребёнка. Дети с интересом ждут голоса знакомых персонажей Акбай и Мияу, рады слышать голоса новых участников: мамы, папы, бабушки, дедушки, мальчика, девочки и т.д Аудиозапись используется во время введения новых слов, повторения; даны речевые образцы, диалоги, игры, песни; записаны знакомые детям сказки для показа настольного театра. ***Воспитатели групп проводят работу по закреплению изученного материала в режимных моментах, а также*** знакомят родителей с реальными достижениями детей в овладении татарским языком; с тем, какую помощь могут оказать они детям по закреплению приобретенных знаний.

В режимных моментах используют различные дидактические игры, задача которых обучить различным видам речевой и языковой деятельности.

Разработаны авторские дидактические игры и пособия : «Азбука важных слов», «Коллаж», обучающие компьютерные программы для средней, старшей и подготовительной группы – «Посмотри и запомни», обучающие раскраски «Раскрась и запомни» способствующие закреплению пройденного материала, игры «Песочные фантазии», «Теремок», « Покорми Алсу и Айрата» и др

Авторские дидактические игры и пособия позволяют расширить детские возможности в запоминании и воспроизведении новой информации помогают ребенку усвоить лексику татарского языка

ПЕСОЧНЫЕ ФАНТАЗИИ.

Коробка 50х50х 15 см с прозрачным дном, наполненная песком.

Набор карточек 45 х48см для смены заданий.

Мелкие игрушки, мелкий строительный материал, конструкторы «Лего», транспортные игрушки.

Играть можно с сухим или влажным песком.

Игра «Секретики», «Найди пару», «Кто такой что такое», «Угадайка».

Закрепление слов в соответствии с лексическим минимумом УМК.

РАСКРАСКА-СЛОВАРИК «РАСКРАСЬ И ЗАПОМНИ» включает все слова для каждой возрастной группы (существительные) в соответствии с лексическим минимумом УМК. Воспитатель имеет возможность распечатать любые картинки по желанию детей, выбрать нужный размер, расположить на листе нужное для занятий количество картинок.

«АЗБУКА ВАЖНЫХ СЛОВ». У каждого ребенка подготовительной группы есть такая «Азбука». Родители вместе с ребенком записываю важные для ребенка на каждую букву алфавита, такой прием позволяет лучше узнать ребенка, что ему интересно, что волнует, что для него важно. В эту книжку воспитатель вписывает слова, изученные на занятиях по татарскому языку, и используют в свободное время для индивидуальной работы.

МНОГОФУНКЦИОНАЛЬНАЯ ДИДАКТИЧЕСКАЯ ИГРУШКА «ТЕРЕМ-ТЕРЕМОК».

Игра состоит из игрового поля ( в виде полянки) и домика, на которых закрепляются игрушки

На крыше домика расположена игра «Магнитная мозаика» для закрепления названий основных цветов спектра.

Детям даются задания назвать героев по-татарски, посчитать их, ответить на вопросы, построить диалог, манипулируя игрушками.

Воспитатель прячет внутрь домика игрушку или картинку, называет её по-татарски, ребенок переводит на русский язык и, открывая крышу, проверяет свой ответ. Также легко организовать игру по сказке «Теремок».

ИГРУШКИ ИЗ КИНДЕР-СЮРПРИЗА, также очень удобны для закрепление слов в соответствии с лексическим минимумом УМК , нужно только отобрать нужные . Детям даются задания назвать игрушки , посчитать их, ответить на вопросы, построить диалог, манипулируя игрушками, поселить их в домик, посчитать этажи у домика ,рассказать сказку «Теремок» на татарском языке,.

«ИГРУШКИ-ТОПОТУШКИ».

Изображение героя прикрепляется к тыльной стороне ладони при помощи резинки, на указательный и средний пальцы надевают наперстки или пробочки. Такая игрушка может «ходить», «бегать», «прыгать» на столе, при этом ножки топают, отбивая любой ритм. Интересно строить диалоги, отвечать на вопросы, выполнять команды.

«ЦВЕТНЫЕ КОРОБОЧКИ».

Закрепляются слова-названия цветов спектра, слова «большой», «маленький», внутрь коробочки можно спрятать игрушки разных цветов, сответствующих размеров, закрепить слова в соответствии с лексическим минимумом УМК.

«ПРИЩЕПОЧНЫЙ ТЕАТР» – организация игр-драматизаций на татарском языке, повторение слов, построение диалогов, игровых ситуаций.

ИГРЫ С ДИСКАМИ.

С картинками, наклеенными на использованные компьютерные диски удобно играть и закреплять слова в соответствии с лексическим минимумом УМК. Игры «Найди пару», «Мнеморина», «Назови по-татарски», Посчитай!, «Что лишнее», и т.д. Если закрепить диски с изображением на ленту, то можно использовать вместо масок

КОЛЛАЖ.

Несколько изображений одного и того же предмета или действия на большом листе – удобное пособие для закрепления изученного материала, как с одним ребенком, так и с небольшой группой детей в свободное время, картинки всегда на виду, не

требуется никакой предварительной подготовки к проведению занятия. Также дети могут играть самостоятельно задавать вопросы друг другу.

ИГРА «ПОКОРМИ АЛСУ И АЛИНУ».

Повторение слов, тема «Продукты» и других тем. Учить дете называть предметы по-татарски, отвечать на вопросы, выполнять задания, «Предложи Алсу яблоко» и т.д.

Педагоги ДОУ целенаправленно и последовательно создают ситуацию успеха . Ребенок получает удовольствие от общения и сотворчества со взрослыми и в течении всего воспитательно-образовательного процесса, организуют ситуации, вызывающие потребность в общении, учитывая возраст детей и их речевой опыт, используя разнообразные и привлекательные для ребенка методы и приемы (игровые, сюрпризные, проблемно-поисковые), творческие задания, стимулирующие речевую активность и способствующие развитию инициативной речи, творческих речевых умений. К этому процессу с удовольствием подключаются и родители наших воспитанников.

Координация усилий педагогов и родителей предшествовала и сопутствовала развитию двуязычной языковой среды нашего ДОУ. Родители и дети учатся вместе , на собраниях, тренингах, праздниках. Принимают участие в конкурсном движении .

Эффективным оказалось использование программы Скайп для организации индивидуальной работы с детьми, которые по каким-либо причинам не смогли присутствовать на занятиях по обучению татарскому языку.

*Результаты внедрения УМК в ДОУ*

Дети используют объем словарного запаса татарских слов по УМК в общении со сверстниками и взрослыми.

Педагоги в воспитательно-образовательном процессе создают языковую среду для общения, используют в работе Интернет ресурсы, в том числе мультимедиа материалов.

Родители активно включены в процесс развития своего

ребёнка через использование рабочих тетрадей, которые дают возможность усвоить лексику татарского языка, закрепить речевой материал в игровой форме, поддерживать интерес к языку.

Добиться успеха в обучении русскоязычных детей татарскому языку позволило, с одной стороны, использование личностно-ориентированного подхода к ребёнку, с другой стороны, создание языковой развивающей среды.

## ЗАМАН ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ЙӨЗ ТОТЫП

**Хәбибуллина Г. Ф.,**
**ТР Бөгелмә муниципаль районы аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 3 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең укыту эшләре һәм милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары**

Соңгы елларда Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән мәктәпләрдә белем бирүнең федераль дәүләт белем стандарты расланды һәм тормышка ашырыла башлады.

Яңа стандартлар Россия Федерациясе халыкларының мәнфәгатьләрен һәм мәгариф ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Алар рус телен һәм туган телне, рус һәм туган телдәге әдәбиятны өйрәнүгә бердәй таләпләр куя, уку планының тәкъдим ителгән 3 нче варианты буенча рус һәм татар телләрен тигез күләмдә өйрәнү өчен мөмкинлекләр тудыра.

Безнең мәктәпнең тарихы 1934 нче елда Бөгелмәдә «Тулы булмаган татар мәктәбе» буларак башланып китә. Бер елдан ул урта үрнәк (средний образцовый) мәктәп итеп үзгәртелә. Биредә Бөгелмә, Азнакай, Әлмәт, Баулы төбәгеннән татар балалары белем алган. Кызганычка каршы, узган гасырның 70 нче елларыннан ул үз эшчәнлеген рус мәктәбе буларак дәвам итә.

Бүгенге көндә мәктәптә меңнән артык укучы белем ала. «2014 – 2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Программасын гамәлгә ашырып, укучыларга ныклы белем бирү, әхлакый сыйфатлар, милли үзаң тәрбияләү, башка милләт кешеләре белән килешеп, уртак тел табып, дус булып яшәргә өйрәтү максатыннан, күп эшләр башкарыла.

Мәктәбебездә милли мәгариф системасы берничә юнәлештәге эшчәнлеккә: татар милләтеннән булган балаларга рус мәктәбе шартларында ана телендә белем һәм милли тәрбия

бирү, татар телен дәүләт теле буларак өйрәтү, толерант шәхес тәрбияләүгә нигезләнә. Мәктәптә укучы 201 татар баласының 34% туган телендә белем ала, 61 укучы татар төркемнәрендә укый.

Укытучыларыбыз бала шәхесе эшчәнлегенә кирәкле сыйфатлар булдыру мәсьәләсе белән тирәнтен шөгыльләнә. Педагогик осталыкның торган саен әһәмияте арта, укытучыдан актив педагогик эзләнү, үзенең эш тәҗрибәсендә билгеле бер укыту технологиясенә нигезләнгән методик система булдыру таләп ителә. Үз методик системаңны булдыруның төп максаты – шәхес тәрбияләү: кечкенәдән үк баланы шәхес итеп кабул итү, аның сәләтен күрә белү һәм аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү.

Заман таләпләренә туры китереп, татар теле укытучыларыбыз үз эш тәҗрибәләрендә уку эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, тәнкыйди фикерләү, шәхескә якын килү, проблемалы укыту, иҗади үстерелешле укыту технологиясе кебек инновацион алымнар кулланып эшлиләр.

1-11 сыйныфларның рус төркемнәрендә татар теленә өйрәтү педагогия фәннәре кандидаты доцент Р. З. Хәйдәрованың авторлык программалары нигезендә алып барыла. Ул программаларны куллану материалны барлык балалар да үзләштерерлек шартлар тудырырга, һәр баланың сәләтен, үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә алып укытырга мөмкинлек бирә. Укучыларыбызның татар теленнән белем күрсәткечләре югарыда телгә алынган технологияләрнең өстенлекләрен күрсәтә.

Белем бирү процессын төрле яңа укыту структуралары белән баету юнәлешендә дә эш алып барыла. **Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов үзенең бер чыгышында, ассызыклап:** «Сингапур белем бирү системасы традицион ысулларга каршы килми, аны уен формалары, эш алымнары белән баета. Укытучы тренер, партнер роленә керә. Укучылар кечкенә яки зур төркемнәрдә

эшлиләр. Дөрес фикер бергәләп табыла,» – диде.

Дифференциаль бүленешле укыту, яхшы материаль-техник база һәм квалификацияле укытучылар татар теленнән ныклы, сыйфатлы белем бирүне, укучыларның белем дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итә.

Татар теле укытучыларының мәктәп методик берләшмәсендә 13 укытучы бар: бишесе – югары, алтысы – 1 нче квалификацион категорияле. Аларның квалификация күтәрү курсларында белем алуларына, һөнәри осталыкларын үстерүгә уңай шартлар тудырылган.

Укыту һәм тәрбия эшендә укытучыларыбыз заманча мәгълүмати технологияләрдән дә оста файдалана. Мәктәп китапханәсендә һәм уку кабинетларында татар әдипләре тормышына һәм иҗатына багышланган интерактив дәреслекләр, татар телен өйрәнү өчен төрле дисклар, татарча фильмнар, язучылар әсәрләре буенча төшерелгән спектакльләрнең язмалары бар. Без телебезне башка милләт халыкларының да теләп өйрәнүләренә ирешергә телибез; аларның татарча аралашуларына омтылабыз икән, татар телен һәм әдәбиятын укытканда, яңа алымнар, ысуллар куллануның әһәмияте бик зур.

Хәзерге вакытта татар телен һәм әдәбиятын укыту күпкә катлауланды. Укытучы балада мәктәптә укытылган дистәләгән фәннәр арасыннан татар теле белән кызыксыну уятырга, туган телнең матурлыгын онытылмаслык итеп күңеленә сеңдерергә, үз туган теле белән горурлану хисе тәрбияләргә тиеш.

Республика күләмендә уздырылучы конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашу иҗади эшләүче укытучыларның хезмәтләрен тиешенчә бәяләргә, педагогик-методик эшчәнлеген активлаштырырга мөмкинлек бирә. Укытучыларыбыз педагогик укуларда, татар теле һәм әдәбияты кабинетлары бәйгесендә, татар теле укытучыларының «Мастер-класс» конкурсында һәм башка чараларда бик теләп һәм нәтиҗәле катнашалар.

Мәктәбебездә «Сәләтле укучы» дип аталган про-

грамма тормышка ашырыла. Аның кысаларында эшчәнлек берничә юнәлештә алып барыла: укучыларның фәнни оешмасы эшчәнлеге белән җитәкчелек итү, фән буенча олимпиадага әзерлек; талантлы укучыларга ярдәм һәм аларны тагын да үстерү. Укучыларыбызның фәнни, иҗади бәйгеләрдә, фәнни-практик конференцияләрдәге чыгышларының нәтиҗәләре куандыра. Ел саен «Зирәк тиен» уен-бәйгесендә, «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә, күренекле шәхесләргә багышланган фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңүче укучыларыбыз бар. Бәйгеләргә әзерләнү һәм катнашу укытуның нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә торган иң әһәмиятле чараларның берсе булып тора.

Татар телен һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк. Эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк.

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН ЗАМАН ТАЛӘПЛӘРЕ КУШКАНЧА УКЫТАБЫЗ

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН*

Форм.бум. 60x84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Усл.печ.л. 10

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com